

ҮЛМӘС ҖЫР

МУСА ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА ҖЫЕНТЫК

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1971

СБ7—39

Төзүчесе, кереш сүз һәм искәрмәләр авторы
РАФАЭЛЬ МОСТАФИН

7-4-3
94-19НМ

КӨРӘШ ҖЫРЫ

Җыр өйрәтте мине хәр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.

Муса Җәлил. «Җырларым».

1945 елның маенда совет гаскәрләре фашистларның башкаласы Берлинны алды. Шундагы Моабит төрмәсендә сакчылар да, тоткыннар да калмаган иде инде. Сугышчыларның берсе бушап калган төрмә ишек алдында йомарланып, таушалып беткән кәгазь кисәгенә игътибар итә. Анда таныш рус хәрефләре белән нәрсәдер язылган була. Солдат кәгазьне алып, тигезли дә ниндидер немец китабыннан ертып алынган бер биткә язылган түбәндәге юлларны укый: «Мин танылган татар язучысы Муса Җәлил. Мине Моабит төрмәсенә яптылар, политик яктан гаепләделәр һәм, ихтимал, тиздән атарлар. Әгәр бу язу безнең кешеләрдән берәрсенең кулына эләксә, минем иптәшләремә — Мәскәү язучыларына миннән сәлам тапшырсын».

Аннары шагыйрь соңгы сәламен җибәргән язучыларның фамилияләрен санап китә (алар арасында Александр Фадеевның фамилиясе дә бар) һәм семьясының адресын күрсәтә.

Татар шагыйренең батырлыгы турында беренче хәбәр илебезгә әнә шулай килеп җитә.

Сугыш беткәннән соң озак та үтмәстән, Франция һәм Бельгия аша патриот шагыйрьнең җырлары да әйләнеп кайта. Бу җырлар шагыйрь тарафыннан төрле кәгазь кисәкләреннән тегелгән ике кечкенә блокнотка туплангганнар. Анда йөзләп шигырь язылган. Бу шигырьләр Моабит циклы исеме астында бөтен дөньяга танылдылар.

1956 елның 2 февралендә, немец-фашист илбасарларга каршы сугышта искиткеч ныклык һәм батырлык күрсәткән өчен, өлкән политрук Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое дигән исем бирелде. Ә 1957 елда «Моабит дәфтәре» шигырьләре циклы өчен ул, шагыйрьләр арасында беренче булып, Ленин премиясенә лаек булды.

Мусаның яшьлеге бөек революцион давыллар чорына туры килә. 1919 елда, чолганышта калган Оренбург һәр яктан һөҗүм итүче акгвардиячеләрнең атакаларына каршы торган чакта, унөч яшьлек шагыйрь Кызыл Армиянең «Кызыл йолдыз» газетасы редакциясенә беренче шигырен китерә.

Кулыма мин «кызыл кылычны» алсам,
Шулай шуннан «кызыл фронтка» барсам,
Олуг бер дәрт белән сафка атылсам,
Кулымны уртага, дошманга салсам.
...Менә шунда берәр пуля очса-килсә,
Килеп ул күкрәгемне бишкә киссә,
Үлем кулы килеп басса — егылсам,
Җаным күккә — гарешка очса-китсә.

Менә шунда «бәхетле» мин, «бәхет» шул,
Минемчә зур-олуг шан — зур бәхет ул.

Ундүрт яшендә Муса үзенең туган авылында «Кызыл чәчәк» исемле балалар оешмасы төзи. Бу оешма

соңыннан ул якларда пионер хәрәкәтенең яралгысы була. Муса — авылда беренче комсомол ячейкасын оештыручылардан һәм аның иң актив членнарыннан берсе. Унбиш тулганда ул коммунистлар отряды составында, кулына корал тотып, ак бандаларга каршы сугыша. 1923 елда Җәлил Казан рабфагына укырга керә. Бу вакытта ул бик күп яза, әсәрләрен матбугатта да чыгара башлый. Унҗидегә житкәндә, ул инде шагыйрь буларак танылып өлгерә.

Яшь Җәлилнең шигырьләре көрәш һәм хезмәт романтикасы белән сугарылган. Аларда комсомолларның ялкынлы дәрте, көнкүреше, дуслыгы, мәхәббәте чагыла.

1926—1927 елларда Җәлил башта Орск өязендә, аннан соң Оренбург губерна комсомол комитетында инструктор булып эшли. Авылларда йөреп, яшьләрне оештыра, кулакларны һәм аларның ярдәмчеләрен фаш итә, яңа тормыш төзү өчен көрәштә актив катнаша. Аның бөтен иҗаты дөньяны үзгәртү һәм яңа тормыш төзү хисе белән сугарылган.

Егерменче елларда Җәлилнең «Авыру комсомолец» поэмасы киң популярлык казана. Поэманың төп герое — революцион сугышчы, Лена вакыйгаларын башыннан кичергән, Юденичка һәм Махнога каршы көрәштә катнашкан кеше. Акгвардиячеләрнең пулясы аның үпкәсен яралаган, патша төрмәләренең идән аслары сәламәтлеген какшаткан, чахотка авыруы тәмам аяктан еккан — берничә көн генә гомере калган. Ләкин ул халык яулап алган азатлыкта үзенең дә өлеше булуга шатлана, үзен шуның белән бәхетле саный.

Яшьләрнең соравын үтәп, Җәлил бу поэмасын алар алдында күп тапкырлар укый. Менә сатин күлмәк кигән, кара чәчен янга тараган, янып торган кара күзле Җәлил кызу атлап сәхнәгә күтәрелә. Аз гына дулкынланып алга күз ташлый... Үзе кебек үк яшь, сакал-мыек та чы-

га башламаган йөзләр, уңып беткән гимнастеркалар, фуфайкалар, кыек якалы күлмәкләр, кызыл ситсы яулыклар... Аннан соң һичбер ясалма пафоска бирелмичә, тирән хис белән укый башлый... Поэмага кушылып музыка уйный. Я «Титаникның һәлакәте» вальсы, я матәм маршы, я көчле «Марсельеза» яңгырый. Зал сихерләнгән кебек тынлый, ә Муса туктаганнан соң көчле алкышлар башлана...

1927 елда шагыйрь Мәскәү университетының әдәбият бүлегенә укырга керә. Шул ук вакытта ул Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Кечкенә иптәшләр» дигән балалар журналының редакторы булып эшли. Югары белем алгач, Җәлил киң ижат мәйданына чыга.

Сугышка чаклы ук инде Муса Җәлил нык танылган һәм популяр шагыйрь була. Аның шигырьләренә, җырларына, поэмаларына, балалар өчен язылган әсәрләренә һәм опера өчен либреттоларына укучылар һәм тәнкыйтьчеләр югары бәя бирәләр. Аның либреттосына Н. Жиһанов язган «Алтынчәч» операсы әлегә чаклы татар театры сәхнәсеннән генә түгел, бәлки илебезнең башка опера театрлары сәхнәләреннән дә төшми. Сугыш башланыр алдыннан Җәлил «Хат ташучы» дигән лирик поэмасын бастыра, «Илдар» операсының либреттосын тәмамлый, күп кенә яңа зур әсәрләр өстендә эшли.

Илебезгә фашистлар Германиясенең хыянәтчел һөжүме шагыйрьнең ижат планнарын жимерә. Муса сугышның беренче көннәреннән үк армиядә — башта политработниклар курсларында, ә аннан соң Волхов фронтының «Отвага» газетасы редакциясендә. 1942 елның маендa Икенче удар армия чолганышта кала. Монда Муса Җәлил дә була. Сугышчылар айдан артык фашистлар һөжүменә каршы торалар. 1942 елның 26 июнендә Муса Җәлил бер группа сугышчылар белән чолганыш бөжрасыннан чыгарга тырышып карый. Маши-

нага төялеп алар дошман тарафыннан һәрвакыт утка тотылып торган сазлык өстенә агач җәйгән юлдан зур тизлек белән баралар. Ләкин машинаның тәгәрмәче астында мина шартлый. Җәлил белән бергә булган кешеләрнең күбесе үлә. Ә Муса, авыр яраланып, шартлау дулкыны белән читкә алып ташлана. Шундый хәлдә ул гитлерчыларга әсирлеккә төшә.

Чәнечкеле тимер чыбыклар белән уратып алынган лагерьда шагыйрьнең нәрсәләр кичергән һәм ниләр уйлаган булуын аның шигырьләре ачык сөйли. Ул коточкыч бәхетсезлеккә төшүенә, хурлыклы коллыкка эләгүенә бик нык кайгыра. Аның йөрәге әрни, исән калуы өчен Ватан каршында үзен гаепле саный.

Кичер мине, илем, синең бөек
Исемең белән килеп сугышка,
Данлы үлем белән күмәлмәдем
Бу тәнемне соңгы сулышта.

Дошман чолганышында калгач, Муса үзенең дусты тәнкыйтьче Г. Кашшафка язган бер хатында барлык әзер әсәрләрен җибәрәчәге турында хәбәр итә, чөнки «төрле хәлләр булуы бар: юлда дәфтәрне яки аннан да кадерлерәген (мәс. башны) югалтырга мөмкин», дип шаяртып яза. Үзенең әдәби мирасы турында аның Гази Кашшафка алдан ук васыять язып җибәрүе һич тә очраклы түгел.

Ләкин дошман кулына эләгү турындагы фикер аның башына бервакытта да килмәгән булса кирәк. Җәлил үзенең бер хатында Волхов фронтында язган шигырьләре арасыннан «Соңгы патрон турында баллада»сын искә ала. (Җәлилнең фронтта язылган башка күп кенә шигырьләре кебек, бу шигырь дә Волхов сазлыкларында югалып калган.) Соңгы патрон... Котылу да, могҗиза да көтмәгән политрук Җәлил әнә шул турыда уйла-

на. Һәм шуңа күрә дә ул, хәрби дусты — пистолетының хыянәт итүе турында ачынып яза:

Чаян чага үзен соңгы чиктә,
Бөркет ярдан түбән ташлана.
Мин соң бөркет түгел идеммени,
Баш иярге шуннан башкага!

Нишлим, сугыш дустым — пистолетым
Соңгы сүздән кинәт баш тартты.
Богау салды дошман кулларыма
Һәм хурлыклы юлдан атлатты.

Ләкин әсирлеккә эләккәч, үлем сәгате якынайгач, Җәлилдә яшәүгә сусау тойгысы уяна. Көрәшү өчен яшәргә, кулдан килгән кадәр дошманнан үч алу өчен яшәргә:

Тик бер өмет, дуслар, сезнең сафта
Табар соңгы көрәш теләген,
Яраланган, ләкин тар коллыкка
Баш имәгән керсез йөрәгем.

Ватанга, халыкка файдалы булырга омтылу, фашистларга каты нәфрәт шагыйрьдә хәрби әсирләрнең яшерен оешмасын төзү фикере тудыра.

Сугыш башында барлык әсир «азиатларны» кырып бетерергә приказ биргән немецлар командованиесе, 1942 ел ахырында Сталинград янында уңышсызлыкка дучар булгач, аларны үз Ватаннарына каршы көрәштә файдаланырга уйлый. Ашыгыч рәвештә «милли легионнар» — төрек, әрмән, грузин легионнары төзелә... Польшаның Радом шәһәрчәгендә «Идел-Урал» легионы оештырыла башлый. Бирегә Идел буе милләтләреннән булган әсирләрне көчләп куып китерәләр. Фашистларның кабахәт ниятләрен өзү, әсирләр кулына биргән коралны гитлерчыларның үзләренә каршы бору — җәлилчеләр үзләренең алдына әнә шул бурычны куялар. Һәм

алар бу максатка шактый дәрәҗәдә ирешәләр дә. Дөрес, бу аларга бик кыйммәткә төшә. Дошманны алдау өчен, җәлилчеләргә башта немецлар белән хезмәттәшлек итәргә ризалык биргән булып кыланырга туры килә.

Җәлилгә һәм аның дусларына бу карарга килү бик җиңел булмагандыр, әлбәттә. Бу турыда аның «Ышанма» дигән шигыре буенча хөкем йөртергә мөмкин. Муса анда үзенең сөйгән ярына менә шулай дип мөрәҗәгать итә:

Сина миннән хәбәр китерсәләр,
«Ул егылган арып», — дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, якын күрсәләр.
Илдән киттем ил һәм синең өчен
Автоматым асып аркама.
Илемне һәм сине алмаштыргач,
Җирдә миңа тагын ни кала?

Муса ак эмигрантларның «Идел-Урал» комитетында эшли башлый. Яшерен оешманың башка членнарын эмигрантларның «Идел-Урал» газетасы редакциясенә, пропагандистлар һәм легион отделениеләренең командирлары итеп, типографиягә, радио тапшыру редакциясенә һәм башка жаваплы эшләргә урнаштырырга мөмкин була. Бу — «Совинформбюро» белдерүләрен даими рәвештә ишетеп торырга һәм аларны әсирләр арасында таратырга, листовкалар һәм өндәмәләр бастыруны җайга салырга мөмкинлек бирә. Үзенә фашистларның культура-агарту эшен алып барырга тапшыруларыннан файдаланып, Җәлил хәрби әсирләр лагерьларында була, һәр җирдә конспиратив элемтәләр урнаштыра, легионда оештырылган хор капелласы өчен үзешчән артистлар сайлап алу сылтавы белән яшерен оешмага яңа членнар тарта.

Көрәшчеләрнең хезмәте бушка китми.

Көнчыгыш фронтка җибәрелгән «Идел-Урал» легионының беренче батальоны (монда меңгә якын сугышчы була) фронтка барып җитмәс үк, Витебск районында восстание күтәрә, немец офицерларын һәм сакчыларын кырып бетерә, коралланган килеш, Белоруссия партизаннары ягына чыга.

Бу вакыйга гитлерчыларга җитди сабак була. Шуннан соң фашистлар татар легионнарын фронтка җибәрергә батырчылык итмиләр. Фашистлар яшерен оешма булу турында сизенәләр, провокаторлар җибәрәләр, шымчылыкны көчәйтәләр.

1943 елның августында гестапо подпольщикларның эзенә төшә. Хәрби эсирләрнең ныклап эзерләнгән гомуми восстаниесе башлануга берничә көн калганда, Җәлилне һәм аның яшерен группасының күпчелек членнарын кулга алалар.

Немец язучысы Леон Небенцаль Гитлер командованиесенең күп кенә әһәмиятле документларын тапкан. Ул документларның берсендә татар легионерлары «иң ышанычсызлар» дип аталган. Икенче бер документта «көнчыгыш иреклеләре» дип аталучылар дивизиясе командующиеның татар һәм аның күршесендә урнашкан әрмән легионнарын (җәлилчеләр алар белән бергәләп кораллы чыгыш ясау турында килешкән булганнар) һич кичекмәстән коралсызландыру турында приказы телгә алына.

Ләкин җәлилчеләрне кулга алганнан соң да фашистлар совет патриотларының каршылыгын сындыра алмыйлар. Легионерларның күп өлеше төркем-төркем булып һәм берәмләп Польша һәм Франция партизаннары ягына кача һәм сугышның соңгы көннәренә чаклы кулларына корал тотып гитлерчыларга каршы сугыша.

Моабит төрмәсенең таш капчыгына ташланган, аяк-куллары богауланган, ләкин рухы сынмаган Муса көрәшне туктатмый. Хәзер аның кулында бердәнбер корал — сүз кала, һәм шагыйрь аны әче нәфрәт белән дошманнарының йөзенә ата:

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә.
Кирәк икән үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.

Менен түгел, бары йөзен генә
Юк итәлдем синең сыңарның,
Һәм халкымнан, кайткач, шуның өчен
Мин тезләнеп гафу сорармын.

Моабитта Мусаның үзен җәзалаучыларга каршы аяусыз көрәше Чехословакиянең милли герое Юлиус Фучикның батырлыгына тиң. Җәзалауга, газаплауга дучар ителгән, ләкин «кырык үлем» куркынычы алдында да баш имәгән татар шагыйре, Фучик кебек үк, үзенең репортажын «палач балтасы астында» алып бара.

Моабит дәфтәрләре — әсирлектәге шагыйрьнең кичерешләрен турыдан-туры чагылдырган лирик көндәлек ул. Аларда тоткынлыкның авырлыгы да, азатлыкны сагыну да, йөрәк эрнүе дә бар. Коточкыч зур газаплар кичергәндә дә, авыр уйлану минутларында да без бу гаҗәеп кешенең гаять зур эчке көчен сизәбез.

Тимер чакматашка бәрелгәч бөгелә. Корыч исә очкын чыгара.

Язмыш Җәлилгә бик авыр сынаулар әзерли, аны кешелекнең киләчәге өчен көрәшнең алгы сызыгына куя. Һәм шушы алгы сызыкта шагыйрь бөгелми, каушап калмый. Киресенчә, ул үзенең рухи байлыгын ахырынача ача, гасыр белән бергә атлый ала.

Шагыйрь гомеренең соңгы көннәрендә иң тирән эчтәлекле һәм художество ягыннан камил әсәрләр тудыра. «Җырларым», «Ышанма», «Катыйльгә», «Бүләгем», «Серле йомгак», «Алман илендә», «Батырлык турында» һәм башка бик күп шигырьләрне совет поэзиясенең чын шедеврлары дип атарга мөмкин. Кәгазьнең һәр кисәген саклап тотарга мәҗбүр булган шагыйрь үзенең Моабит дәфтәренә йөрәгендә кайнап чыккан, язмый калдырырга мөмкин булмаган сүзләрне генә төшерә. Аның шигырьләренең көче әнә шуннан килеп чыга да.

Синме соң бу — бөек Маркс иле
Һәм давыллы Шиллер ватаны?
Тоткын итеп сиңа китерде дә,
«Кол» дип мине немец атады.

Шулай дипме сине белә идем,
Гёте белән шашкан чагымда?
Бетховенның кыю симфониясе
Ник яңрамый мәрмәр залында?

Шагыйрь караңгы фашизм төнендә дә яхшы һәм кешелекле Германия туачагына ышанычын югалтмый. Ул яңа Германиядә гаделлек кояшы чыгачагына һәм аңа Маркс белән Гейненың кайтачагына нык ышана.

«Немецларны — Гёте һәм Гейнены, Бах һәм Бетховенны, Маркс һәм Тельманны чын дусларча яраткан шагыйрьне үтерүчеләрнең немецлар булуы нинди хурлык һәм нинди фажига. Алар моның белән үз милләтләренә зыян китерделәр», — ди ачынып икенче бер немец шагыйре Эрих Мюллер.

Игелеклелекне, кешелеклелекне һәм гаделлекне мактап җырлавы белән Җәлил немец халкына гына түгел, бәлки планетабыздагы башка халыкларга да якын.

Латыш язучысы Ян Судрабкалн Рига шәһәрендә Җәлил шигырьләренең җыентыгы чыгу уңае белән болай

дип язды: «Бу кечкенә генә китап латыш һәм татар халыкларын бер-берсенә якынайта, коммунизм өчен бара торган уртак көрәштә туганлык һәм дуслык белән безне тагы да ныграк берләштерә».

Фашистлар төрмәсендә Муса Җәлил бельгияле Андре Тиммерманс, поляк Ян Хоцур, италияле Рениеро Ланфредини белән бик тиз уртак тел таба. Җәлилнең поэзиясе хәзер дә башка милләт халыкларының йөрәгенә үтеп керә, аларны тынычлык, демократия, кешелекнең якты киләчәге өчен көрәшкә берләштерә.

Җәлил шигырьләре дөньяның илледән артык теленә тәрҗемә ителгән. Аны Чехословакия һәм Германия Демократик Республикасында, Англия һәм Франциядә, Финляндиядә, Румыния һәм Канадада яшәүче кешеләр үзләренең ана телләрендә укыйлар. Аның исеме һәр җирдә батырлык һәм изге антка турылык символына, барлык алдынгы, демократик көчләрнең байрагына әверелде.

Шагыйрьнең үлемсез батырлыгы турында матбугат битләрендә беренче мәгълүматлар күренү белән, бу темага шагыйрьләр, композиторлар, рәссамнар мөрәҗәгать иттеләр. Җәлилгә багышлап күп санлы шигырьләр, поэмалар, балладалар, мәкаләләр, истәлекләр язылды, бераз соңрак зур күләмле әсәрләр — повестьлар, драмалар, хәтта бер роман да басылып чыкты. Н. Жиһановның Мусага багышланган «Җәлил» операсы бөтен илебезгә яңгырады, кайбер чит илләрнең опера сәхнәләрендә дә куелды. Патриот шагыйрь турында күп санлы җырлар, романслар, маршлар иҗат ителде. Муса турындагы музыкаль әсәрләр арасында үзенең эчке пафосы һәм тәэсир көче белән А. Монасыйповның «Җәлил» исемле симфониясе аерылып тора. Җәлилнең һәм аның иптәшләренең героик образларын рәссамнар һәм

скульпторлар эшләделәр һәм эшлиләр. Җәлил яшерен оешмасының эшчәнлеге турында ике нәфис фильм төшерелде: берсен, «Кызыл ромашка» исемлесен, ГДР кино хезмәткәрләре, ә «Моабит дәфтәре»н Ленфильм студиясе эшләп экраннарга чыгарды. Шулай ук Җәлилнең *тормышына һәм иҗатына* багышлап берничә документаль фильм, күп санлы телевизион постановкалар, радиотапшырулар, концертлар һ. б., һ. б. булды.

Балар барысы да Муса Җәлилнең халык күңеленә мәңге җуелмаслык тирән эз салып калдырган бөек исем булуын күрсәтә. Ул татар халкы өчен генә түгел, бик күп башка халыклар өчен дә кадерле, җанын аямый көрәшкән, сокландыргыч һәм үрнәк образ буларак яши. Шуңа күрә дә бу темага татар язучылары гына түгел, рус, немец, казакъ, калмык, башкорт, молдаван, чуваш *һәм башка халык язучылары* әледән-әле мөрәҗәгать итәләр. Заман узу белән бу образ тоныкланмый, ә киресенчә, халык аны тагы да якынрак күрә һәм язучылар да, сәнгать осталары да бу бөек образда халыкның намусын, данын, батырлыгын, иленә турылыклылыгын гәүдәләндерәләр.

М. Җәлил турындагы әсәрләрне нигездә ике типка бүләргә мөмкин. Беренчесе — документаль яктан нигезләнгән, һәр факты җентекләп тикшерелгән әсәрләр: документаль повестьлар, хикәяләр, очерклар, истәлекләр, мемуарлар, публицистик мәкаләләр, аның иҗатына багышланган монографияләр һәм тикшерүләр. Болар *арасына тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече Гази Кашшафн*ың Җәлил иҗатына һәм тормышына багышланган билгеле хезмәтләрен, рус язучысы Юрий Корольковның «Кырык үлем аша» исемле документаль повестен, Хәдичә Җәлилованың «Абыем турында» дигән мемуарларын, Роберт Бикмөхәммәтов, Нил Юзеев, Вячеслав Воздвиженский һ. б. әдәбиятчыларның китапларын,

«Муса турында истәлекләр» китабына тупланган истәлекләрне, саннары берничә меңгә җиткән газета һәм журнал мәкаләләрен кертергә мөмкин.

Икенчесе — Муса Җәлил иҗатына багышланган әдәби әсәрләр. Бу әсәрләрнең авторлары документаль төгәллектән бигрәк шагыйрьнең поэтик образын гәүдәләндерергә тырышалар. Шуңа күрә бу тип әсәрләрдә уйдырма образлар, фактик яктан нигезләнеп бетмәгән эпизодлар һәм чынбарлыкта булмаган вакыйгалар очратырга мөмкин. Әмма аларда иң мөһиме — Җәлилнең үлемсез образы онытылмаслык булып укучылар алдына килеп баса.

Мондый әсәрләр рәтенә Шәйхи Маннурның «Муса» романын, Әнвәр Давыдовның «Муса абый» повестен, Гали Хуҗиев, Нәби Дәүли, Җубан Молдагалиев, Даут Күгелтдинов, Илдар Юзеев поэмаларын, Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат пьесаларын, күп санлы шигырьләрне, балладаларны һәм башка әсәрләрне кертергә мөмкин.

Бу җыентыкка фәкать шул икенче типтагы әдәби әсәрләр генә тупланды. Аларның да иң яхшылары гына сайланып, күбесенән өзекләр генә алынды, чөнки Җәлилгә багышланган барлык әсәрләрне дә укучыларга тәкъдим итәр өчен калын-калын томнар кирәк булыр иде. Җыентыкны мәктәптә әдәбият дәресләрендә кулланма рәвешендә дә, әдәби кичәләрдә уку, сәхнәдә күрсәтү өчен материал итеп тә файдаланырга була.

Рафаэль Мостафин.

УЛ ГАСЫРЛАР БУЕ БАЛҠЫП ТОРЫР

(Муса Җәлил турында совет һәм чит ил язучылары)

«Дөньяда һәм дөнья әдәбиятында исемнәре белән иҗатларын мәңгелек данга күмгән күп кенә шагыйрьләр бар. Ләкин шагыйрь һәм герой Муса Җәлил кебек әсәрләре белән генә түгел, бәлки үлеме белән дә исемен мәңгеләштергән шагыйрьләр бик аз. Менә алар: бөек Байрон, Венгриянең *данлыклы халык шагыйре* Петефи, герой Юлиус Фучик һәм, ниһаять, Муса Җәлил».

Сәмәд Вургун,
азербайҗан шагыйре.

«Муса Җәлилнең Моабит шигырьләрендә без аның ялкынлы йөрәге тибешен ишетәбез, безгә шагыйрьнең тирән хисләре һәм уйлары, аның яшерен өметләре һәм дәртле омтылышлары ачыла. Без ул шигырьләрдә коммунистның көрәш рухын, аның һичнәрсә дә кәкшата алмаган нык ихтыярын, жиңеп чыгуга нык ышануын тоябыз. Ул шигырьләрне укыган саен, аларны бары тик корыч ихтыярлы көрәшче, илнең патриоты, халыкның турылыклы улы гына яза алганын күрәсең».

«Муса Җәлилнең соңгы көннәрен күрсәткән шактый материал безнең кулда, тик ул материаллар аның немец антифашистлары белән турыдан-туры бәйләнештә

булуын исбатламый. Ләкин интернационализм хисе белән янган бу зур шагыйрь яшьлек елларында ук немец эшчеләр сыйныфының көрәшен күзәтеп барган. Муса Җәлил 18 яшендә чагында (1924 елда) «Кисәкләр» дигән поэма язган...

1935 елда шагыйрь Германия турындагы темага тагын кайткан. «Джим» дигән поэмасында гуманист Җәлил фашистик расачылыкны фаш итә.

1943 елның декабренда язылган «Алман иленә» шигыре — пролетар интернационализмның иң көчле документы.

Моабит зинданында яткан Муса Җәлил үзен немец антифашистлары белән фикердәш санаган һәм хәтта фашист палачлар кулында тоткында яткан хәлендә дә немец халкының алдынгы көчләренә мөрәҗәгать иткән.

Саф-саф булып тагын 19 нчы
Елгы төсле жырлап килегез.
Һәм күтәреп өскә уң йодрыкны,
«Рот-фронт» дип жавап бирегез.

Борыгыз муенын комсыз карчыганың,
Кояш чыксын Алман жиренә.
Күтәрелсен Тельман трибунага,
Маркс, Гейне кайтсын иленә.

Арагызда кем бар Цеткин улы,
Тельман егетләре кайсыгыз?
Ишетегез бөек хаклык сүзен,
Төрмәләрне безнең ачыгыз, —

дип язган ул.

Моабит зинданында Муса Җәлил сагышланып көткән якты көннәр безнең республикабызда чынбарлыкка әйләнде, алар бөтен Германиядә дә чынбарлыкка әйләнәчәк. Ватаныбызның көнбатышында башларын калкытып килгән кара милитаризм көчләренә каршы, шул

бөек идеяләр өчен алып барыла торган көрәштә бөек шагыйрь һәм патриот Муса Җәлилне без үз яныбызда итеп сизәбез».

Леон Небенцаль,
немец язучысы.

«Талантлы татар совет шагыйре үзенең үлемен, коммунистларга хас булганча, батырларча каршылады. Дөньяга ташланган иң соңгы карашы да аның ачык өметле булды. Соңгы сулышына кадәр аның йөрәгендә җыр сүнмәде:

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем көрәш язына,
Сонгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла.

Муса Җәлилне немец фашистлары үтерделәр. Моны онытуы да, гафу итүе дә мөмкин түгел. Ләкин без шуңа горурбыз: ул совет шагыйренең исемен югары тотты, аның бөек мәгънәсен төшермәде. Без шуңа горурбыз: аның ялкынлы шигырьләре, үзен үтерүчеләргә һәм дөньяны яңадан канга батырырга теләүчеләргә гаеплəү акты булып, озак еллар буена яңгырап торачак. Без шуңа чиктән тыш горурбыз: безнең каләмдәш дустыбыз хәбәрсез югалмады, ул тереләр белән бергә дөньяның тынычлыгы өчен көрәшә».

Мостай Кәрим,
башкорт шагыйре.

«Мин үз гомеремдә Муса Җәлилне **бер тапкыр** да күрә алмадым, ләкин күз алдыма аны **шулкадәр** яхшы китерәм, әйтерсең мин аның белән күптән **һәм яхшы** таныш булганмын. Аның шигырьләрен **укып, мин гүя** аның халыкка һәм партиягә тугрылыклы **йөрәге белән** сөй-

ләшәм. Ул үзенең шигырьләре белән хак эшкә куркусыз барган поэзиянең батырлык икәнен, горур һәм азат шигъри сүзне бернинди сынаулар да жиңә алмавын исбат итте.

Аның «Моабит дәфтәре» — кешенең рухи батырлыгына һәйкәл, бу шигырьләр киләчәк буыннарны дулкынландырыр һәм аларда да аңа охшарга тырышу хисе тудырыр.

Әгәр үткәнгә борылып карасак, аның комсомолда узган яшьлегенә кайтсак, Җәлил шигырьләренең совет кешеләренең батыр хезмәтенә багышланган булуларын һәм хәзер дә заманча яңгырауларын, эчтәлекле икәнлеген күрербез. Аларның үсү юлы туры һәм саф. Аларның көче ниндидер гаять зур югарылыкка күтәрелергә, гаять көчле казанышта балкып күренергә тиеш булган һәм шуның нәтиҗәсендә аяусыз көрәштә сыналган «Моабит дәфтәре»нең үзе якты, үзе ачык, үзе кырыс илһам көче барлыкка килгән.

Муса Җәлилгә — беренче шагыйрьгә — гомумхалык Ленин премиясенең бирелүе югары гаделлек, безнең барлык шагыйрьләребез өчен югары үрнәк булды.

Муса Җәлилнең зур исеме — совет поэзиясенең горурлыгы һәм даны!

Гомерем минем моңлы бер жыр иде,
Үлемем дә яңгырар жыр булып!

Чыннан да шулай — Җәлил жыры, Җәлил тормышы жыр булып мәңге яңгырар!»

Николай Тихонов,
рус шагыйре.

«Муса Җәлил... Сез, Франция диварларында эленеп торган зур кызыл афишаларны онытмаган кешеләр, кабатлагыз бу исемне, хәтерләгез сезнең палачлар килә

төрган рельсларны шартлаткан Манушиянны — әрмәнне. Манушиян да төрмәдә шигырьләр язган... Искә төшерегез Муса Җәлилнең исемен: сөеклесеннән ул үзенең үлүенә ышанмауны үтенгән, чөнки җырның гомере кеше гомереннән озынрак... Муса Җәлилнең ялкынлы *җыры түгел, бәлки салкын тәне туфрак белән күмелде,* Иван Грозный солдатлары өчен түгел, Казанны яндыручылар, Казанны әллә ничә мәртәбә яндыручылар өчен түгел, үч алырга чакыручы байрак астында ант иткән руслар — бердәм туганнар өчен күмелде. Ул ант аларны алга илтте, башка бер шәһәргә — Моабит төрмәсе булган, Моабит төрмәсе урнашкан Берлинга алып китте, бөтерелеп әйләнгән жыр ялкыны анда барып җитәр алдыннан алып китте. Бу кешеләр, үзләре казыган окоплардан чыгып, поход адымы белән Рейхстагка барып *життеләр. Аларның* берсе Рейхстаг түбәсенә бик югарыга ут-ялкын байрагын — кан төсендәге ант байрагын менгезеп кадады. Һәм шундук салкын жирдә мәетләр калмады, — о Муса Җәлил, анда бары тик жиңүчеләр генә иде инде!»

Луи Арагон,
француз язучысы.

«Минем өчен Муса Җәлил сынаулар һәм үлем каршында гражданлык һәм язучылык батырлыгы күрсәткән кешеләрнең бер үрнәге булды һәм шулай булып калачак.

Ул — зур шагыйрь генә түгел, ә бәлки көчле рухлы батыр. Ул — безнең аңа карата рәхмәт хисе йөрткән хәтеребезгә нәкъ шулай булып урнашкан зур кеше».

Константин Симонов,
рус язучысы.

«Муса Җәлил!
Бу ике сүздә поэзия һәм ирләрчә батырлык чагыла.
Муса Җәлил!
Исән чагымда, йөрәгем типкән чакта мин бу ике сүзне кабатлаудан туктамаячакмын».

Степан Щипачев,
рус шагыйре.

«Бөтен дөнья культурасы тарихында, гитлеризм агуына каршы аның көрәше тарихында, кара фашизм төнендә Муса Җәлил, Юлиус Фучик белән берәттән, иң якты фигураларның берсе булып басты. Бу кешеләр — интеллигент, әдәбиятчы үрнәге. Алар — тупас физик көч өстеннән рухи көчнең тантана итүен, үз карашларына ышану тирәнлегенең хәтта төрмәдә, вакытыннан алда тантана иткән явызлыкны таш капчыкта да жиңүен күрсәткән кешеләр.
Минем өчен Муса Җәлил гитлеризмга каршы безнең героик көрәшебездә калыккан иң гүзәл фигураларның берсе булып гомерлеккә калыр».

Сергей Смирнов,
рус шагыйре.

«Ул минем күңелемә иң якын кешеләрнең һәм сөекле шагыйрьләрнең берсе буларак керде.
Җәлилне укыганда һәм уйлаганда, аның бөтен гомере батырлык булып күз алдына килеп баса. Аның белән замандашларыбыз горурлана һәм киләчәк буын кешеләре дә аңа охшарга тырышырлар.
Аның «Моабит дәфтәре» Памирның иң ерак кышлакларына кадәр килеп житте. Жиңеп үлгән кеше үлемсез була. Муса Җәлил венгр халык шагыйре Петефи һәм Чехословакия улы Юлиус Фучик белән бер рәттә. Җә-

лилнең тормышны раслый торган героик поэзиясе халыкларны якты киләчәк өчен көрәшкә чакыра, ул гасырлар буе балкып торыр».

Мирза Турсун-Задә,
таҗик шагыйре.

«Палач балтасы астында шундый зирәк, Ватанга чиксез мәхәббәт, ә фашистларга карата җимергеч нәфрәт тулы ялкынлы юллар язу өчен тимер, сыгылмас ихтыярлы, якты акыллы, зур һәм кайнар йөрәкле кеше булырга кирәк. Муса Җәлил әнә шундый шигъри юллар язды.

Шагыйрь жиңүгә нык ышанды, һәм ул жиңү көне килде. Ватаныбыз өчен гомерләрен биргән күп санлы геройлар арасында Муса Җәлил исеме сүнмәс йолдыз булып һәрвакыт янар».

Петрусь Бровка,
белорус шагыйре.

«Һәр шагыйрьнең үз язмышы була. Муса Җәлил — героик язмышлы шагыйрь. Героиканың мәгънәсен белгән грузин халкы ерак Татарстанның мәшһүр улы Муса образын чын күнелдән ярата. Ватаныбызның барлык халыклары кебек үк, без дә куркусызлыгы белән бөтен дөньяны таң калдырган яшь һәм сокландыргыч шагыйрьне үзебезнең йөрәкләребездә саклырбыз».

Георгий Леонидзе,
грузин шагыйре.

«Тугандаш татар халкының бөек улы Муса Җәлил истәлеге гасырлар буе яшәр. Ул зур кеше, зур гражданин һәм зур шагыйрь иде. Советлар Ватанына мәхәббәтен ул үзенең сокландыргыч гүзәл шигырьләрендә жырлады. Совет Ватаны өчен гомерен корбан итте.

Аның шигъри батырлыгы яшәү батырлыгы белән кушылды. Бу батырлык фажигале, ләкин һәркемне көнләштерерлек. Муса Җәлилнең язмышы һәм фидакарь поэзиясе миңа Литва шагыйрен — Бөек Ватан сугышында фашист палачлары кулыннан һәлак булган Витаутас Мотвил язмышын һәм иҗатын хәтерләтә.

«Моабит дәфтәре»нең литва теленә тәрҗемә ителүе, бөек шагыйрьнең үлемсез даны, бөтен дөньядагы кебек үк, минем хәтеремдә дә яшәве миңа шатлык бирә».

Антанас Венцлова,
Литва язучысы.

«Мин аның белән 1936 елда таныштым. Тиз арада «Джим» поэмасын — фашистлар Германиясе турындагы, төрмәләр, шуларның берсендә шагыйрь үзе дә һәлак булачак төрмәләр турындагы әсәрен тәрҗемә иттем. Тәрҗемә өстендә автор белән даими иҗат бәйләнеше тотып эшләдем. Ул чакта шагыйрь Мәскәүдә тора, ул миндә була, ә мин аның Столешников тыкрыгындагы квартирында була торган идем.

Ул мөлаем, нечкә хисле, бөтен табигате белән музыкаль кеше иде».

Семен Липкин,
тәрҗемәче.

«...Кеше хыялы кешеләргә ут таратып биргән өчен таш кыяга кадакланган Прометей образын тудыра. Бу образ, жирдә кешеләр бәхете хакына көрәшкә һәм батырлыкка чакырып, миллион йөрәкләрдә меңнәрчә еллар буе яши. Муса Җәлил үзенең батырлыгы белән Прометейдан да югарырак күтәрелде дияр идем мин: ул күңеленең сүнмәс утларын таратуны Моабитның таш

стенасына кадакланган хәлдә дәвам иттерде. Аның көче әнә шунда, үлемсезлеге әнә шунда».

Кирәй Мәргән,
башкорт галиме.

«Муса Җәлил шигырьләрен мин һәрвакыт каушау һәм дулкынлану хисе тоеп тәрҗемә иттем. Бу соклангыч кешенең һәм ялкынлы шагыйрьнең фаҗигале язмышы хакында уйламыйча гына, аның әсәрләренә кагылырга ярамый».

Анна Ахматова,
рус язучысы.

«Муса Җәлил тирән ихтирамга һәм соклануга лаек кеше булып яшәде һәм шулай үлде. Аның «Моабит дәфтәре» — какшамас ышану, гаять зур ихтыяр көче, якты, актив гуманизм хакында сөйләүче документ.

Гражданин һәм шагыйрь Муса Җәлил батырлыгында тугандаш татар халкының рухи матурлыгы, көчле зур жаны, бетмәс-төкәнмәс каршы торучанлык куәте чагылды».

Рәсул Рза,
азербайҗан шагыйре.

«Муса Җәлил — татар халкының сокландыргыч улы, аның җырчысы һәм аның герое — бөтен совет халкының сөекле шагыйренә, данына һәм горурлыгына әверелде.

Моабит палачлары Җәлил поэзиясен үтерә алмадылар. Җәзалап үтерелү алдыннан, ул богауланган кулы белән: «Гомерем минем моңлы бер җыр иде, үлемем дә яңгырар җыр булып», дип язды.

Җәлил хаклы. Аның яшәве үлемнән көчлерәк булды, чөнки аның батырлыгы — мәңгелек, ә җыры — үлемсез».

Марк Лисянский,
рус шагыйре.

«Шагыйрь — кешедән аерылгысыз. Аның тормышы һәм иҗаты бер эздән ага. Әгәр шагыйрьнең шигырьләре күкрәүләрдә һәм давылларда туса, бу хәл аеруча әһәмият казана.

Поэзиянең куркусыз батыры үлемне җиңгән, баш өстендә палач балтасы күтәрелеп торган бер вакытта, кара фашист тоткынлыгында, каты кул һәм нык рух белән үзенең «Моабит дәфтәре»н иҗат иткән. Кешеләргә тугрылык, Ватанга тугрылык турындагы шигъри ант аның озакламый тибүдән тукталачак йөрәгендә мәңгелек чишмә төсле ургыла.

Ул үзенең кыска, ләкин якты шигъри юлында, үз каны белән беркетелгән иҗат батырлыгында безгә тынгысыз васыять калдырган. Моны киләчәк буыннар ислә-рендә изге мирас итеп тотарлар.

Әсир ителгән, ләкин буйсынмаган сугышчы шагыйрьнең чәнечкеле юлы Литва җире аркылы да узган. Тик үлемсез геройның безгә шулай кадерле булуы моның белән генә аңлатылмый. Легендалар белән бизәлгән, яктылыгын һичкайчан жуймаячак дан белән бүләкләнгән герой хәзер дә үзенең рухланып язылган шигъри юллары белән туган Татарстанына эндәшкән кебек, Неман буе халкына, безнең бөтен Ватаныбызга, ирек сөюче кешеләргә, поэзиянең һәм азатлыкның бөтен дөньядагы барлык дусларына мөрәҗәгать итә».

Эдуардас Межелайтис,
Литва шагыйре.

ЕВРОПА ӨСТЕНДӘ ҖӘЛИЛ ТАВЫШЫ

Арагызда кем бар Цеткин улы,
Тельман егетләре кайсыгыз?

М. Җәлил.

В последний раз — опомнись, старый мир!

А. Блок.

Син беренче иден:
Син күтәргән иден беренче кат
Яшь давылның тәүге байрагын;
Пролетарның туган жире, Гареп,
Һәм Марксның тәүге мәйданы
Син иден.

Син беренче иден... Люмпеннарың
Тәү набатны көткән кичләрдә,
Пролетарий кызлар мансардларда
Коммунага байрак чиккәндә
Син беренче иден...

Еракта син, Гареп, ул көннәрдән,
Еракта син хәзер,
Бер гасырлык ара артында;
Катып калган анахронизм син
Ирек алган азиат каршында.

Кайда синең
Чартистларны биргән,
Маратларны биргән илләрең?
Кайда синең
Гильотиналарда
Король башын кискән ирләрең,
Кайда инде?

Кем син хәзер, кем син?
Әйтерсең лә
Яман улы яхшы атаның:
Чуен корольләре кулы аша
Коммунарга хәнҗәр кададың...

Вәхшинең дә кулы бармый аңа —
Шигырь асу, шигырь суюга...
О, бюргерлар! —
Поэзия каны,
Җәлил каны сезнең муенда!

Бу кан өчен нацист кына түгел,
Черчеллең дә мәсьүл, Көнбатыш...
Шулмы сезнең «без мәдәни» дигән,
«Без элита» дигән дөньягыз?

Гуман чорың кайда, Бонн һәм Лондон?
Юк, сез моны
«Аңламыйсыз» ла:
О, ни оят! — Биш йөз депутатка
Бер коммунист... парламентында!

Җәлил йөри, тере тавыш йөри
Җырны аскан илләр ягында,
Блок бара якын юлдаш сыман,
Блок бара Җәлил янында...

Россияннар исемен ишетү белән, —
Мәдәни дә гәрчә үзегез, —
Урта гасыр незуиты йөзен
Хәтерләтә башлый йөзегез.

«Татар» сүзе «тартарлары» белән
Синоним дип йөргән бюргерлар,
Монахларыгыз язган сафсатага
Нигезләнгән сезнең бу «җыр»лар.

Кем коткарды сезне, кем коткарды
Көрән реванш динозаврыннан? —
Кызларыңның, толларыңның канын
Көрән елан имгән чагыннан,
Кем коткарды
Ярты Европаңны
Нацист итеге изгән чагыңнан,
Кем коткарды?

Җәлил килә, тере тавышы килә
Кара йөзле җәллад каршына.
Блок килә аның белән бергә,
Терәк булып халык тавышына.

ИРТӘЛӘР ҖИТТЕ ИСӘ

Әминә Җәлилгә

Иртәләр җитте исә,
Аклысын кия ярын:
Юлларда күзе аның...
Ә юлда — җилләр исә,
Иртәләр җитте исә...

Аклысын кия ярын,
Карасын кими әле:
Белми ул, белми әле
Сугышта ниләр барын,
Аклысын кия ярын...

Юлларда күзе аның...
Ә юлда — куе тузан,
Син килеп чыгар сыман
Тузанга батып тагын,
Юлларда күзе аның...

Ә юлда җилләр исә:
Җил, йөгерел килеп кереп,
Сөенечләр бирер кебек...
Күзләре юлда гизә...
Ә юлда — җилләр исә...

Иртәләр җитте исә,
Уян да, терел дә син,
Кайт әле өеңә син:
Күр, гомере ничек кичә,
Иртәләр җитте исә?

МОАБИТНЫ КҮРДЕМ ТӨШЕМДӘ

Моабитны күрдем төшемдә мин,
Фашистларны күрдем төшемдә.
Күрмәсәңче, дөнья, беркайчан да
Күрмәсәңче моны
Өнеңдә.

Тәрәзәсе тимер пәрәвезле,
Һәр ишеге кат-кат йозаклы.
Һәр допросы урта гасырдагы
Инквизитор эшенә охшашлы.

...Менә килә, минем өскә килә
Алты потлы көрән үрмәкүч...
Очраштым мин азмы аның белән
Куллар бәйле хәлдә
Күзгә-күз.

Алты потлы көрән үрмәкүч күк,
Килеп баса менә каршыңа,
Шнапс исе бәргән исерек кулын
Тыга синең керсез җаныңа.

Тыга, капшый
Илгә мәхәббәтне, —
Җанның иң саф алмазын эзли.
Айлар буе, еллар буе шулай
Тенти, капшый... протокол төзи.

Көн дә шулай:
Безнең нәфрәтләрнең
Утларында яна-яна ул,
Туган илгә мәхәббәтебезнең
Гәүһәрләрен талый, мародер...

Тәрәзәсе тимер пәрәвезле,
Һәр ишеге кат-кат йозаклы.
Үтерелергә сәгать калган чакта
Нигә минут
Озын бу чаклы?!

Дивардагы акшар асларында
Кансыл кызыл хәреф эзләре,
Кар астында калган гүрләр гүя
Җәлилләрнең
Соңгы сүзләре.

Бармагымны ярып,
Каным белән
Соңгы сүзне яздым диварга:
Кем дә булса, бәлки, исән калса,
Алып чыгар аны дөньяга.

Минутларның авыр озынлыгын
Ничек итеп онтып торырга?..
Тиргәшәм мин шунда Гегель белән,
Бәхәсләшәм
Җаным турында...

— Әгәр дә җан идея генә булса,
Нигә кулны *бәйләп куялар?!*
Димәк, безнең йодрыкларда, Гегель,
Марксизм исен тоялар!
Тиздән мине атачаклар менә,
Кил, карап тор, Гегель, син шуна:
Материядән аерым җан юклыгын
Сүзсез генә
Раслыйм мин сиңа!..

Моабитны күрдем төшемдә мин,
Фашистларны күрдем төшемдә,
Күрмәсәнче, дөнья, беркайчан да,
Күрмәсәңче моны
Өнеңдә.

ҖӘЛИЛ ШӘһӘРЕ

Мең дә бер кат рәхмәт әйт бу чорга:
Саклый истә, куша, әмере нык.
Замандашың, күр, каршыңа баскан,
Шәһәреңә синең әверелеп.

Корпуслары җиде генә әле,
Җитәр беркөн җитмеш җидегә...
Җәлил аша чорның үзенә карыйм,
Башым куеп ачы җиленә...

Моабиттан чыккан ялкыннарда
Тотканнардыр кебек кирпечне...
Җырларыңа күчереп калдыр икән
Киләчәгең өчен син көчне...

Урам, парк, шәһәр булып яшә,
Шулар өчен кер дә син утка...
Кирпечләрен тезгән чакта заман
Әйләндерсен җырың цементка.

Кем бу чорга якынрак тора:
Синме, улмы? Уйдан ара баш...
Җилләр ачы, истәлекләр ачы,
Шатлык белән сагыш аралаш.

Һәйкәл урынында уйланулар

Башка чакта гел кисәтеп килде
Безне заман: артык җәелмә...
Ә бу юлы бер дә икеләнми
Һәйкәл кирәк, диде, Җәлилгә.
Ул кодрәтле, ул йөретә эшне,
Ул мең еллар буе биеткән...
Һәйкәл өчен урын сайлый заман,
Шагыйрьләргә әйбәт биектән...
Шәһәр Советының каршысында
Калку урын... чынмы, әйт әле;
Александр II нең, имеш,
Шул урында торган һәйкәле?
Биек урын, сигез гасыр тулган
Тарихы да шунда, тирәндә...
Шул урында мәңгеләшсен шагыйрь,
Ичмасам, үч итеп тиранга...
Җыелыр беркөн Әхмәт Симаевлар,
Шабаевлар, Гайнан Курмашлар...
Читтә бергә, үз илендә нигә,
Монда нигә бергә булмаслар?
Җыелырлар бергә, күзләренә
Текәлеп бер, әйдә, карыйкчы:
Инженер да, җырчы да бар монда,
Бухгалтер һәм шагыйрь, тарихчы...
Җыелырлар Җәлил тирәсенә
Безнең кешеләр, безнең илнеке...
Бер һәйкәлгә урын сайлый заман,
Ә күңелемдә минем — уникe...

ТОРЫГЫЗ, МУСАЛАР...

Кайвакыт күп төрле
Уйлардан йөдисең...
Килә бер җир буйлап
Кычкырып йөрисем:
Басуда — арышлар,
Бакчада әнисләр
Өлгерде, торыгыз,
Торыгыз, Алишлар...
Кайвакыт тынлыктан
Качасың юри син...
Килә бер җир буйлап
Кычкырып йөрисем:
Дошманнар тынмаслар,
Коялар яңадан
Кургашлар, торыгыз,
Торыгыз, Курмашлар...
Кайвакыт исним дә
Чәчәкле җил исең,
Килә бер җир буйлап
Кычкырып йөрисем:
Чәчәкләр үсәләр,
Көн саен тормышта;
Сез кирәк, торыгыз,
Торыгыз, Мусалар...

ЯКТАШЛАР

(Повестьтан өзек)

II

Җомга көн начар түгел иде. Көн иртә үк башланды. Тәрәзәләрдән иртәнге алсу нурлар сибелде. Тәрәзәләр төне буе ачык торганнар, йокы өенең һавасы да бик әйбәт, салкынча иде.

Муса көрән одеял астыннан башын калкытты. Йокы өендә тынлык. Шәкертләр үлгән кебек йоклый. Хәер, почмакта үзенә аерым ширма корып йоклаган мөбәссир (мәдрәсәләрдә тәртип саклаучы) Балтачев кына, бер ягыннан икенчесенә әйләндеме, карават шыгырдап куйды һәм шунда үк тынды.

Галибанә яктырып әкрен генә
Ал таң ата! —

диде Муса, Тукай шигырен исенә төшереп, һәм елмайды. «Бүген җомга. Дәресләр юк. Иртәнге чәйдән соң өйгә, әтиләр янына барып кайтасы иде бит. Кичә утын китергән булырга тиешләр, ярышасы, өешәсе бар бит. Мөбәссирдән рөхсәт алырга кирәк». Муса шулай дип уйлап алды.

Мусаларның авылдан күчеп килүләренә бер ел булды. Атасы «бәлки, шәһәргә барсак, җүнлерәк яшәмәбезме икән», дип шәһәргә күчеп килгән. Мусаның дәү әнисе

Гыйльми әби әйтмешли, «кайда барсаң да, бәхет үз артыңнан ияреп йөри икән». Беләк көченә, маңгай тиренә ышанган Мостафа кайда гына барып бәрелмәсен, тормыш бер яздән чыкмады. Әле Әхмәт байның йон юа торган фермасына барып бәрелде, әле Баһау картның постоялый дворында тирес чыгарып карады — берсе дә гаилә тамагын туйдырырлык рәт бирмәде.

Кәрвансарай артындагы икмәк пешереп сатучы түгәрәк сакаллы Гыйлемдар карт чәйханәдән чыгып килгәндә, Мостафаны очратып, үзенә тоз күтәртеп алып киткән иде. Юл буенча аның тормышын сорашып барды. Мостафа бу кешегә бөтен нужасын сөйләп ташлады. Авылда бер дә рәт булмагач, бала-чагасын төяп шәһәргә килүен әйтеп салды. Гыйлемдар карт сүзне тыңлап бетергәч:

— Исемең ничек синең?— диде.

— Мостафа.

— Их, Мостафа, Мостафа,— диде Гыйлемдар карт,— фәкыйрьне аны ходай авылга да, шәһәргә дә мул итеп өләшкән. Аны кузгатып маташырга ярамый. Шәһәрдән авылга бер фәкыйрь китә икән, авылда өр-яңа бер фәкыйрь арта, авылдан шәһәргә бер фәкыйрь килә икән, шәһәрдә бер фәкыйрь арта. Фәкыйрь арттымы — бай байый. Син шуны да белмисең икән!— диде.

Өенә җиткәч, ике пот тоз күтәреп килгән Мостафага ике тиен акча бирде. Бирде дә рәхәтләнеп көлде.

— Безнең шәһәрдә иң арзан әйбер тоз, авыр булса да, җиңел булса да тоз. Син тирләсәң дә, арысаң да, сиңа ике тиеннән артык акча биреп булмый. Әгәр син миңа ике пот бал күтәреп килсәң, мин сиңа биш тиен бирер идем.

— Уратып сөйләвеңне анламыйм,— диде Мостафа.

— Рәхәтрәк, турырак яшисең килсә, җиңел кәсеп табарга кирәк. Менә минем акыллы сүземнең асыл мәгъ-

нәсе шунда.— диде Гыйлемдар карт. Мостафа бу карттан аерылып берничә ай гомер үткәннән соң «ул әйткән сүз шул түгелме икән?»— дип, барлы-юклы әйбереп сатып, иске-москы алып әвеш-түеш итеп карады. Ләкин сәүдә эше турыдан-туры алдашуга бәйләнгәнлектән, ул моны булдыра алмады, күнеле тартмады, кулы бармады.

Ул Миновный урамында «аусак, җир күтәрер әле» дип кояш чыгышына таба кыйшая башлаган кечкенә генә агач йортта тора бирде. Хуш күнелле хатыны, түгәрәк йөзле, уйчан күзле Рәхимә апа, ирен борчырга теләмәде, аның бер уена да каршы килмәде. Әчтән генә «язмыш аны миннән башка да жәфалый, мин читәрәк торсам да ярар»,— дип уйлады. Ә Мостафанын зирәк акыллы анасы Гыйльми карчык шушы сүзләр белән тынычландыра барды:

— Борчылма, күпме сикерсәң дә, кендегеңнән югары сикерә алмассың. Дөньяда нужа күрүче бер син генә түгел.

Муса бүгенге кояшлы жомга көнне әнә шул өйне, шул гаиләне искә төшерде. Бүген ул ничек тә кайтырга тиеш иде.

Әле берәү дә торырга уйламый. Мөбәссирдән башка әйләнеп ятучы да юк. Юк, алай түгел, әнә Заһит әйләнеп куйды, тәрәзәдән битенә төшкән кояштан качып одеялын башына таба тартты, аннан тагын ачты.

Муса урыныннан торды да, сак кына басып, Заһит яткан карават янына килде. Ул тыныч йокламый, күзен бер ныграк йомып куя, бер яртылаш кына ача. Мусага ялгыз кыен, ул кемне булса да уятырга тели, әмма ни өчен, үзе дә белми. Тик шуны белә: аның ялгыз каласы килми.

Заһитның колагына табан иелде һәм әкрен генә:

Кояш чыкты, нур балыкты,
Тәрәзәдән һәм калыкты,—

диде. Моны һәрбер шәкерт белә, кирәксә дә, кирәкмәсә дә кабатлана торган шигырь иде ул. Муса үзе дә туеп беткән иде инде бу шигырьдән, шулай да Зәһитны уятырга ярады. Зәһит кара күзләрен зур итеп ачып җибәрде һәм сискәнеп торып утырды.

— Нәрсә бар?

— Берни дә юк.

Зәһит караватка кире ауды. Муса аны кабат уятып маташмады. Ялгыз калу аңа кыен иде, шулай да ул үз урынына барды, караватына чалкан төшеп ятты. Уйланды. Сөнәлем Зәйнәпкә атап бер шигырь язасы иде, ул аны бер ишетүдә ятлап алырлык булсын иде. Менә шулай:

Их, син, Зәйнәп,
Кара әле шәйләп,
Йөрмә сагыз чәйнәп,
Яулык бәйләп.

Кинәт йокыдан торырга звонок шалтырады. Караватлардан башлар күтәрелде. Мәбәссир Балтачев ширмасы артыннан килеп чыкты һәм кычкырып җибәрде:

— Торыгыз, таһарәткә сезгә аерып азан әйтергә мени?

Мәдрәсәдә хәрәкәт башланды.

Муса урынын җыйгач та Зәһит янына килде.

— Мин бүген бер нәрсә уйладым.

— Нәрсә?— диде Зәһит ялкау гына.

— Спектакль куябыз. Мин пьеса язарга керешәм. Өч кешелек. Берсен син, берсен мин уйныйм. Тик тагы бер кыз табарга кирәк. Кыз кешесез булмый, шәп чыкмый, матур булмый. «Варенье» дип атала.

— Ләкин шәп яз,— диде Зәһит,— дөньяда аның кебек пьеса булмасын.

— Син бигрәк тагы. Тик бу турыда ләм-мим, бер кешегә дә сөйләмә, эчтән тын.

Муса Заһит янында озак тормады. Бик кыска вакыт эчендә булган бу аз гына сөйләшү Заһитны шактый уйга калдырды. Мусаның чынлап та күптән шундый теләге бар иде. Зурлар, югары сыйныфларда укучылар спектакльләр куялар. Ә кечкенәләр өчен рольләр юк, булса да берәү-икәү генә була. Дөресен әйткәндә, алар да роль түгел, сәхнәгә чыгалар да, «Әти кайтып килә», «Безгә кунакка барыгыз», «Бозау сыерны имә» кебек бер-ике сүз әйтәләр дә югалалар. Ә бит балаларның да уйныйсылары, сәхнәдә озак торып, озын-озын сүзләр сөйләп, көлеп, шаярып, кайгырып, җылап, тагын әллә ниләр эшләп уйныйсылары килә. Аптырагач алар цирк карап кайтсалар, шундагы клоуннар булып кыланалар, я булмаса көрәшчеләрнең көрәшләрен уйныйлар. Кайсылары үзләренә циркта көрәшүче Заикин, Иван Леший, Иван Светогур, Хаҗи Мукан, Сәет Кахоталарның исемнәрен алганнар. Боларны да уйнарга урын юк. Дөрес, биш вакыт намаз уку өчен билгеләнгән мәчет бүлмәсе цирк өчен бик уңайлы. Анда яшел сукнодан бөтен идәнне тутырып намазлык җәелгән. Анда тик намаз гына укырга рөхсәт итәләр. Беркөн ачкычын элэктереп француз көрәше оештырып караганнар иде дә, моның өчен бик каты элэкте, икешәр көнгә ашаудан мәхрүм иттеләр. Заикин, Хаҗи Мукан, Сәет Кахоталар кешеләрдән соранып алган сохари, икмәк катылары кимереп йөрделәр.

Муса үзенең пьеса язарга йөрүен тик Заһитка гына әйтте. Аңа да бит: «Бу турыда ләм-мим, беркемгә дә сөйләмә, өчтән тын!»— диде.

Заһит иртәнге чәйдән соң Мусаны эзләсә дә таба алмады. Ул, мөбәссирдән рөхсәт алып, аталарына кайтып киткән икән.

III

Муса Тоз базары аркылы чыгып, спирт заводы урамына борылган иде, сакалы җиткән олы гына бер солдат артыннан килеп җитте дә:

— Тукта әле, туганым,— диде. Аның кулында кечкенә генә капчыгы да бар иде.— Син, туганай, Мостафа малае түгелме?

— Әйе.

Солдат аңа тагы да бер тикәлеп карап алды. Ябыккан, йончыган бу солдатның күзләре, «әйе» сүзен ишетү белән, ялтырап, уйнап куйды.

— Атлавыңа караганда, шушы да Мостафа малае булмаса, дип уйлап килә идем шул. Мусасымы әле син?

— Әйе, Мусасы.

— Ә мин Габдрахман исемле булырмын. Кәли бабаңны беләсеңме, муллада ялчы булып тора иде, шуның улы инде мин. Үзегезгә кайтып барасыңмы?

— Әйе.

— Мин дә сезгә китеп барам.

Муса «өйгә кайткач, ашамам, икмәкләре үзләренә калыр» дип килә иде, менә сиңа кирәк булса, шактый зур авыз ияртеп кайтып килә. Мостафа шәһәргә күчкәч, элек постоялый дворга төшә торган кайсыбер авылдашлары аларга төшә торган булдылар. Ярый әле аның кайберсе икмәге-азыгы белән килә, ә кайбер мәрәвәтсезләре: «Менә, Рәхимә җиңги, авыл күчтәнәче»,— дип, ярты икмәк бирә дә ике-өч көн ашап ята. Хәтта кайберсе, сатарга дип сарык-мазар алып килгәннәре, ишек алдында сарыгын әйбәтләп суя, туный да бер пешерерлек ит тә калдырмый, аны базарга алып чыгып китә, ә итен сатып бетереп кайткач, үчекләгән сыман: «Әмма бу хәтер дигән нәрсә юк шул минем, бер пешерерлек ит тә калдырмаганмын»,— дип риялык күрсәтә. «Менә сиңа

каерып ашый торган ныклы бер солдат, капчыгы да бик кечкенә күренә, сохарие да юктыр әле».

Солдат бик качык күренә. Мусаның уку хәлләрен сораша.

— Син бу мәдрәсәне бетергәч, кем булып чыгасың инде, кемлеккә укыталар?

— Үзем дә белгән юк,— диде Муса (бу мәсьәлә Мусаның гына түгел, башка олы шәкертләрнең дә башын вата иде),— укытучылар да чыга инде моннан, контәрщиклар да була икән, артистлар да, шагыйрьләр дә чыккан.

Габдрахман үз алдына гына сөйләнгән сыман:

— Артисын беләм инде, кәмит уйнаучы. Безнең авылның Хәлил кебегрәк була инде. Хәлил Әбҗәлилов абзаңны беләсең бит, ә шагыйрь дигәне кем була соң аның?..

Муса «шагыйрь» сүзен солдатка бик гади, аңлаешлы итеп төшендерергә тырышты.

— Шигырьләр, җырлар, хикәяләр, китаплар язучы Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури кебек кешеләр.

Мусаның «Тукай кебек кешеләр» дигән сүзен ишеткәч тә, Габдрахман солдат шигырь турында бөтен ишеткәннәрен хәтереннән үткәрде һәм Мусага бала кешегә караган сыман карап алды:

— Тукай дисең икән, юк, туган. Тукай ул берәү генә була. Ә конторщик, мөгаллим дисәң, алар йөзләп була, ә мулла белән мәзин, таз кебек, һәр авылда була. «Авыл тазсыз булмый» дигән мәкальне беләсеңме, шуның кебек, авыл муллысыз да, мәзинсез дә булмый. Ә Тукай? Тукай берәү генә була.

Муса карышмады. Дөрес, шагыйрьләр турында ул Габдрахман солдатка караганда бик күп белә. Шагыйрьләр саны йөзәрләп, меңәрләп икәнен дә белә. Дөньяда Тукай кебек зур шагыйрьләрнең дә байтак икә-

нен ишеткәне бар. Ләкин чынлап та Тукай бер генә. Габдрахманнар, Мусалар, Габдуллалар күп булганда да, әле сүз алып барган Тукай бер генә. Бу сүзне Габдрахман бик дөрес әйтте.

Габдрахман солдат ач яңакларын елмайтып көлде дә тагы да өндәште:

— Әйдә, бәләкәй генә булса да, бер Тукай булырсың может; тырыш, туганай, укыган хур булмый. Фронтта да күрдем мин, писарь булып булса да йөреп ята ул. Тәмәкесе юк икән, кешегә адрес язып булса да тарта ул.

Мусалар ишек алдына барып кергәндә, Рәхимә апа кечкенә генә таш өстендә ком белән ышкып самавыр агарта иде. Самавыр көзге кояшка ялтырап ишек алдына ямь биргәндәй итә. Ул Мусаны күреп елмайды да, күзе Габдрахман солдатка төшү белән, аптырап китте. Әллә Мусага бер-бер нәрсә булып, аны алып киләме дип уйлады, самавыр агарта торган юкә мунчаласын кулыннан төшерми урыныннан торды.

— Әллә Рәхимә җинги танымый инде?— диде Габдрахман солдат, аның исәнләшүе дә шушы сүздә иде.

— Габдрахман дисәм,— диде дә сүзен бүлде Рәхимә апа.

— Картаеп киткәнме?— дип әйтеп куйды Габдрахман.

Рәхимәнең йөзе ачылды.

— Габдрахман шул, менә алланың рәхмәте төшкере,— шунда ук юеш кулын да сөртмичә килеп күреште.— Сакалың җиткәч, нәкъ әтиең Кәлимулла агай булгансың да куйгансың. Әниең куаныр инде, рәхмәт яугыры.

— Үзем дә бик куанып кайтып киләм,— диде Габдрахман солдат,— Саелмыш, Буласа, Тук буйлары бик сагындырды. Рәхимә җинги, өч ел сугыш бит, сугыш — сабан туе түгел шул,

— Алай исән кайткач, бик әйбәт инде, кайсысы кулсыз, кайсы аяксыз кайта, кайсысы бөтенләй кайтмый кала.

Рәхимә җиңгинең күзеннән мөлдерәп яшь чыкты. Мусага хәзер генә бу солдат якын булып китте. Юкса ул аны артык тамак дип хафаланып килә иде.

Габдрахман солдат бөтенләй ачылып китте, көлаклы бүреген чишеп ташлады, гимнастеркасының изүләрен ычкындырып җибәрде. Самавыр кайнап чыкканчы, байтак хәбәрләр сөйләде, ә Муса, читтә генә торган килеш, Габдрахман солдатның бөтен сүзләрен күңеленә сала барды.

— Туган ил, Рәхимә җиңги, үзең аунап үскән туфрак сагындыра икән ул. Мостафа абай нигә кайтмый әле, күреп китим дигән идем. Тизрәк шул Саелмыш елгасында бит юасы килә.

— Кунып китәрсең,— диде Рәхимә,— Мостафа ни, хәзер кайтып җитәр ул. Күрми китсәң, үпкәләр. Сине бик ярата бит ул. Җиһангир дигән хәрчевня тотучыга биш көн кар базы казыган иделәр, шуның акчасын алам дип киткән ие, кайтыр инде, бик озаклады.

Сүз Габдрахманның кайткач нишләргә уйлавына күчте. Шунда гына Габдрахман үзенең күкрәгендә пуля утыруын, шуңа өч айга отпуск бирүләрен әйтте. Чәйгә утырыгда, Мостафа кайтып керде. Аның төсе үзгәргән, тәмам сөмсере коелган, кашлары җимерелгән иде. Габдрахман солдат урыныннан торып аңа каршы барды. Мостафа үзен көчләп кенә елмайды, Рәхимә апа ни дә булса булганлыгын бик тиз сизеп алды. Муса да атасының күңелсез хәбәр белән кайтканлыгын тойды.

Мостафа кесәсеннән илле тиенлек көмеш акча чыгарды да өстәлгә бәрде. Өстә ябылмаган такта өстәлгә акча тык итеп алды да сикереп җиз подноска төште, монда да чылтырамады, тык итеп кенә калды.

— Ни бар?— диде Рәхимә. Утыз елга якын торып, иренең мондый хәрәкәт ясаганын күргәне юк иде аның.

Мостафа Мусага «кайттыңмыни?» дип исәнләшкән кебек итте дә, Габдрахман солдат янындагы бүкәнгә килеп утырды һәм авыр итеп тын алды.

— Бер кәкрәеп беткән карт белән Җиһангир дигән бер харчевня тотучыга биш көн буена погреб өчен ям казыдык. Бүген икәүләп шуның акчасын алырга бардык.

Мостафа поднос өстендә яткан акчаны кире алып, учында, бер-ике тапкыр сикертте дә Габдрахман солдатка тоттырды.

— Сизәсеңме шунда берәр әйбер?

Габдрахман солдат шулай ук акчаны учында сикертеп карады да:

— Нигә, акча бит, менә патша башы да бар,— диде.

Мостафа акчаны солдаттан алып Мусага бирде:

— Мә кара әле, улым, синең күз үткенрәк, шунда бер хикмәт барын беләсеңме икән?

Муса акчаны учында сикерткәләде дә атасына кире бирде.

— Бу акча түгел, бу кургаштан эшләнгән тәнкә, патша башы да түгел бу. Күрмисезмени, колагы эчкә баткан, борынына карагыз, шул патшамыни инде...

— Менә шул шул,— диде Мостафа, урыныннан торып китеп,— акча түгел, фәлшифкә. Менә шуны биреп чыгарган бит Җиһангир дуңгыз! Тфү, шуның өчен биш көн бил бөктек бит!

— Ә ничек белдең соң?— дип кыюсыз гына сорап куйды Рәхимә.

— Шул,— диде Мостафа үз-үзеннән гарьләнеп,— кайтышлый Камалый Бакыйга кердем дә ярты кадак шикәр, ярты кадак келәндер үлчәттем. Боларны алып култыкка кыстырдым да акчаны суздым. Теге шайтан-

ның төсе үзгәреп китте. Син, ди, нишлисең, әллә мине чабата сатучы мукшы дип беләсеңме, хәзер үзеңне городовой белән тәрмәгә! Гер белән башка берне тондыра дип торам. Йөгереп Җиһангиргә бардым, анысы сөйләшергә дә теләми, борынын гына җыерып, сез әллә ни уйлап чыгарырсыз, диде дә шартлатып ишеген ябып та куйды. Мин сиңа андый акча бирмәдем, ди.

Габдрахман солдатның күзләре аларып китте, ябык яңаклары күгәреп тагы да өчкә батты, тешләре шыгырдап куйды.

— Кайда ул Җиһангир хәрчевнясы?— Аның тавышы калтырап китте.

Мостафа ваемсыз гына:

— Әнә теге, Урал номерына каршы.

— Әле һаман патша башы белән алдашалар икән. Фронтта без андыйларны! Их, мин аларны... бүгазларыннан,— дип әллә ни сөйләнде дә өстәлдән акчаны гажәп тизлек белән алды һәм ишекне дә япмый тышка чыгып йөгерде.— Һаман патша башы, фронтта да, монда да патша башы белән алдашалар. Агачтан да патша, кургаштан да патша. Вот понимаешь,— дигән тавышны гына ишетеп калдылар.

Өйдәгеләрне бу көтелмәгән хәл тагы да таңга калдырды. Мостафа әле ишеккә, әле түргә бара алмый йөдәде, үзе нигәдер кулларын уа. Муса тиз генә солдат артыннан йөгерде.

Урамдагы кешеләр туктап, солдат йөгергән якка карап гажәпләнеп торалар. Бер карчык:

— Күзләренә караганда, акылдан шашкан бу,— дип куйды.

Икенче хатын:

— Патшаны әрли түгелме соң?— диде.

Өченчесе өстәп:

— Шулай итә, патша башы белән алдаша, ди бит. Төшкән патшаны әрләдең ни дә, әрләмәдең ни? Үз акылында түгелдер инде, мескен.

— Ай бу сугыш, кемнәрне генә нишләтми.

Муса Габдрахман солдат артыннан җитә алмады, аның эзен халык каплады, әллә кайда югалды.

Габдрахман солдат харчевняны тиз тапты. Бусагадан ике генә сикерде дә, харчевняның эченә кереп китте. Ул арада харчевня ишек төбенә солдатны күзәтеп тамаша карарга килгән халык тулды. Ыгы-зыгы башланды. Муса да килеп җитте. Ләкин аны, тыгылып йөрмә әле монда, дип эчкә кертмәделәр. Хәер, зурларның да бөтенесенә керерлек түгел иде.

Габдрахман солдат харчевня эченә кергәч тә, өстәлләрдә ашап-эчеп утыручылар бу сәер кешегә карап катып калдылар.

— Кайда монда Җиһангир чучка?— диде Габдрахман солдат, аның үз тавышы үзен буа, калтырата иде.

Харчевняның ниндидер тәртибеннән риза булмый, официант белән талашып торган бер исерек касса янында басып торган озын ак күлмәк өстеннән утыртма якалы пинжак, башына такыяга да, фәскә дә охшамаган кызыл нәрсә кигән, очлы сакаллы юан гына кешегә бармак белән төртеп күрсәтте һәм:

— Ана тора ул свинья!— диде.

Габдрахман Җиһангирның нәкъ каршысына килеп басты һәм кәзәкиенең якасы аша бугазыннан буып алды.

— Синме бу патша башы белән алдашасың? Бу кургаш патшаны син ясап, халыкны алдап ятасыңмы? Шушы кургашмы синең патшаң? Без анда фронтта кан коябыз. Ә син шушы кургаш патшаң белән кеше алдап погреб казытасыңмы?

Габдрахман Җиһангирның борынына Мостафа өеннән алып чыккан кургаш акча белән бер төртеп алды.

Җиһангир карт солдат кулындагы ясалган акчаны күрү белән гауганың нәрсәдә икәнен бик тиз төшенеп алды һәм тиз генә касса будкасына кереп китте.

— Каравыл! Разбой! Городовой! Кассамны талыйлар!— дип кычкыра башлады.

Харчевнядагы халык аякка басты. Берничә урында тәлинкәләр чылтырап идәнгә төште, утыргычлар ауды. Бер хатынның башына официант ялгыш кайнар аш түгеп җибәрде. Чыр-чу, чәрелдәү китте. Кемнең ни сөйләгәне аңлашылмады. Берәү әче тавыш белән:

— Күземә борыч керде!— дип кычкырып җибәрде. Кайсыберләре, форсаттан файдаланып, ашаганнары өчен түләми качарга ашыктылар. Күпләр, кызык карар өчен, китәргә теләмәделәр. Ул арада халыкны ерып, кылыч таккан ике городовой килеп керде. Габдрахман солдатны тотып алдылар. Җиһангир карт касса будкасыннан килеп чыкты. Бутала-бутала сөйләп китте:

— Менә, господин городовой әфәнделәр, бу фронттан качып кайткан солдат ике көн инде харчевняны саклый, өченче көн кесәсеннән фальшевый акча чыгарып эчәргә сорый, скандал күтәрде. Мин әйтәм, бу көмеш түгел, кургаш, дим, ул әйтә, кургаш патшага кургаш акча да яраган, ди. Как смет итә ул, хәзерге патша урынына калган правительне кургаш патша дип мыскыл итәргә. Ягъни чын патша төште, кургаш патша калды. Янәсе, сез, городовойлар, кургаш патша кешеләре буласыз.

Городовойларның берсе сыбызгы сызгыртып җибәрде. Җиһангир һаман сөйли:

— Менә, әйтсеннәр шулай дип әйтмәде дип. Бөтенесе дә ишеттеләр. Мин үзем шаһит. Үз сүзләремне үзем раслыйм.

Халык арасында шау-шу китте.

— Алай димәде бит ул.

— Кургаш патша, каткан колак, диде.

— Үтерәм мин атаман Дутовны, диде.

— Патшаны да түгел, Дутовны да түгел, харчевня хужасын, Җиһангирны үтерәм, диде бит.

— Җиһангир карт сиңа гына патша бит ул.

— Ә син үзең кемне яклаганыңны бел, тел төбең кая бара синең.

— Закон белән шаярмагыз!

— Сумашедший бит ул, миенә шрапнель ватыгы тигән. Значит дурак! Дуракка закон язылмаган, закон шулай ди.

— Бер дә сумашедший түгел, дөресен әйтә. Җиһангирның үзендә фалшифкә акча бар дип күпләр әйтә. Теге патшаны да, алдады, монысын да алдый ул.

Ул арада тагын бер городовой килеп керде. Монысы юан, киеме дә бик яңа, погоннары да ялтырый иде. Ул ияклэрен селкетеп кенә Җиһангир белән исәнләште. Җиһангир бөтенләй ялтырап китте.

— Ә, Фәттах әфәнде, бик вакытлы килдең,— диде ул аңа,— менә качкын талый язды үземне.

Бу вакытта Муса харчевня эченә керә алмаган кешеләргә эшнең нидә икәнен аңлатып маташа иде.

Городовойлар халыкны ярып Габдрахман солдатны урамга алып чыктылар, аның кулын артка каерып бәйләгәннәр. Атламасаң дип, типкәләп төрткәлиләр, халык арасыннан берәү:

— Моңа бүген кургаш патшаны, катkан колакны таныталар инде,— дип куйды. Икенче берәү Мусага табан ымлап:

— Менә бу малайның сөйләвенә караганда, ике тиенлек тә гаебе юк. Гаеп Җиһангирда,— диде.

— Көчле белән көрәшеп булмый шул.

— Бер дә сумашедший түгел, хаклыкка бара торган солдат. Шундый солдатлар күбрәк булганда...

— Кургаш патша дигәнме, әй!

— Дөрес тә инде.

— Авызыңны җыеп сөйләш. Казаматта урын сиңа да табылыр.

Бик күп халык Габдрахман солдатны һәм городовойларны частька тикле озата бардылар. Халыкны актыктан куып жибәрделәр. Муса посып-посып кына һаман шул тирәдә әйләнде. Частьның аскы катындагы яртысы жиргә баткан, тимер рәшәткәле тәрәзәләргә дә колак салды. Шул тирәдә әллә кемнәрнең ухылдаган, ыңгырашкан тавышлары да ишетелеп калгандай булды.

Мусаны өйдә бик күңелсез каршы алдылар. Мостафа агай башын игән, мич янындагы эскәмиядә утыра. Рәхимә апаның керфек очларында вак кына яшь тамчылары күренә. Мостафа агай башын күтәрми генә:

— Капчыгын карагыз, тентү-мазар килсә, артык-портык нәрсәләре чыкмагае. Үзенә тагы да авырлык килер,— диде.

Капчыкта барлыгы зур гына дүрт сохари, кипкән ярты балык, дүрт шакмак шикәр, авылдан килгән берничә хат иде. Муса хатларның берсен укып чыкты.

«Патша хәзрәтләре, аның балаларының иминлеген саклап, аның, дошманнарына каршы кулына мылтык-кылыч тотып сугышып йөрүче улыбыз Габдрахманга, синең кайтуыңны зар-интизарлык белән көтеп, кала якларыннан килгән кара юллардан күзләребезне алмый көтеп торучы атаң һәм әниеңнән сагынып, бер күрергә зар-интизар булып, саргаеп чуктин-чук, күптин-күп сәламнәрне юллап калабыз». Патша хәзрәтләре урынына калган гыйльман вә вильданнары-санатлары туып-үскән жиренә кайтыр юлларны киң кылсын, дип башлаган бу хатта, ярлылык, фәкыйрьлектән зарлану, авылда өч-дүрт кешенең генә котырып, череп баюыннан башка хәбәр юк иде.

Иң азактан бәет тә язылган:

Қояш баткан яклардан
Алмыйбыз күзебезне.
Таңнар аткач кайтыр дип,
Көтәбез үзегезне.

Муса мәдрәсәгә ватылып, кыерсытылып кайтты. Заһит аны бик шат каршы алды. Муса күңелсез генә:

— Куй әле, Заһит якташ,— диде һәм караватына ауды. Бик озак ятты, кичке ашка да бармады. Заһит ашханәдән аның икмәген алып кайтып бирде. Ләкин Муса алмады:

— Үзең аша, минем тамакка берни дә бармый,— диде.

СИН — ПОЛИТРУК

Безнең өчен һаман
Син — политрук.
Син тезәсең безне бер сафка,
Шигъри казанышлар ранжирында
Иң танылган ирләр — уң якка!

Бу юбилей түгел,— көчне туплау:
— Кайда Фатих Кәрим?— дисең син.—
Кайда безнең батыр Демьян Фәтхи,
Уң флангта күрмим!— дисең син.

Тукай клубына үткән чакта
Мәрмәр исемлектә кемнәр бар —
Һәммәсе дә безнең ирек өчен
Сугышып үлгән Байрон бит алар!

Син әйтәсең: тереләр дә бергә
Бу почетлы безнең сафта,— дип,—
Әйдә, Баттал, син дә кыю атла,
Иҗат күген уяу сакла!— дип.

СИНЕҢ ЯЗМЫШЫҢ

Безнең язмыш күбрәк дус кулында —
Коткарган да, батырган да шул!
Сатса да тик таныш-белеш сата,
Чит кеше бит безне белми ул.

Чын дусларың, Муса, бик кайгырган!
Кайберләре куркып калганнар...
Күңелдәген чыгарудан элек,
Семьяларын уйлап алганнар.

Андыйлардан син югары булдың,
Нинди хәлгә тик төшмәдең син?!
Язмыш атты тирән упкыннарга,
Ләкин бер дә бирешмәдең син!

Туган илне, дусларыңны жүеп,
Алга бардың кырып дошманны,
Күз яшеңне кайчак йота-йота,
Уйладың син тугры дусларны..

Фашистларның йөзенә төкерә алдың,
Көрәш тынмас алар бетмичә.
Зур бәрелештә жиңдең,
Иленә дә,
Дустыңа да хыянәт итмичә!

РОМАШКАЛАР

Ерак түгел моңаеп
Утыра ромашка кызы,
Тик чуклары ак түгел,
Кан шикелле кып-кызыл.

Муса Җәлил.

Ромашкалар, ромашкалар,
Ничә тапкыр керде җырга.
Ромашкалар күңелләрдә,
Ромашкалар үсә кырда.

Ромашкалар ап-ак чуклы,
Ромашкалар кызыл чуклы.
Кызыл чуклы ромашкалар
Хәтерләтә янган утны.

Әйе, кызыл ромашкалар —
Әйтерсең таң шәфәкъләре.
Тамган ана Алиш каны,
Тамган аңа Муса каны.

Кырда үскән ромашкалар
Вакыт үткәч коелалар.
Кызыл чуклы ромашкалар
Мәңгелеккә җыеналар.

Беләсезме! Волхов шәһит —
Анда кызыл ромашкалар!
Кар астыннан чыга да ул
Күтәрелә яз башыннан:

Берәү, икәү, ун, егерме,
Йөз һәм миллион ромашкалар.
Бухенвальдта, Моабитта,
Шпандауда ромашкалар,

Ут шикелле тора янып,
Бирешми ул салкыннарга.
Кар өстендә чәчәк ата,
Яшмый хәтта ялкыннарда.

Кызыл чуклы ромашкалар
Күчә шулай күңелләргә.
Исе китми кар-буранга,
Баш ими ул үлемнәргә.

Ромашкалар, ромашкалар,
Ничә тапкыр керде җырга.
Ромашкалар күңелләрдә,
Ромашкалар үсә кырда.

МӘҢГЕЛЕК ҖЫР

Изгәләр дә таптап шагыйрь җырын,
Атсалар да төбәп йөрәккә,
Ул җыр, илче булып, ирек нурын
Тузан аша илтә ераккa.

Җыр югалмый, ул мәңгегә туган,
Юк азагы аның, юк башы.
Пушкинга да эстафета булган
Билгесез бер җырчы юлдашы.

Җаным өшеп китә үткәннәргә,
Хәтер төер булып буа бик:
Юксына күк аһ-зар Тукайларны,
Җәлилләрне шомлы Моабит.

Әнә палач баскан баш очына,
Зәһәрлесен ата ул укның.
Карга аккан каннан төтен чыга,
Ыңгыраша ташы Машукның.

Палач чаба Фучик-батыр ирне,
Җанын ала шагыйрь-Мусаның.
Шулай да җыр алга өнди җирне,
Канатыннан кагып тузанын.

Тәрҗемә дә кирәк түгел аңа,
Яшәү юлы ачык, нык аның:
Ул халык һәм синең язмышында,
Язмышында азат дөньяның!

Мөхәммәт Садри тәрҗемәсе

СИН УРНАШТЫҢ ДӨНЬЯ КҮКРӘГЕНӘ

Кайдан алды егет мондый көчне,
Кайдан алды мондый ялкынны?

М. Җәлил, «Егет көче».

Мондый көчне болай кайдан алдың?
Кадерлем, син һаман хәтеремдә!
Татарстанны, Россияне, димәк,
Вөжданың күк йөрткәнсең бергә.

Актык көндә исеңә төште Павло[1],
Йөрәгендә, димәк, яшәгән
Украина иле,—
Бөек дуслык белән коткарылган
Газаплардан, уттан, дәһшәттән.

Кайгыдан чал кергән Павло күрде:
Төз атладык дошман явына.
Аның йөрәк тавышы ишетелде
Набат булып Урал ягыннан.

Кырып, мыскыл итеп халыкларны,
Европада дошман йөргәндә,

[1] Павло Тычина — украин шагыйре. М. Җәлил соңгы васыятендә аның исемен телгә ала.

Башкортны дус иткән украинлы,
Ана телен аның өйрәнгән.

Белми киттең, Муса, славяннар
Улы, оныгы, нәселе Павлоның
«Батьківщина» дигән сүз артыннан
Башкортчалап
«Ватан» дигән сүзне язганын.

Бу сүз шулай синең теленда дә,
Аннан олы сүз юк дөньяда:
Ватан-ана! Улы булып әнә
Шагыйрь антлар иткән бит аңа.

Син сугышчы каны тамган гөлне —
Ромашканы иҗат иткәндә,
Яңа Болгария шагыйренең
Саркылгандыр каны идәнгә.

Әйе, Вапцаров ул җәй аенда,
Кырык икенче елда атылган,
Синең кебек чын коммунист булган,—
Баш тартмыйча үлгән антыннан.

Дәртле шагыйрь кайнар, саф күңелдән
Дулкынланып үлем алдында,
Үлемсезлек эшенә ышаныч белән,
Сигез юл җыр язып калдырган.

Бер-берегезне бер дә белми торып
Йөрәкләрегез бергә типкәннәр,
Шигъри көчләр янар таулар булып
Үлемгәчә сезне илткәннәр.

Трубадурлар, бардлар һәм скальдлар —
Сезнең белән иде барысы да:
Сезнең күңелләрдә Бухенвальдлар
Көлгә очты үлем каршында...

Егерменче гасыр шагыйрьләре
Без дәвылда, дауда яшьнәдек,
Халыкара дуслык, туганлыкка —
Зур максатка ышанып яшәдек.

Безнең белән бергә яңа җырлар
Солдат булып барды зур яуга.
Пышылдады безгә соңгы юллар
Нәфрәт сөйләп курку, каушауга.

Утка әверелделәр сүзләрең дә,
Очырып казематлар тузанын...
Син урнаштың дөнья күкрәгенә,
Әй кордашым, дустым, туганым!

Нури Арсланов тәрҗемәсе

МУСА ҖӘЛИЛ

(Трагедиядән өзек)

ҚАТНАШАЛАР:

Муса — шагыйрь.
Илстан — язучы.
Бәкер Хәйруллин — майор.
Гөлгенә — медсестра.
Янгир — башкорт.
Низаметдин — колхозчы.
Сарманбай — чуваш.
Моряк.
Макаров Андрей Павлович — разведчик (Гейдель).
Энгельман — партизан (бельгияле).
Зәбихулла Альбиков — эмигрант.
Эмилия — кызы.
Зоммерфильд — гестапочы.
Берта — аның хатыны.
Бурман — концлагерь һәм төрмә башлыгы.
Розенберг — рейхслейтер.
Сакчы — концлагерьда Бурманның ярдәмчесе.
Каравыл һәм башка каравылчылар.

Вакыйга 1942—1944 елларда Германиядә һәм Берлинда бара.

ДҮРТЕНЧЕ КАРТИНА

Концлагерь. Комендатураның алгы киң бүлмәсе. Каршыда ике якка ачылмалы киң тышкы ишек. Аның бер канатында янә тар бер кечкенә ишек булып, кешеләр шуннан иелә төшеп кергән-чыкканда, тышта каравыл басып торганы күренеп кала. Уң почмакта челтәрле тар тәрәзә аша чәнечкеле тимер чыбык һәм бараклар күренә. Сул як почмакта тимер рәшәткә — пленныйларны вакытлы ябып тору урыны. Цемент идәннәр, дүрт почмаклы, кабер шикелле

авыр, калын чуен капкач; аңа түшәм аша чыгыр белән чылбыр тагылган. Анда уң якта, барьер култыгында, кечерәк гади өстәл, ике йомшак урындык, телефон. Стенада Гитлер рәсеме. Вакыт бик иртә. Урындыкта баш кизү йоклый. Шалтырап тышкы ишек ачылып, Бурман белән каравыл башлыгы керә. Кизү сискәнеп урыныннан тора.

Кизү *(кулын күтәреп бер якка басып)*. Һайль Гитлер!

Бурман. Һайль Гитлер... *(Өстәл артына уза.)* Берлиннан шалтыратмадылармы?

Кизү. Фон Зоммерфильдмы? Әлегә юк, майн обер штурмфюрер!

Бурман. Әлегә юк... Ә кичә качкан кырык кешебез? Нәрсә диярмен мин аңа? Кырык беренчегә мине асыгыз диярменме? Аның утарына кеше җибәрү ничек?

Кизү. Хәзер җыелалар.

Бурман *(боерып)*. Тыңла! Хәзер бер взвод кешене таш күпергә җибәр. Шунда аска төшеп ышыклансыннар, шул эшкә баручы пленнарны бик нык күзәтергә! Качарга итсәләр, шундук камап алып, барын да монда тотып китерергә! Аңладыңмы! Өч мотоцикл алсыннар!

Кизү. Тыңлыйм. *(Чыга.)*

Бурман өстәлдән папка алып бүлмәгә кереп китә. Тышта иртәнге сәгать алтыга кагыла. Тышкы ишек ачылып, иелешеп, Низаметдин, Бәкер, Янгир һәм Илстан тимер рәшәткә ягына кертелә.

Сакчы *(тышкы яктан аларны төрлечә төрткәләп, ашыктыра. Илстанга камчысы белән кизәнеп)*. Я?..

Янгир *(Илстанны авудан тотып калып, үзенең алдына чыгарып, сакчыга)*. Я?

Сакчы. Ах, шулаймы? *(Аңа камчысын күтәрә.)*

Янгир *(кымшанмыйча, өстен тон белән)*. Ошылай. *(Илстанны үз гәүдәсе белән каплап алдан кертә, аннан ашыкмыйча гына үзе керә. Сакчы тыштан басты-*

рык салып, ишеккә камчы белән сугып киткәне ишетелә.) Я ничек, кустым! Төсең бик киткән китүен. Барырлыкмы һоң?

Илстан. Әй, туган, туган. Син мине куй әле. Гумировны әйт. Ул менә исәнме диген?..

Бәкер. Ссс. Тыңлыйк әле... Берни дә ишетмисезме?

Янгир. Монда ташлаган булһалар, бетте. Кая моннан тавыш ишетелү!

Низаметдин. Беләсезме, бу базның икенче хуты бар. Чокыр ягына чыга. Тимер ишек. Биредән ташланган кешеләрнең мәетләрен ул яктан машиналарга төяп, тегендә... *(Кулы белән еракка күрсәтә.)*

Янгир. Туктагыз. *(Икенче ишекне тыңлый.)* Әгәр дә беззе яңадан башка эшкә енап алып китһәләр? Касабыз?

Илстан. Ансыз мин качмыйм.

Бәкер. Гумиров өченме, әллә Гөлгенә өченме?

Илстан. Гөлгенә өчен дә.

Янгир. Гөлгенә тиме? Куй. Бында ниндәй Гөлгенә булһын! Бында ир дә юк, хатын да юк. Бында бер генә төрле кеше бар — плен.

Илстан. Яратам мин аны, башкорт, аңлыйсыңмы, яратам!

Янгир. Ярату тиһеңме? Куй. Бында тәмугның үз уты да еткән, яңадан мәхәббәт уты менән дә яну... Әй, кустым, һин гаҗәп кеше икәнһең! Мин бында үземде үзем дә яратмаем. Мәхәббәт!

Тышкы ишектән бер сакчы кереп үз артыннан Макс Гейдельне кертә. Ул погоннан һәм «СС» знаклардан. Ак чырайлы, калку зәңгәр күзле, кечерәк ак мыеклы, яшь кеше. Бүлмәдән Бурман чыга. Ул барьер эчендә.

Сакчы *(барьер авызында тукталып, доклад бирә)*. Сезгә штабс-капитан Макс Гейдель.

Гейдель *(алга чыгып)*. Һайль Гитлер!

Бурман *(бик тырышып)*. Һайль Гитлер!

Гейдель. Сезгә махсус пакет. *(Тапшыра. Сакчы чыга.)*

Бурман *(ачып)*. Ах, сез Каунастан?

Гейдель. Мин үземнең шефым Зоммерфильдны биредә каршы алырга тиешмен. *(Сәгатенә карап.)* Ул бер сәгать элек Берлиннан очкан булырга тиеш.

Бурман *(каушап)*. Фон Зоммерфильд? Үзе килә-мени? *(Ишектән кертелгән Гөлгенәне, Сарманбайны һәм морякны күреп.)* Ә, э... Күрәсең, без аның утарына эшкә пленныйлар җибәреп ятабыз. Рөхсәт итегез.

Гейдель. А, эшегездән бүленмәгез.

Сакчы *(Бурманга)*. Тугыз кеше китерелде. Берсе карцерда.

Бурман. Чыгарыгыз!

Бурман стенадагы рубильникны моторга тоташтыра. Тимер чыбыклар белән чыгырга тыгылган авыр идән капкачы күтәрелә.

Бурман. Тереме ул?

Сакчы, кесә фонарен кабызып, аска төшеп китә. Арткы пландa әсирләр йөзендә авыр күзәтү. Бераздан авыр аяк, чылбыр тавышлары. Аннан Муса чыга. Аның бер кулбашы тайган, калак сөяге белән тоташ килеш өскә нык күтәрелеп тора. Башта ул берни дә күрми, яктыда күзләре камашып, тирән сулыш ала. Йөзендә авыртулы газап. Артыннан сакчы чыга. Капкач чыгыр белән яңадан ябыла.

Бурман. Ычкындырырга!

Мусаның чылбырлары ычкындырыла, беләгенә тупас кагылудан йөзе тартыла. Гөлгенә Мусадан күзен алмыйча карап торган җиреннән сизми дә калып аңа таба атлап куя.

Бурман *(бер аңа, бер Мусага карап)*. Нәрсә соң аның? Кара үзең!

Гөлгенә *(Мусага, якын ук килеп, аңа тотынып, күзләренә караган хәлдә, ниндидер йомшак, акрын тавыш белән). Имгәттеләр? (Аның сау кулбашына йомшак кына итеп кулын салып, икенче кулы белән авыру белән, иңсәләрен сыйпап, һаман күзләренә карап, йомшак кына тавыш белән.)* Иңбаш сөягегез урынынан тайган. Бирегез миңа учыгызны...

Бурман *(гаҗәпләнеп, барьер янында басып торган Гейдельгә)*. Күрәсезме ул шаманканы? Ырым белән?.. Ә?..

Гөлгенә *(һаман йомшак тавыш белән Мусага)*. Бер генә минутка исегезне җыегыз. Нык басып торыгыз!.. *(Бер кулы белән Мусаның учыннан, икенче кулы белән белгеннән тотып, кулын җәя төшеп, кинәт кенә аска табан арткарак итеп тарта. Мусаның йөзендә газаплы бер җыерылу. Аның кулбашы югары калкып чыгып, әйләнеп кинәт үз табигый хәленә кайта да йөзендә шундук рәхәт җиңеллек балкып чыга. Ул хәтта гаҗәпләнүдән кулын селкеп иңбашын тоткалап карый.)*

Муса *(Гөлгенәгә)*. Мең рәхмәт сине тапкан анага!

Әсирләр йөзендә елмаю. Гөлгенә үз урынына баса.

Бурман *(башын селкеп тора)*. Шушы да армия! Шаманнар! Германиягә каршы сугышчылар! Рәхмәт диегез фрау Берта фон Зоммерфильд сезгә эш биргәнгә! Марш! *(Бар да юнәлә, Бурман арттан барган Мусаны Гейдельгә күрсәтеп.)* Сез карагыз аңа! Карагыз!

Гейдель. Әллә безнең өчен дә кызыгы бармы?

Бурман. Кызык кынамы соң!

Гейдель *(сәгатенә карап)*. Ул чагында мин аның үзенә генә бер өч сорау биреп карарга тиешмен.

Бурман *(бер сакчыга)*. Кайтар җиде йөз дә берне! Группа көтсен! *(Сакчы чыга.)* Рөхсәт итегез, фон Зоммерфильд килүенә мин дә анда кайбер әмерләр бирергә тиешмен.

Гейдель. Рәхим итегез. *(Бурман чыга. Муса кертелеп, ишек ябыла.)*

Гейдель. Сезгә «төн гөле»ннән сәлам.

Муса. Пароль?

Гейдель. Гөлҗимеш.

Муса. Ләкин...

Гейдель *(фуражкасын, пенснесын салып)*. Сез мине хәтерлимсез?

Муса. Андрей Палыч? Хәзер таныдым. Исәнмесез! *(Каранып алып.)* Тиз әйтегез.

Гейдель. Берлинда татарча газета чыгачак. Шуңа болар татар язучыларын җыячаклар. Анда безнең ышанычлы бер кешебез булырга тиеш. Ул кеше — син.

Муса. Дошман органына? Минме? Акылыгыздамы сез?

Гейдель *(җитди)*. Муса! Синең үз инициативаң белән монда шундый кыю эшләр эшләвең иптәшләрне бик шатландырган. Мин сиңа аларның тәкъдимен тапшырдым.

Муса. Һич кабул итә алмыйм. Белегез, Андрей Палыч, безнең шушы китүебез — китү. «Төн гөле»нә миннән сәламемне тапшырыгыз!

Гейдель. Ычкынасыз?.. Ул чагында сүз юк. Хәерле юл! Сез таш күпер ашамы?

Муса. Әйе.

Гейдель. Ул тирәдән саграк үтегез.

Сакчы *(керә)*. Җиде йөз дә бер! Команда кузгала!

Гейдель алып китәргә кулын селки. Муса сакчы белән чыга. Бурман керә.

Бурман *(аның йөзенә карап)*. Бу азиатлар лагеремы? Бу... әгәр дә фон Зоммерфильд биредәге безнең эш шартларын белсә иде...

Гейдель. Сез кадровый офицермы?

Бурман. Унтер штурмфюрер! Унъеллык партстаж! Бу аягым яраланмасамы? Мин инде полковник булган идем. Ә хәзер... җавап бир шушы соры токым өчен!.. Менә сез ул яктан бәхетле кеше дияр идем мин. Гестапоның үзендә. Һәм ул шулай тиеш тә. Мин сезне беренче күрү белән әйттем: менә ул, мин әйтәм, саф арий токымы! Нинди ялт иткән ак чырай! Ә күзләр...

Гейдель. Сез ялгышмыйсыз.

Бурман. Ялгышмыйм. Чөнки мин үзем дә саф канлы немец. Шулай булгач?.. Я әйтегез, минем кебек кешегә Берлинның үз янында концлагерь юкмы? Төрмә юкмы? Сез менә шул хакта фон Зоммерфильдка әйтсәгез иде. Мин бит анда да эшли алам. Әйтик, Моабитта, ә? Югыйсә монда... Болар белән...

Гейдель. Яхшы.

Бурман. Я, менә сөйләштегез, ничек соң шул субъект?

Гейдель. Әллә. Минемчә, ул ниндидер...

Бурман. Юаш?

Гейдель. Мокыт кебек.

Бурман. Сез мокыт дисез, ә ул ниндидер шаман телендә шигырьләр яза, икенче көнне бөтен азиатлар шуны җырлый. Көндез җырлый, төнлә чыбыкны кисә дә *партизанга кача*. Беләсезме, ул, шушы азиат, мине, йөз процентлы арий токымын, борынымнан сөйрәп йөртмәкче була. Ә шулай да без хәзер ул хөрмә төшен ватабыз.

Гейдел. Кызык, ничек ул?

Бурман. Сез хәзер моны үз күзегез белән күрер-

сез! *(Ике ишекне дә киң ача. Каршыда чокыр аша урманлы, томанлы таулар күренә. Бинокль белән карап.)* Әнә алар күпергә керәләр. *(Бинокльне аңа бирә.)* Карагыз. Алар хәзер качарга тиешләр. Әйе, әйе! Шушы номер аларга бүген качу оештырган! Бабакай лагерена! Бер минуттан атыш тавышлары ишетелергә тиеш.

Гейдель. Әһә, сез шуны белеп, анда поскыннар куйдыгыз?

Бурман. Әлбәттә! Минем дә бер эш күрсәтәсем килә. Югыйсә ул монда качулар оештырсын, Бурман аның өчен фон Зоммерфильд алдында җавап бирсен!

Гейдель. Ә шулай да берничәсе качып өлгерсә?

Бурман *(бик каты куркып)*. Сез нәрсә, майн обер штурмфюрер!.. Алар арасында безнең үз кешебез бар!.. *(Атыш тавышлары.)* Әһә! *(Барып рубильникны баса, тревога сиренасы. Тышта эрле-бирле каравыллар күзгә чалына. Мотоцикл киткән тавыш.)* Хәзер унике мең кешене торгызып, мин аларга лагерьдан качуның ни икәнен күрсәтәчәкмен! *(Ераста мотоцикл тавышлары. Бурман тышка йөгерә. Артыннан Гейдель дә чыга. Тышта мотоцикллар килеп туктаган ыгы-зыгы ишетелә. Аннан тышкы тар ишек ачылып, берәм-берәм яралы, тузан-балчыкка буялган Муса, Илстан, Низаметдин, Гөлгенә, Сарманбай һәм моряк тимер рәшәткә ягына кертелә. Сакчының тышкы ишекне ябып, өстән бастырык салуы ишетелә.)*

Муса *(идәндә ыңгырашып яткан Низаметдинның башын күтәреп)*. Низаметдин абзый... Хәлең ничек? Кай җиреңә тиде?

Низаметдин *(ыңгыраша)*. Аркамда... пуля утыра. Гөлгенә хәрендәш... Илстан... Ah, ah! Син дә Гумиров!.. Күрәсең, безгә үз туган җиребезгә чыгу насыйп булмады. Ah, ah!.. Мин беләм, туганнар, болар безгә хәзер бөтен булган явызлыкларын күрсәтәчәкләр. *(Гөлгенәгә.)*

Авылда синең хәтле кызым кала... Фатыйма! Балам! Кем сине карар, кем сиңа кызым дияр?.. Кайта алмадым... Алла! *(Авырткан җирен тотарга тырыша.)*

Муса. Иптәшләр, Бәкер ни хәлдә калды?

Моряк. Ул автоматы белән дамбадан аска ыргылды. Күрәсең, аны...

Сарманбай. Ә песнең башкорт! Ух, очкан кошмыни! Мокаен, урманга читте. Читкә котылды.

Ишек шалтырап ачылып, Бәкерне кертәләр. Аның куллары богаулы, атлаган саен иелеп, аксаган бер аягының тезен тотарга тырыша, ah-ah килеп алга егыла.

Сакчылар чыгып, ишек ябыла.

Муса. Бәкер? Хәзер үзем карыйм аягыңны.

Бәкер. Карамагыз да! Аяк!.. Их, юләр, юләр, ә? Качабыз, имеш, ә кая качабыз?.. Гитлер бүген Сталинградка җиткән! Иртәгә Казанда. Ә без, «дошманны үз җирендә генә кыйныйбыз». Лозунг кычкыручылар! Дөрес итәләр, шул кирәк безгә!

Муса *(ачулы)*. Бәкер!

Бәкер. Нәрсә Бәкер? Мин шуңа ышанган! Мин монда аягыма пуля алыр өчен килмәгән! Әйт, ни өчен мин богауда? Ник сез богаусыз?

Илстан. Тукта, без соңгы сулышыбызда тик шуны беләсебез килә: кем аркасында, ни өчен үләбез? *(Мусаның күзләренә текәлеп карап.)* Муса, әйт! Туры кара да әйт! Кем сатты безне?

Сарманбай. Әкертен!

Бурман, Берта, фон Зоммерфильд һәм ике сакчы керәләр.

Бурман. Күреп рәхәтләнегез. Менә алар!

Берта. Юк, мин иремнән аларга иң каты җәза бирдерүләрен сорармын!

Бурман. Ә сез анда йортта өрлеккә тагылган бауларны күрмисезмени? Тыныч булыгыз, ханым, бу эш өчен сезгә ирегезне борчыйсы юк. *(Сакчыга.)* Сөйлә, кайсы башлап безнең каравылга ташланды?

Сакчы *(Бәкерне күрсәтеп)*. Богаулысы. Мин аңа атыйм дигәнче, янымнан монысы бәрде. *(Низаметдинны күрсәтә.)* Аннан болары. Ярый, шул чак безнең мотоцикллар урап алды. Алардан берәү үлде, берәү качты.

Бурман. Качты? Әле табалмадыгызмы?

Каравыл. Эзләү этләре жибәрдек, майн обер штурмфюрер!

Берта. Майн гот! Минме шул бичара адәмчекләрнең хәленә кермәдем? Минме аларга, ачлар дип, йорт икмәге бирдермәдем? Алар Рәсәйдә шуны күргәнме? Шуңа каршы урманга качалар! Юк, аларга хәләл ризык аш түгел, имение талап, урлап ашарга кирәк! Аларны атыгыз. Монысын да! Монысын да! Ә менә монысын... *(Морякның түшендә татуировка күреп.)* Ах, карагызчы нинди татуировка!

Бурман *(морякка)*. Тор аягыңа, бандит! *(Карап.)* Аждаһа! Кызны кочкан!

Берта. Нинди нечкә эш! Шушы хәтле рәсемне бозарга мөмкинме? Юк, юк, немка буларак моны рөхсәт итә алмыйм. Сез аны атмассыз! Бары асарсыз гына. Аннан бу татуировканы бозмыйча гына алып миңа бирерсез. Беләсезме, бу искиткеч абажур булачак. *(Төлгенәне күреп.)* Ә бу кыз?

Бурман *(исемлектән карый)*. Татарка. Азиат, ә? Уң як өске тешендә коронка! *(Йөзен күтәреп.)* Снайпер!

Берта *(кызыксынып)*. Снайпер?

Бурман. Әйе. Ул, беләсезме... *(Аңа акрын нидер әйтә.)* Ике йөз дә биш белән...

Берта *(гаҗәпләнеп.)* Мәхәббәт? Шушы варварлардамы? Кызык!

Бурман. Хәзер күрерсез. *(Бер каравылга.)* Ач шул капкачны! *(Каравыл рубильникны моторга тоташтыра, идәннең чуен капкачы ачылып бер кырыйга куела. Илстанга карап, боерып.)* Номер ике йөз дә биш! Каравыл Шейникны атып үтерүче! Атла! Баз алдына! *(Аны баз авызына йөзе белән бастыралар.)* Сакчы! Кызның кулына пистолет бирергә! Кызый! Шул торган җиреннән аңа атарга! Тидерә алсаң — син азат! Күрик, син нинди снайпер!

Каравылчы пистолетны алып Гөлгенә янына килә.

Муса *(кинәт каравылның кулыннан пистолетны бәреп төшерә)*. Китәр! Сез нишлисез, вәхшиләр! Үтерәсез икән үтерегез, ләкин кешеләрнең саф хисләреннән көләргә сезнең хакыгыз юк!

Әсирләр. Хакыгыз юк!

Бурман. Хак? Кем сиңнән сорый аны? *(Мусага.)* Алай да син шушы актың белән үзеңнең чын йөзеңне ачтың! Коммунист, политрук, шагыйрь Муса Җәлил! *(Пистолетны ала.)*

Гөлгенә. Юк, бирсен иде ул пистолетны!

Тышкы ишектән Зоммерфильд, Зәбих һәм Гейдель керәләр.

Зоммерфильд. Һайль Гитлер! *(Түргә юнәлә.)*

Бурман. Һайль Гитлер!

Берта. Майн гот! Зоммерфильд! *(Аның муенына ташлана.)*

Зоммерфильд. Һа?.. Минем сөекле хатыным биредә? *(Уза-уза.)* Бу ниткән хаос? Ниткән кәгазь? Йолкышлар?

Бурман. Лагерьдан качучылар. Мин аларны исемлек буенча... *(Кулында кәгазь калтырый.)*

Зоммерфильд. Исемлек? *(Кәгазьне алып, Зәбихкә әйләнеп.)* Ах, әйе, һер Альбикоу! Бәлки, монда

сезнең өчен... *(Исемлекне аңа бирә. Үзе тукталмыйча барьер ышыгына, өстәлгә уза. Зәбих тиз-тиз исемлекне карый.)*

Зоммерфильд *(өстәл янына утырып, Бурманга)*. Бу нәрсә сезнең монда, һер Бурман? Мин сездән сорыйм? Утыр, Берта... *(Урындык күрсәтә.)*

Бурман. Майн һер фон Зоммерфильд. Алар...

Зоммерфильд. Мин аларны сорамыйм, сезне! Сезгә августта күпме задание бирелгән? Күпмесе үтәлгән? Күпме чәч? Күпме теш?.. Ә сез безгә нәрсә тоттырасыз? Качучылар исемлегеме? *(Хатынына йомшак.)* Утар тынычмы? *(Каршында басып торган Гейдельгә.)* Сезнең пакет? *(Аның сузган пакетын ачып ниндидер кәгазьләргә кул куя башлый. Янындагы хатынына йомшак.)* Овчарка тазамы? Йортны яхшы каравыллыймы? *(Кул куя.)*

Берта. Эһе, таза. Ә беләсеңме, безнең теге 12 потлы ата дуңгыз...

Зоммерфильд *(аны тыңламыйча, пакетны Гейдельгә сузып)*. Син хәзер шуны алып мин килгән очкыч белән туп-туры Гиммлер янына очасың.

Гейдель. Эст! *(Пакетны алып чыга. Бар 'да кузгала.)*

Зоммерфильд *(әсирләргә карап)*. Ә бу богаулысы? Башлыкларымы? *(Бәкергә карый.)*

Бурман *(нөктәле итеп)*. Әйе... *(Команда биреп.)* Каравыллар! Алып чыгыгыз үзләрен! Бөтен лагерь торгызылсын! Өченче бырыда асарга! Аннан бу башлыкларын аерым рәвештә башын балта белән бүкәндә чабарга! Марш!

Зәбих *(кәгазе белән килеп)*. Гафу итегез. Биредә жидә йөз дә беренче номер... шагыйрь.

Зоммерфильд. Калдырыгыз аңа ул номерны. Һер Альбикоу бирегә рейхслейтер Розенберг тарафын-

нан, зур полномочие белән. Ул лагерьда йөрер. Үзенә кирәк тапкан кешеләрне, һичсүзсез, аңа бирегез! Ә хәзер... Бүген мин имениебезнең хәле белән танышырга тиешмен. Иртәгә хәтле! Хушыгыз! *(Чыгалар.)*

Бурман. Номер җиде йөз дә бер! Бирегә! *(Мусадан башкалар чыга.)*

Зәбих. Сәламәтмесез, Муса әфәнде. Менә бирегә рәхим итегез, утырыгыз әле.

Муса. Гафу итегез, кем белән сөйләшәм?

Зәбих. Мин Зәбихулла Альбиков булам. Берлиннан. Шунда яшәүче. *(Утыралар.)* Иң элек сезгә ни эш белән килүемне аңлатыйм. Фронт хәлләрен күрәсез. Германия гаскәрләре Кавказга да, Идел-Урал да сугыш кыры булачак. Без — татарлар; мөселман халкын бу һәлакәттән саклап калу безнең милли, дини бурычыбыз. Шул уңай белән без менә, Германиядә яшәүче татарлар, Берлинда бер милли газета чыгарырга уйладык.

Муса. Ягъни, хәрби орган?

Зәбих. Юк, ирекле газета. Ләкин үзегез беләсез, Германиядә безнең каләм әһелләре юк. Сез мине аңлыйсыздыр? Без, Муса әфәнде, сезне, сугыш әсире буларак, шул эшкә катышырга тәкъдим итәбез.

Муса. Туктагыз. Мин сугыш әсире, ләкин мин бит әле совет граждане. Ничек сез миңа безнең белән сугыш хәлендәге Германия матбугатында эшләргә тәкъдим ясый аласыз?

Зәбих. Бу бит хөкүмәт газетасы түгел, үзегез кебек үк хәрби әсирләр матбугаты...

Муса. Сез беләсезме, мин — коммунист!

Зәбих. Муса әфәнде, без сезнең коммунист булганыгызны беләбез...

Муса *(бүлдереп)*. Шулай булгач? Ничек сез...

Зәбих *(торып, стаканга су салып)*. Сабыр итегез,

Муса әфәнде, мин аңлыйм, сез хәзер бик борчулы. *(Алдына су куя.)* Бераз тынычланыгыз. *(Тынып.)* Әле яшь кеше икәнсез. Гаиләгез дә бармы? Балагыз да?.. Ләкин үзегезне бик кыен эшкә дучар иткәнсез. *(Тагын тынып калып.)* Менә шул, Муса әфәнде, бик кызганыч, ләкин үзегез күрәсез: сезнең алдыгызда хәзер бары ике юл: берсе... *(Мусага карый. Тышта бургы уйнала. Муса сискәнә.)* Үзегез ишетәсез. Өченче бургыда сез һәлак булачаксыз. Ә без, шуңа карамастан, сезнең талантыгызга ихтирам йөзеннән эш тәкъдим итәбез. Беләм, сезгә, коммунист мәзһәбендәге кешегә, мондый борылыш ясау бик авыр. Алдан ук әйтәм, сезгә бездә эшләү бик жиңел булмаячак. Менә алдыгызда каләм, менә кәгазь. Мин сезне калдырам. Тик сез ялгыш уйда кала күрмәгез тагы... Юк, Муса әфәнде, без сезне бернигә дә көчләмибез. Ашыкмагыз, һәр ягын уйлагыз, анысынмы сайлыйсыз, монысынмы — бу сезнең үз ихтыярыгыз... *(Чыга.)*

Муса *(ялгыз)*. Нинди кеше ул? Нәрсә әйтте? Ул мине көчләми, бары тик... икәүнең берсен генә сайларга тәкъдим итә. Ләкин бу икенең кайсын гына алып карасаң да, берсе икенчесенә торырлык; берсе — үлем, икенчесе — хыянәт! Я, соң монда миңа сайлап торырлык нәрсә бар? «Мин түгелме шигырь уты белән ант итүче канлы сугышта: үлемгә, дип, ачы нәфрәт белән елмаермын соңгы сулышта!» Я, мин соң аны моңарчы да елмаеп каршы алган кеше түгелмени? Ник бу юлы минем бөтен йөрәк бәгырьләрем шундый ачы бер ут белән әрнеп яна соң?.. Аһ, бу шундый катлы-катлы хыянәтләр корбаны булу! Бу кара тәкъдимнәр... Йөрәгендә шулхәтле үч ялкыны булып та, үзең шушы бер адәм гарибе Гитлер тиранлыгы алдында көчсез калып, аның әмере буенча үлемгә бару? *(Тышта ике мәртәбә бургы.)* Әнә ул әмер! Бу — аның бургысы! *(Тәрәзәдән карый.)* Бөтен лагерь аякта. Әнә ул — өрлеккә тагылган берничә бау... Дар

агачы. Аста басып торган Гөлгенә! Әйе, ул! Нинди пакь, нинди балкый аның йөзе! Палач аның муенына бау төшереп тигезләп карый... Янында ук Илстан! Низаметдин абзый, хәтта Янгир... Ул да китерелгән. Ул да, күрәсең, качалмаган. Уртада бары тик бер генә бау буш тора. Нәрсә ул? Ник бар да шунда борылып карады? Ах, әйе... Аны палач шулай селкетеп җибәрде... Мине көтәләр! Ул — минем бавым! Мин дә хәзер шунда барырга, мин дә шул иптәшләрем янына басарга тиеш. Хуш, Әминәм! Баламны кулларына күтәреп торган Әминәм! «Соң сулышта синең мәхәббәтең җиңеләйтер үлем газабын; Илемне һәм сине сөюемне каным белән җиргә язармын!» *(Атлый.)* Ә бу? *(Өстәлдәге кәгазьгә күзе төшә.)* «Син сүнәрсең, әмма бу якты кояш сүнмәс әле. Ул мөкатдәс, син залимның әмренә күнмәс әле!» *(Ертып ыргыта да ишеккә юнәлә. Кинәт ул чайкала, ава башлый, тотынып калып, артына әйләнеп.)* Ә? Кем ул? Кем ул миңа Муса дип эндәште? Шундый саф итеп, матур итеп эндәште? *(Тирәсенә карый.)* Юк, беркем дә юк. Монда Муса да юк, аңа эндәшүче дә юк. Монда бары Гитлер! *(Рәсемгә күзе төшә.)* Монда ул! Бу аның патшалыгы! Монда бары ул гына бар кешене дә ике төрле һәлакәткә хөкем итә ала. Я хыянәткә, я үлемгә! Хыянәт! *(Маңгай тирен сөртеп.)* Тукта, тукта, Муса. Чапаев та яраланган, соңгы бомбасын да аткан, ләкин бит ул дошман кулында пассив үләргә риза булмаган, суга сикереп төшкән дә Җаекның аръягына йөзәргә тотынган. Ә монда... Монда Гитлер миңа корал тәкъдим итә! Үзе! Соң шулай булгач? Мин бу коралны алырга да үзенә үк төзәргә тиеш түгелме соң?.. Димәк?.. Тукта, тукта! *(Гитлер рәсеменә карап.)* Ул миңа ике юлның берсен тәкъдим итте. Ләкин монда минем өчен әле өченче юл бар.

З ә б и х керә. Ул Мусага астан гына күз ташлап ала да үз юлына барган кебек арткы планда тышкы ишеккә юнәлә.

М у с а. Әфәнде! Мин уйладым. Мин сезгә эшкә барырга риза!

З ә б и х. Риза? Муса әфәнде! *(Килеп кулыннан ала.)* Шулай акылга муафикъ итәрсез дип уйлаган идем. Тәбрик итәм.

М у с а. Ләкин монда язучылар бер мин генә түгел.

З ә б и х. Әйтсәгез лә? Бәлки, сез аларны да безгә күрсәтә алырсыз? Безгә бит мөмкин чаклы... Минем вәкаләтем бик зур. Сез безгә әйтегез генә.

М у с а. Ул чагында... Иң элек сез бу үлем процессын туктатырга тиешсез. Сезгә файдалы кешеләр нәкъ анда.

З ә б и х. Шушы кешеләр? Һә, тыныч булыгыз, Муса әфәнде. Минем вәкаләт кәгазендә рәйхсләйтер Розенберг мөһере... *(Тәрәзәгә бара, аны ача, кесәсеннән яулык чыгарып өч мәртәбә селки. Тышта отбой бырғысы)*. Ишеттегезме, отбой! Шушының белән сез лагерьдан котылдыгыз. *(Чыга.)*

М у с а *(ялгыз)*. Әйе, бер әсирлек бетте, икенчесе башланды. Ләкин монысы тагын да катлаулырак көрәш булачак. Күрик!

Пәрдә

ҖИДЕНЧЕ КАРТИНА

Гестапо. Озынча тар бүлмә. Артта буйдан буйга яшькелт сары төстә стена, анда таррак рамаларда өч рәсем: Гиммлер, Гитлер, Геринг. Каршыдарак ике урындык. Берсе җәза өчен булып, өстендә башка кидерелә торган чуен кыршау, ул артка кайтарылып тора. Шул ук уң як кулда чуал (камин) янып тора. Аннан төшкән кызыл шәүлә стенадагы рәсемнәрне тантаналы янгын өстендә йөздереп күрсәтә. Сул як почмакта, артта Гейдель өстәле. Шул якта шторасы ачылган тәрәзә.

З о м м е р ф и л ь д *(телефонны алып)*. Алло! Гейдель! Миңа җиде йөз дә бернең эшен керт. *(Икенче теле-*

фон шалтырый, алып.) Һайль... Кем? Кем? Ах, фрейлен Эмилия? Хәерле... Ләкин мин мәшгуль. *(Куеп, икенче трубканы ала.)* Эрнест, ни өчен безнең эчке телефонда Эмилия? Кайдан шалтырата ул? Менә шул: мине беркем дә бүлдермәсен! Ә? Кем бу?.. Ах, тагын сез? Мин мәшгуль, Эмилия, аңлыйсызмы, мәшгуль! Биш минутка? Юк, өч минутка да юк! Ике минутка? Төгәл икеме? Ярый, кереп чыгыгыз! *(Трубканы куя. Бу вакыт аның алдында калын папка күтәреп Гейдель басып тора. Зоммерфильд аңа карап.)* Уфф! Бу татаркамы? Көне буе минем телефоннан төшми. Басып керә! Гестапога! Нинди раса бу?..

Гейдель. Интересный кыз... *(Папканы аның алдына куя.)*

Зоммерфильд. Инде интересный түгел. *(Телефонны алып.)* Төрмә! Бурман? Һайль! Җиде йөз дә беренчене миңа китерергә. Җәлил. Әйе, Җәлил! Төрмә! *(Икенче телефон шалтырый, алып.)* Кем тагын... *(Ачылып.)* Ах, Берта, минем кадерлем... Хуш кайттыгыз... Кайчан, яңа гынамы? Я, ничек калды утар? Исәнме? Яхшы. Минем овчаркаларым? Яхшы... Ә, ә? Дуңгызга дисең? Укол җибәрттегезме? Яхшы... Эрик ничек? Эрик дим, малай? Үсә? Ничек, ничек? Песине дисең? Я, я. Кирпеч тагып? Ах, бандит, ә? Ха-ха-ха! Бирегә килергә? Юк, юк. Минем һәр минутым исәпле. *(Ишектән кергән Эмилиягә башы белән ымлап.)* Узыгыз! *(Трубкага.)* Кич... Шалтыратырмын. *(Куя. Гейдельгә.)* Беләсеңме, Эрик — минем малай, нишләгән? Үзебезнең карт песине аскан... Әйе, әйе. Каеш белән муеныннан буган да чөйгә. Песи тыпырчына, үлми. Ул аңа кирпеч тагып. Икене таккан бит! *(Көлә.)* Әмма да бандит! Әмма да бандит! Әле җиде генә яшьтә бит. Утырыгыз, туташ.

Гейдель. Раса?

Зоммерфильд. Ууу... Чын арий токымы малай. Сез сорагыз, ни өчен аса диегез! Песи бит — кара бөдрә.

Шуңа күрә исеме дә Жидовка иде аның. Малай аны:— Ә, син жидовкамы? Бездә жидовкаларны асалар. Әйдә, үзеңне аскылыкка! Я әйт, малайга кем кушкан ул әшне? Кан куша. Үзебезнең кан. Раса! *(Эмилиягә.)* Сез ноль дә житмеш ике буенчамы?

Эмилия. Әйе, сез миңа аның белән күрешергә рөхсәт бирермен дигән идегез.

Соммерфильд. Ә нәрсә өчен?

Эмилия. Беләсез... Мин... Аның язмышы өчен борчылам.

Соммерфильд. Күрәсез, мин мәшгуль. Сез минем кулымны тотасыз.

Эмилия *(акрын, аска карап)*. Билгеле, мин юләр булдым... Сез миннән... Хәзер жирәнәсез. *(Яшен сөртә.)*

Соммерфильд. Калдырыйк. *(Читкә.)* Ах, котырта ул мине шул күз яше белән! *(Аңа)*. Әтиегез ни хәлдә?

Эмилия. Рәхмәт, сау-исән.

Соммерфильд. Менә күрәсез. Без аны артык борчымыйбыз. Төркиягә барып кайтырга да виза бирәбез. Сезгә борчылырга бер урын да юк. Ә ноль дә житмеш ике... *(Тора.)* Беләсезме, мин сезгә нәрсә эшли алам? *(Сәгатен карый.)* Бүген кич сәгать 6 га төрмәгә килегез. Комендатурага. Мин анда булам.

Эмилия. Мин аны күрә алырмынмы?

Соммерфильд. Сез аны... Алырга килерсез.

Эмилия *(урыныннан торып)*. Майн готт!

Соммерфильд. Ә кич сәгать сигездә.... *(Торып аны озата; акрын.)* Биредә булырсыз. *(Эмилия чыга.)* Бу хатын-кызмы? Сөйгәнен коткару өчен, хәтта... Аңламыйм, аңламыйм. *(Өстәлгә килеп, папка өстенә уңын жәеп куеп.)* Бүген жиде йөз дә бергә үлем жәзасы бирергә.

Гейдель. Жиде йөз дә беренчегә?..

З о м м е р ф и л ь д. Һа, ул татарга — күрсәтмә хөкем. Бөтен төрмә алдында. Барабан белән.

Г е й д е л ь. Ләкин бит, ялгышмасам, әле оешмалары табылып та беткәне юк? Ни өчен мондый ашыгычлык?

З о м м е р ф и л ь д. Мин дә әйтәм, Җәлил беркая да китмәс. Ул күптән безнең кулыбызда. Ләкин бит аңардан соң икенче мөселман батальоны да безгә каршы баш күтәрде. Дөрес, бу юлы аларның берсе дә Совет ягына чыга алмады, үзләрен монда ук кырып бетерә алдык. *(Телефон шалтырый.)*

Г е й д е л ь *(алып)*. Әйе. Трубканы бирәм. *(Зоммерфильдка бирә.)* Рейхслейтер Розенберг.

З о м м е р ф и л ь д. Розенберг? *(Каушап, җыйнаклаңып басып, трубканы ала.)* Һайль! Тыңлыйм. Әйе, әйе... Яхшы. *(Трубканы куеп.)* Розенберг бирегә килә. Гиммлерны күрергә. Миңа да кереп чыгачак.

Г е й д е л ь. Сезгә дә? Көнчыгыш Европаның баш министры — үзе?

З о м м е р ф и л ь д. Нигә министр гына. Нацистлар партиясенең башы да ул... *(Иңбашын җыера.)* Нәрсәгә килә икән бу?

Г е й д е л ь. Ни генә булмасын, аның килүе сезнең өчен зур ихтирам.

З о м м е р ф и л ь д. Ихтирамын ихтирам... *(Телефонны алып.)* Эрнест! Фон Розенбергны каршы алырга әзер торыгыз! *(Куеп.)* Кичкә генә алты генералның башын чөйгә бәрдек. Төнлә тагын, ишеткәнсеңдер, өчлекнең утырышы булган.

Г е й д е л ь. Өч «г»нең дисез?

З о м м е р ф и л ь д. Әйе, анда Гитлер, Гиммлер, Геринг, ә монда бүген, исәнмесез, фон Розенберг ашыгыч рәвештә үзе рәхим итә. Шундый хәтәр вакытта. Ярый, хәерле белән килсә? Әгәр дә Гитлер бүген аның да башын шушы кыршауга салырга кушкан булса? Я, нәрсәгә килә

икән ул, нәрсәгә? Син бит анда Герингның ничек тә безнең башка менеп атланырга йөргәнен беләсең. *(Телефон шалтырый, алып.)* Кем китерелде? Җиде йөз дә берме? Кертми торыгыз!.. *(Куеп.)* Йа күкләр! Шул вакыт берсе Җәлилне бирегә кертеп ята! *(Коридорга колак салып.)* Чү! Килде түгелме?

Ишек ачылып китә, Розенберг керә. Гейдель чыга.

Зоммерфильд. Һайль!

Розенберг. Һайль! Гиммлер үзендәме?

Зоммерфильд. Әйе.

Розенберг. Кичә анда бер утырыш булган. Бик тар. *(Портфеленнән кәгазь чыгара.)* Укы.

Зоммерфильд. Стенограмма?

Розенберг. Безгә караган өлеше. Син укы, укы...

Зоммерфильд. *(гаҗәпләнеп).* Ә-ә... нәрсә, ди? *(Укый.)* «...Шунсы гаҗәп, легионны совет ягына чыгаручы группа әле булса исән-сау. Гиммлер кул астында утыра. Башлыклары — коммунист Муса Җәлил дигән кеше хөрмәтле фон Розенбергның җитештергән кадрларыннан берсе...» *(Маңгай тирләрен сөртеп алып.)* Розенбергның!.. *(Дәһшәткә төшеп аңа карый.)* Кем сөйли моны? *(Кәгазьне карап.)* Әйе, Геринг!

Розенберг. Төшенәмсең?

Зоммерфильд. Бик яхшы төшенәм... Бүген ул биредә әйтелгән Муса Җәлилне юк итәргә ашыгыч боерык бирелде. Хәзер бу җилнең кайсы яктан икәне миңа бик яхшы аңлашыла.

Розенберг. Шушы Җәлилнеме? Бүген үтерелергә дисез? Сез нәрсә?..

Зоммерфильд. Ә нәрсә?

Розенберг. Хәзер аны үтерү — бу бит Герингның безгә карата әйткән шушы сүзен раслау дигән сүз булыр иде! Ул бит моны ишеткәч, Гитлер алдында нәрсә

диячәк? Менә күрдегезме, мин әйткәч кенә чыгарып аткан булдылар, ә шуңарчы нәрсә карап торганнар? Шулай диячәкме? Бу бит скандал!

З о м м е р ф и л ь д. Ә нишләргә кушасыз соң?

Р о з е н б е р г. Киресенчә: безгә хәзер ул Җәлилнең үз кешебез икәнен исбат итәргә кирәк. Ул хәзер — мин Совет гражданлыгыннан баш тарттым, дип игълан бирергә тиеш. Минем газетада. Үзенең хаты, үзенең фоторәсемнәре белән. Аңлыйсыңмы?

З о м м е р ф и л ь д *(кузгалмыйча, гаҗәпләнеп)*. Җәлилне баш тарттым дип игълан иттерү?.. Беләсезме, майн рейхслейтер!..

Р о з е н б е р г. Тукта, егетем. *(Кыршауга күрсәтеп.)* Ә соң синең бу үлем кыршавың, 48 сантиметрлы кыршавың нәрсә? Аны беренче башлап дөньяга чыгарган даһи императорыбыз Фридрих Вилһельмме? Ул үзенең дошманы белән ничек эш иткән соң? Яле, акыллым, утырчы шул урындыкка. Күрәсеңдер, менә бу, сиңа, минем баш үлчәвем. Син минем кул астында яшисеңме? Рәхим ит, синең дә башың шушы кыршауга сыярга тиеш инде. Сыймый икән — үзеңә үпкәлә, баш сөягең — чырык! Ул шулай иткән. Һәрбер юньле император үз халкының башын шундый кыршау эчендә тота. Кулыбызда шундый механизм. Ә син нәрсә? Бер бичара әсир кисәген шуңа да күндерә алмыйм дисеңмени? Гестапо!

З о м м е р ф и л ь д. Гафу итегез, сез бит — СССР гражданлыгыннан дисез! Хат яздырып!

Р о з е н б е р г. Хатны без әзерләгәнбез. Менә ул. *(Портфеленнән чыгарып алдына сала.)* Аннан миңа бүген үземнең көнчыгыш бүлегендә ул Җәлилгә бәйләнешле менә шундый бер фото бирделәр. *(Чыгара.)* Семьясы.

З о м м е р ф и л ь д *(карый)*. Уһу... Бу аның хатыны? Кызы белән. Менә бу ярый. Ул, беләсезме, хатыны, бала-

сы турында һич кенә дә тыныч тыңлый алмый. *(Укый.)* Әминә ханым. Сез моны миңа биреп тора аласызмы?

Розенберг. Мин аны сиңа китердем, Фридрих. *(Чыгарга юнәлә.)*

Зоммерфильд. Рейхсфюрерга биредән рәхим итегез. *(Ишекне ача. Розенберг чыга. Зоммерфильд телефонны алып.)* Җиде йөз дә беренчене кертегез. *(Зоммерфильд әзерләнә, пистолетын алдына сала. Муса керә. Ул арестант киемендә. Аның сул кулы хәрәкәтсез булып тәненә ябышкан, йөзендә аркылыга зур яра эзе. Чал чәчле. Рухи хәлләре бары тик тавыш, сүз һәм күзләр аша чагыла.)*

Зоммерфильд. Бирегә узыгыз. Җәлил бит? Чал булгансыз. Әллә начар ук ашаталармы? *(Көлә.)* Ләкин анысына без түгел, үзегезнекеләр гаепле. Икмәкле районнарны бездән кире алып маташалар. Тартырга мөмкин. *(Папканы ача, карандаш ала, рәсми, коры тонга күчеп.)* Шулай итеп, сез Муса Җәлил?

Муса. Алдан ук әйтеп куям, мин сезгә бер җавап та бирмәячәкмен.

Зоммерфильд *(җавап ала)*. Сез — татар? Белеп торыгыз, сезнең һәр дәшмәвегез «әйе» дип язылып барыла! Егерме җиденче елдан коммунист? Концлагерьда сез качулар оештырып, үлемгә хөкем ителгән? Шуңар карамастан, сезгә газетада эшләү мөмкинлеге бирелгән? Сез анда империягә каршы яшерен төркемнәр оештыргансыз? Фюрерга каршы бу сәхифәләрне сез язгансыз? *(Блокнот күрсәтә.)* Бу шигырьләрне сез яздыгыз? Сез мөселман батальонын Совет ягына чыгарга коткы алып бардыгыз? Ә немец коммунистлары белән бәйләнешегез? Барлык бу җинаятьләрегез өчен сезгә былтыр ук үлем җәзасы игълан ителгән; сез укыдым дип кул куйгансыз? Дәшмисез? Ә бүген... *(Өстәл календарен аңа таба борып.)* Бу дата сезгә берни дә аңлатмыймы? Карагыз сез

аңа, хәлиткеч цифр... *(Өстәлгә бармагы белән башта нык, аннан йомшак итеп кагып куя.)* Хәер... *(Торып карандашын ташлабрак җибәреп, бөтенләй йомшак, кешечә тавыш белән.)* Дөресен әйткәндә болар бар да әллә кайчан мәгълүм. Моның өчен генә сезне чакыруның кирәге дә юк... *(Йөреп киткәндәй итә дә шунда ук өстәлгә кире кайта.)* Сезнең хатыныгыз — Әминә ханыммы әле? *(Муса чак кына сискәнеп йөзен күтәрә.)* Эш шунда: ул икенче мәртәбә инде безгә шалтыратып, сезнең белән күрешергә сорый. Билгеле, күрешү өчен бу беркадәр уңайсызрак урын... Аннан соң әле, бу обстановкада үзегез моны теләрсезме?

М у с а. Мөмкин түгел!

З о м м е р ф и л ь д. Мөмкин түгел? Ах, сезгә сөйләмәдеммени әле? Эш моннан гыйбарәт: сез безнең газетада эшләгән булуыгыз белән Россиядә сезнең фамилиягез кара исемлеккә элэккән. Фатирыгыз печатьләнгән. Хатыныгыз баласын алып фронт аша качкан. Ул күптән монда. Берничә кат инде, сезнең белән күрешергә сорый!

М у с а. Ялган!

З о м м е р ф и л ь д. Белмим, бәлки, ул безне алдый торгандыр? *(Тартмадан фотоны чыгарып Мусага күрсәтә.)* Улмы?

М у с а *(торып сузыла)*. Әминә!..

З о м м е р ф и л ь д. Ә юк, шуннан гына карап әйтегез. Бу сезнең хатыныгызмы?

М у с а. Хатыным! Балам!

З о м м е р ф и л ь д *(артыннан укый)*. Чулпан... Матур гына кызчык. Матур. Артындагы бу язу — аныкымы? *(Фотоны аңа бирә.)*

М у с а. Чулпан!.. Балам!.. *(Рәсемне үбеп ике кулы белән кочаклап сыгылып кала.)*

З о м м е р ф и л ь д. Бала. Ир белән хатынга балалы булу нинди бәхет! Үзенең кечкенә тәпиләре белән ничек

атлап йөри ул? Ә? Минем үземнең дә шуның чаклы балам бар. Эрик. Димәк, бу сезнең балагыз? *(Алырга кулын суза.)*

М у с а *(яшьле йөзләрен аңарга күрсәтмәс өчен әйләнеп, рәсемгә карап, пышылдап.)* Әминәм! Бу — син! Чулпаным, бу — син!.. Минем балам! *(Артына карап, укый.)* «Муса. Үзең сораган буенча. Әминәң, 42 нче ел».

З о м м е р ф и л ь д *(көтмәгәндә җиңел бер хәрәкәт белән рәсемне тартып алып)*. Менә шул! Хатыныгыз сезгә шул рәсемне күрсәтергә кушты. Ул хәзер кызыгыз белән биредә. Шушы стена артында утыра. Мин сезне күрештерергә каршы түгел. Тик эшнең бер уңайсыз ягы бар бит. Үзегез күрәсез, сез фюрерга каршы зур җинаятьләрегез өчен үлемгә хөкем ителгән кеше. Шулай да без бу хакта Гиммлер белән сөйләшкәннән соң, ул бер шарт белән сезгә бу күрешүне рөхсәт итәргә мөмкин дип тапты. Моның өчен сезгә Германия подданные булып язылырга кирәк. Әйе, әйе. Менә сезгә кәгазь, каләм. Монысы гаризагызның формасы. *(Алдына Розенбергның калдырган хатын сала.)* Моның тәртибе шулай. Сез нәкъ шунда язылганча күчереп язасыз. Хәзер фотограф рәсемегезне төшереп алыр.

М у с а *(язуны карап)*. Миңа? СССР гражданлыгыннан чыгарга? Шушындый тәкъдим?

З о м м е р ф и л ь д. Ә нишлисез? Сезгә хәзер икенең берсен: я шуңа кул куясыз да хатын-балагыз белән Германиядә рәхәтләнеп яши бирәсез... Яки...

М у с а *(кәгазьгә кулы белән басып, нык)*. Юк!

З о м м е р ф и л ь д. Сез... *(Кнопкаларга баса. Тәрәзәдә штора бердән төшеп ябыла. Мусаның йөзенә көчле прожектор төшә, Зоммерфильд үзе чуалдан төшкән кызыл янгын шәүләсе эчендә кала. Мусаның йөзенә карап.)* Баш тартасыз? Хатын-балагыздан? Шушындый бала-

дан? Ата булып? Димәк? Хатыныгызга без шулай дип әйтергә тиешбез!

Муса. Минем хатыныммы?.. Миннән Ватанга хыянәт сорый торган хатыныммы? Юк! Минем андый хатыным юк!

Зоммерфильд. Ах, азиат! Алга чыгып бас! *(Тартмадан бер пуля алып.)* Бу пуля сезгә билгеләнгән. *(Пистолетын ачып.)* Күзегез белән күреп калыгыз, мин аны кордым. Сез аңа лаек булдыгыз. Атла! Мин «өч» дигәндә, шушы пуля сезнең үҗәт миегез эченә кереп утырган булыр. Әйлән! *(Муса стенага йөзе белән әйләнә.)* Сине хәзер бер генә сүз, бер генә җавап коткара: әлегә хәтле ачылмаган иптәшләрең кемнәр?.. Кутәрәм. Әйтәсеңме? Атарга төзәдем. Саныйм. Бер. Әйт, кемнәр? Ике. Яңадан өч секунд кыйммәтле гомерең калды. Әле син үзеңне коткара аласың. Берсе үтте. Әйт, кемнәр алар? Икенчесе үтте. Әйт! Өч.

Муса *(кинәт йөзе белән әйләнеп)*. Атыгыз!

Зоммерфильд. Ах, кара токым!

Муса. Нәрсәгә бу уен? Күпме мәртәбәләр? Атасыз икән, атыгыз йөземә! Аңлагыз ахырында: мин сезгә үземне кимсетергә, минем белән уйнарга рөхсәт итә алмыйм! Мин сезгә теләсә кем түгел, Совет солдаты. Коммунист.

Зоммерфильд *(ярсып)*. Мин сезне мәҗбүр итәрмен! Мин сезнең башыгызга кыршау салырмын. *(Килеп кыршауны әйләндереп җибәрә. Аякларын тибеп.)* Эндәшмә! Дәшмә!..

Розенберг керә.

Розенберг. Нинди тавыш? Нәрсә бу?.. Ни өчен пистолет?

Зоммерфильд *(Мусага)*. Сезнең белән империя рейхслейтеры Розенберг сөйләшә. *(Розенбергка.)* Җинаятьче Муса Җәлил.

М у с а. Сез Розенберг буласызмы?.. Сез бу нацистларның философымы? Сез аларга шулай минем кебек бер хәрби әсирнең хатынына, баласына булган мәхәббәт хисләре белән уйнарга, шантаж ясарга кушасызмы? Ничек сез...

Р о з е н б е р г. Сез шагыйрь?.. Утырыгыз. Тынычланыгыз. Билгеле, сезнең кебек интеллектуаль бер кешегә полицей методлары куллану бик дөрес булмас иде. Ләкин *сәламәт акыллы булыйк. Фон Зоммерфильдның* сүзендә сезнең өчен бик кыйммәтле бер хакыйкать бар бит... Күрәсез, Русиягә кайту юлы сезгә бикле. Монда да хәзер сезне үлем көтә. Ә без менә сезнең кебек талантлы бер кешене җиңел генә расходка чыгара алмыйбыз. Чөнки без цивилизацияле халык. Без хәтта сезне көчләп булса да, коткарып калырга юл эзлибез, төшенәсездер? Ул да булса алдыгызда, шул кечкенә бер кәгазь... *(Мусага табак этәргәндәй итә.)* Дөрес, ул болай гына, формальность... Ләкин бу инде — яшәү. Сез коммунизм дисезме? Тәгълиматмы? Ә мин әйтәм сезгә: төкерегез! Яшәү шулай коры принцип өчен генә, доктриналар өчен генә башны югалтырлык арзан нәрсәмени?

М у с а. Димәк, сез минем урынымда булсагыз, башыгызны коткару өчен хәзер икенче бер халыкка подданныйлык кабул иткән булыр идегез?

Р о з е н б е р г. Минме? Әлбәттә. Сез бик яхшы беләсез, мин дә бит Руссия подданные... идем. Алай да менә Германиягә чыктым да монда подданный булдым. Начармы иттем? Әле бит шунысын да уйлагыз: Германия хәзер Атлантикадан алып Уралга җиткән бөек бер хәрби держава булу алдында тора. Аны бу юлыннан бернәрсә дә тота алмый. Сез Идел — Кама буеннан бит? Шулай булгач? Сез безнең подданный булуыгыз белән бергә үз илегезне дә югалтмыйсыз, шунда ук булачаксыз. Бәхетегез, сезгә соңгы сәгатьләрегездә юк-бар кәгазь кисәге

бәрабәренә гомер тәкъдим итәләр. Яшәү! Шигырь! Матбугат! Мин белмим, шагыйрь булган кешегә моннан да баш тартырга мөмкинме?.. Хәзер һич икеләнүсез утырыгыз да Гитлер исеменә гаризаны языгыз. Мин сезгә шул киңәшне бирәм.

Муса *(йөзенә елмаю чыга)*. Киңәшегезгә бик рәхмәт, Розенберг әфәнде. Инде рөхсәт итегез, шуңар шөкер йөзеннән мин дә сезгә бик файдалы бер киңәш бирер идем. Сез оккупацияләнгән Руссия җирләренең баш министры дип аталасыз бит.

Розенберг. Шулай аталам.

Муса *(дәвам итеп)*. Аталасыз шул: күрәсез, хәзер көнчыгышта сезнең андый өлкәләрегез бетеп бара инде. Алар бөтенләй дә бетеп, сезгә дә юк җирнең юк министры булып көлкегә калганчы, хәзер үк, һич кичекмәстән, Гитлерга гариза язып, үзегез отставка алып калырга тәкъдим итәм.

Розенберг *(сикерәп торып)*. Ничек? Шушы бер татарчык миннән көләргә җөрьәт итәме? Үзенең шушы хәлендә? *(Зоммерфильдка.)* Мин аны яклый алмыйм! *(Чыгарга юнәлә.)*

Зоммерфильд *(каушауга төшеп, кнопкаларга баса, ике каравыл керә)*. Алыгыз аны! *(Розенбергка ишекне ачып.)* Рәхим итегез.

Чыгалар. Муса каравыл астында чыгарга юнәлгәндә, икенче ишектән Гейдель керә.

Гейдель. Бер генә минутка. Ул допрос протоколына кул куярга тиеш. Калдырып торыгыз! *(Каравыллар кире чыга.)* Иптәш Муса Җәлил!

Муса. Сез?.. Аңлатыгыз!

Гейдель. Катастрофа башланды. Дошманнар ашыга. Синең бар булуың аларга куркыныч.

Муса. Ышана аламмы? Чынмы бу? Син! Минем бу

канлы язмышымның шаһиты. Әйт: халкым мине үзе өчен үлемгә бара икәнемне беләме? Беләчәкме?

Гейдель. Иң элек моның өчен — мин шаһит. Тик, син күрәсең, Муса. *(Стенадагы рәсемнәргә ишарә итеп алып.)* Мин бу үлем җинаятьчеләренең үзләрен кулдан ычкындырмаска куелганмын.

Муса. О, юк! Син шуның белән минем өстемнән бар караңгылык тавын алып ташладың. Рәхмәт сиңа, рәхмәт! *(Кайнар рәвештә кулын кыса.)* Тик... *(Әйләнеп карап алып.)* Тагын бер генә сорау мине борчый...

Гейдель. Хыянәтче турындамы? Мин сиңа нәкъ шул хакта белдерергә ашыга идем. *(Өчкә почмакланган кечкенә кәгазь чыгара.)* Укы.

Муса *(укып, шаккатып)*. Ул?

Гейдель. Бирегез.

Муса. Бу соңгы дәлил миңа! Курыкма, аны миннән беркем дә тартып алмас. *(Яшерә. Аяк тавышлары.)*

Гейдель. Киләләр! *(Ишеккә.)* Каравыллар! *(Каравыллар керә.)* Алыгыз аны! *(Мусаны алып чыгалар. Гейдель аңа караган хәлдә кала.)*

СИГЕЗЕНЧЕ КАРТИНА

Төрмә. Үлем көтүчеләр камерасы. Түрдә тимерле тәрәзә. Алда, сул кулда тимер ишек. Икешәр катлы итеп ясалган урыннар. Вакыт кичкә таба. Пәрдә ачылганда Илстан кечкенә тимер кисәге белән стенаның буявын әрчеп, астыннан язу сызыклары эзли. Янгир ишек күзеннән карый. Бәкер тәрәзәгә йөзе белән утырган, тышны күзәтә.

Илстан *(җырлый, аннан Янгир да килеп аңа кушыла)*:

Без дошманны илдән куып,
Оясын көл итми торып,
Өйгә кайтачак түгел.

Их кызлар, уңган сеңелләр,
Өйгә кайтачак түгел.

Кайтмасак та яныгызга,
Без булсак җырларыгызда,
Шатланыр иде күңел.

Их кызлар, уңган сеңелләр,
Шатланыр иде күңел.

Янгир *(батареяның тимер тарагын чиертеп, музыкаль аккомпанемент бирә. Чиертеп).* Юк, мин Муса кебек сыгаралмам. Ул инде уның остаһы.

Илстан *(кыра).* Юк, нишләп соң әле булса аны кайтармый торалар икән? Мусаны әйтәм.

Янгир *(һаман батареяны тыңлап).* Беләһеңме, теге немец шагыйре Гельмс аның берничә шигырен немецчәгә әйләндергән. Бөтә төрмә хәдер Мусаны ерлай. *(Бәкернең җилкәсенә кул сала.)* Тыңла.

Бәкер. Синдә җыр кайгысы.

Янгир. Ә нәмә?

Бәкер *(һаман тәрәзә аша карый).* Күрмисеңмени?

Янгир. Эшафотнымы? Ярый, кора бирһендәр. Һинең менән минем кебек үлем кешеләренә уның ни аермаһы бар?

Бәкер. Ә син күрмисеңмени? Анда нәрсә беркетәләр?

Янгир. Балта? *(Илстан да алар янына килә.)*

Бәкер. Юк, син шунысын әйт: бүген болар... *(Тын ала.)* Бөтен төрмә күз алдында берәр зур тамаша күрсәтергә җыеналар бит. Кем өчен бу?

Янгир. Әллә Тельманны китерделәр микән?

Бәкер. Тельманны? Юк, кая ул! Ул бит Бауцен төрмәсендә.

Янгир *(тәрәзәдә кош күреп, аяк очында гына шунда ашыга.)* Әй, әй! Карагыз, кош! Әнә, әнә, томшыгы менән рамды сукый. Кызылтүш. *(Бәкергә.)* Һелкенмә, куркытаһың. *(Эндәшеп.)* Йөрәккәйгенәм. Миңа кара, әй матур, әй матур! Бәбкәйгенәм. Карагыз, был теге бер көнге кызылтүш бит? Канатында бер салы да бар. Әй, бу шул бит. Муса аңа шигырь язган. Әй... әнә осып китте. Тәки куркыттың.

Илстан *(яттан укый):*

Син очарсың, бәлки, минем илгә,
Син ирекле, житез канатлы.
Тик әйт, кошчык, синең минем янга
Бу килүең соңгы кабатмы?
Соңгы кабат булса, тыңла, кошчык,
Соң теләген мәгърур жаныңның,
Оч син илгә нәфрәт һәм мәхәббәт
Жыры булып тоткын шагыйрьнең!
Ук шикелле үткен канатыңнан
Таң шикелле якты жырыңнан
Таныр сине халкым,
Бу — дип, аның
Соңгы жыры көрәш кырыннан!

Янгир. Көрәш кырыннан! Һай егетләр, ысыннан да, ниндәй шагыйрь был Муса тигән кеше, ә? Менә һин бүген концертта ошыны һөйлә. Муса алдында. Мин «Биеш»те ерлаем. *(Бәкергә.)* Ә һин?

Бәкер. Нәрсә мин?

Янгир. Һуң? Концертта һиңа лә нәмә лә булһа эшләргә кәрәктер бит?

Бәкер. Йортта эшафот коралар, балта! Ә боларда, беләсезме, үзешчән концерт кайгысы. Юк, аңларга кирәк ахырында. Бу сезгә колхоз клубы түгел. Бу үлем камерасы!

Янгир. Ә без аны колхоз клубы итәбез тиһәк? Нигә *камера булырга тиеш һоң ул? Һин аңла*, концерт бер үк вакытта бөтә кинотеатрларда барасак. Аны Муса үзе оештырган.

Бәкер. Муса шул менә! Шигырь. Имеш, чәчәк. Нинди-дер кошчыклар. Я? Шулмы соң бу Германия?

Илстан (укый):

Синме соң бу — бөек Маркс иле
Һәм давыллы Шиллер ватаны?
Тоткын итеп сиңа китерде дә
«Қол» дип мине немец атады.

Мин күрмәдем синдә кояш нуры,
Баскан аны *канлы тузаның*;
Тик таныдым батыр Тельман яткан
Подвалларның авыр йозагын!

Янгир *(Бәкергә)*. Мусамы? Аның еры Германиянең ете кат ер асларыннан үтеп, гөрләп сыга, ипташ. Ә теге һүзләре? Нисек ти әле?

Чәнечкеле чыбык бәйләсә дә
Мин шагыйрьнең аяк-кулларын,
Бер көч тә юк җирдә богауларлык
Аның кайнар йөрәк моңнарын.

Менә ул — шигырьең көсе. Әйткән дә биргән!

Бәкер. Шагыйрьнең ихтыярын беркем дә богаулый алмый... ә үзләре богауда. Юк, җаннарым! Бу үлем койма-ларын Марксның бөек тәгълиматы да ега алмаган. Бу стеналарны Эрнст Тельман да тишә алмаган. Ә сез — җыр! Шигырь! Җитмәсә ул үзе — татар шигыре! Әнә почмакта пәрәвезгә эләккән чебен, бәлки, ул да үз җыры белән бөтен дөньяга ишетеләм дип безелди торгандыр?

Сезнең җырларыгыз да шул. Пәрәвезгә эләккән чебен безелдәве булып калачак.

Янгир. Ярый, шулай да булһын, ә һин нәмә ошындый юк кына бер себен өсен нерваңнан сыгаһың. *(Ишекне барып карый.)*

Бәкер. Нервтан чыгам! Минме? *(Атлый, тагын тукталый. Кул бармакларын бүлмә җиленә тотып.)* Әллә нәрсә, минем күкрәк аша һаман салкын бер җил исеп торган кебек. Сезгә дә шулаймы? *(Каранып үз-үзенә, йөреп китә.)* Шулмы эш. Шулмы эш!

Янгир *(ишек күзенә карый)*. Нәмә шулмы?

Бәкер. Ә, юк... Мин бу эшафот турында. Йорттагы... *(Атлый, тагын тукталый, үз-үзенә.)* Юк. Нәрсәгә соң миңа бу эшнең ахырына хәтле шаһиты булырга? Чынлап та?..

Илстан *(стенаны әрчегән хәлдә акрын гына җырлый)*:

Күпме михнәт күргән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән,
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызылып-сызылып чыга күңеленнән.

Бәкер *(кинәт)*. Юк! Мин болай сезнең белән яши алмыйм, в конце концов! Икенче камерага күчерсеннәр.

Илстан. Тукта. Син нәрсә?

Бәкер. Нәрсә дип җырлыйсың син? Син партийныймы?

Илстан. Янгир, син ишеттең бит, нәрсә аңладың мин җырлаган җырдан?

Янгир. Нәмә аңланыммы? Элек безнең халык күп михнәт күргән. Ә көй тип әйткән әйбер халык күңеленнән милли хис менән туа. Шуны.

Бәкер. Их, син! Үзеңне эшчемен, Белорецкида биш ел корыч койдым дигән буласың. Милли хис! Без Гитлер

Германиясендә! Монда — раса! Аңладыңмы? Сезнең бу сүзләрегез аның тегермәненә су кою.

Янгир. Кызма әле, кызма. Их һин, штюрмбанфюрер! Әнә анда безнең Кызыл Армия границага етеп килә. Бу да милли хис. Аңлыйсынмы? Ленин әйткән халыксыл милли горурлык! Һин шуны әйт, тизрәк шул Кызыл Армия килһен дә безне был бандиттар кулыннан коткарһын тиген. Менә эш кайда!

Бәкер. Ә мин нәрсә әйтәм соң? Кызыл Армия шул. Ул килеп житсәме? Һи, аннан!.. Мировой революция булачак! Әйе, әйе. Син нәрсә баядан бирле миңа шулай карыйсың? *(Кулы белән үзенең маңгаен тотып карый.)* Юеш...

Янгир. Юеш шул. Карап торам-торам да, юк икән, әй. Нәмә был, аслыктан еңләюеңме тим, бер зә һүзеңдең атай-инәһе юк бит, кустым.

Илстан. «Мин нәсел-нәсәпсез түгел».

Янгир. Һин нәмә?

Илстан *(стенадан укый)*. «Мин милли һәм бер үк вакытта интернационал зур тәжрибәгә ия»...

Бәкер. Ха-ха-ха! Әнә шул стенадан буяу әрчеп, ниндидер немец милләтчеләре язган язудан укып акыл алырга калгач, булмый шул ул. Бу ил — Маркс, Энгельс иле. Бу — беләсең килсә, Тельман иле. Менә сезгә кемнәрдән өйрәнергә кирәк.

Илстан *(ашыгып кыра)*. Тельман... Тель... Әйе. Тельман!

Янгир. Нәмә тиһең? *(Ашыгып килеп укый.)* Эрнст Тельман.

Бәкер. Юкны сөйләмәгез. Кая, кая?

Илстан. Бу — Тельман. Моны ул язган.

Бәкер *(укый)*. Тельман?.. Ялган! Ул бу камерада ятмаган...

Янгир. Хәзер белербез. Укы.

Илстан. Мин монда тәржемә итеп яза бардым.

Янгир. Тсс... *(Ишек шыгырдап ачыла, Муса керә.)* Муса?

Бәкер. Я ничек? Яңа нәрсә бармы?

Муса. Юк.

Янгир. Һаман шул?

Муса. Шул.

Бәкер. Гажәп.

Муса. Ә нәрсә булырга тиеш соң? Кайда, Энгель кайтмадымыни?

Янгир. Һин әйт, без монда нәмә тапмык диген, кил әле. Илстан теге һин башлаган язуны әрсеп сыгарзы бит. Тельманныкы булып чыкты! *(Аны алып килә.)*

Муса. Тельманныкы?.. *(Укый.)* Эрнест Тельман...

Илстан. Әйе. Шуны Алишка тапшырып ятам. Менә тәржемәсе. *(Кәгазьне биреп, шакылдавында дәвам итә.)*

Муса. Нәрсә ди? *(Укый.)* «Мин үзем аңардан булган, минем яраткан халкым немец халкы...» Ә? *(Көлә.)* Менә ул! Фашистлар аны немец халкына хыянәт итте һәм ул үз милләтенең дошманы дип игълан иттеләр. Ә ул, Тельман, менә интернационалист булдым дип үз милләтен дошман күрүче буш бугазларга нинди шәп отпор бирә. Күрсеннәр!

Бәкер *(алып)*. Юк, туктагыз! Ә монысы нәрсә?.. *(Укый.)* «Минем мактанычым булган немец милләте кыю, горур һәм нык торучан милләт!»

Муса. Нигә, Тельман үзе дә шундый нык торучан, горур түгелмени? Бу аның немецлыгы белән бер дә бәйләнмимени? *(Кинәт тәрәзәгә күзе төшеп, бердән артка кагылган кебек.)* Нәрсә ул анда? *(Яңадан тәрәзәгә килә төшеп, тышка карап тора.)* Эшафот! *(Күтәрелеп, берәм-берәм иптәшләренең йөзенә карый.)* Иптәшләр! Тормышыбызның бу иң җаваплы, иң катгый минутында торганда, без дә үзебезнең нинди горур бер халыкның ул-

лары булуыбызны онытмыйк. Безнең дә әби-бабайлар «Сер бирмик ятка!» дип җырлаган бит. Онытмыйк. Халкыбызның иң бөек сыйфаты булган шул түземлек, шул тәвәккәллек, ирлек чишмәсе безнең һәркайсыбызның үз йөрәк тамырыбызда тибә. Илстан, бирче миңа шул газетаның бер читен. *(Аны ертып ала да бер якка утырып, кырыена ашыгып яза башлый.)*

Бәкер. Янгир!

Янгир. Тсс! Ул яза! Һин тәзерәлә тор, мин ишектә. *(Илстанга астан төртә дә икәүләп аяк очына басып кына ишек ягына китеп, анда акрын гына икәү сөйләшәләр. Бәкерне күздә тотып.)* Камерадан күсәм, тиме?

Илстан. Беләсеңме, бая миндә бер шик туды. Аның әйләнгән саен безнең һәр сүздән милли чир эзләп маташуы юри безне провокацияләү өчен түгелме икән?

Янгир. Кеше бик үтә кызыл, үтә уяу булып кыландымы, артында бер эшәкелек көт тә тор.

Илстан *(коридорга колак салып)*. С-с!..

Янгир *(ишек күзләвегеннән карап)*. Юк, бүленмәгез. Үзебезнең Энгельман кайта!

Энгельман кертелә. Утыз яшьләрдә, какча, озын буйлы, Кара чәчле, бик тыйнак, әдәпле кеше.

Муса. Энгель!

Энгельман *(җиңеннән бер төргәк чыгарып аңа суза)*. Сиңа.

Муса. Нәрсә бу? *(Сүтеп карап.)* Син нәрсә, Энгель? Үз икмәгеңне — миңамы? Юк, юк. Рәхмәт. *(Кире суза.)*

Энгельман *(алмыйча)*. Мин бүген тегендә, сезнең Рәсәй хатыннары яткан бараста эшләдем, рамалар куйдым. Синең җырыңны анда да җырлыйлар икән. Моны сиңа андагы аналар җибәрде.

Муса. Аналар... Үзләренә тигән шушы паектан?

Миңа? Ләкин... Ләкин мин хәзер аны ашый алмыйм. *(Уртага сындырып.)* Илстан! *(Аңа суза.)*

И л с т а н. Нишлисең, Муса? *(Аркасы белән әйләнә.)*

М у с а *(Янгиргә)*. Син дә алмыйсың?.. Ул чагында... Юк, сез моны алыгыз. Беләсезме нәрсә? Йөртергә алып чыкканда, моны Алишка күчтәнәч итеп бирергә кирәк.

Я н г и р. Әйе, әйе. Алиш авыру. Был аңа тиеш.

М у с а *(язганын Илстанга биреп, акрын гына)*. Укыгыз да чүп савытына салып озатыгыз... *(Энгельманга.)* Син кил әле, дус кеше, моны кара! *(Стенадагы язуны күрсәтә, Энгельман гаҗәпләнеп укый.)*

И л с т а н *(кәгазьне алып, Янгиргә дә күрсәтеп тотып, акрын гына укый)*. «Русский товарищ. Ты сюда придешь. Я — татарский поэт Муса Джалиль, осужденный к смертной казни за коммунистическую деятельность, в последний час прошу известить моей семье по адресу...» *(Кәгазе кулыннан төшә башлый.)*

Я н г и р *(алып укый)*. Привет товарищам Фадееву, Бахметьеву, а так-же товарищам Татарской организации...» Димәк... *(Каядыр тышта тоныk кына булып сәгать алтыга суга башлый.)*

М у с а. Нигә бик тындыгыз?

И л с т а н. Алты. Камераларда концерт башлана.

М у с а. Ә нәрсә карап торабыз? Без дә башладык. *(Уртага чыга.)* Ипташлэр! Инҗиденче камераның үзешчән концертын башлыйбыз. Беренче номер. Мин хәзер сезгә уземнең бер шигыремне укыйм.

Я н г и р *(кул чапкандай итеп)*. Һорайбыз. Ләкин, Муса, һин шигырьдең шундаен укы, хәтта иптәш Бәкергә дә тәэсир итәрлек булһын.

М у с а. Бәкергә безнең шигырьләр нәрсә аңа? Эш юктан бер эш кенә. Алай да безнең биредә тамашачы аз. Аны да арагызга алыгыз.

Илстан. Уртага, уртага. *(Янгир белән Илстан Бәкерне алга алып киләләр.)*

Бәкер. Менә чудак халык!

Янгир *(кул чапкан булып)*. Публика көтә. Һорайбыз, һорайбыз!

Муса *(Бәкергә туры карый, укый)*. «Кол».

Ул, куркып дошманы алдында
Калтырап күтәрде кулларын.
Сугышның иң кызган чагында
Ташлады кулыннан коралын.

Бәкер сискәнеп күзләрен йөртә һәм акрын гына җыерылып артка-рак ышыклана.

Дошманы сүгенә, җикренә,
Кулларын каерып бәйләде;
Өстенә тау хәтле йөк төяп,
Камчылап тылына әйдәде.
Ул бара. Кан юа җилкәсен.
Камчы һәм дошманы йөгеннән
Шәм кебек төз буе нишләсен?
Көянтә шикелле бөгелгән.

Бәкер исенә килеп тураймакчы була, ләкин инсәсе яңадан җыерыла. Ул һаман чигенә, Муса һаман өстенә бара.

Кешелек сыйфаты бу чакта,
Әйтегез, бармы бу кешедә?
Аягы, куллары һәм хәтта
Җаны да хуҗасы иркендә.
Юк сиңа кешечә көн итү!
Бикләдең син гомер юлыңны!
Дошманың алдында, егетем,
Бер куркып күтәргәч кулыңны.
Я сугыш син яклап халкыңны,
Я сайла кызганыч коллыкны.

Беренче юл — нинди данлыклы,
Икенчесе — нинди хурлыклы!

Бәкер *(әле берсенә, әле икенчесенә карап, кинәт кычкырып җибәрә)*. Ә нигә миңа карыйсыз? Миңа ник шулай карыйсыз?

Муса. Тукта, син нигә кычкырасың?

Янгир. Бик. Муса бит шигырь генә укый. Һин нәмә был?

Бәкер. Ә кем шулай плен төште? Минме? Минме? Кем әйтә?

Илстан. Ә, юк... бу бит шигырь генә... Шигырь әйтә. *(Мусалар култыклашып артка китеп, нидер сөйләшәләр.)*

Бәкер *(артларыннан)*. Ах, шигырь әйтә! Пожалуйста, искусствогызны сәхнәгездә күрсәтегез, ләкин аны үлем камерасында утырган партия членына карата куллану... *(Үз-үзенә.)* Шигырь?.. Чынлап та, нәрсә укыды ул? Әйтерсең ул сүзләр түгел, йөземә ниндидер утлы, трассалы пулялар белән... *(Ишеттереп.)* Шигырьме? Юк! Бәкернең артында совет трибуналы да берни дә таба алмас! Қилер әнә, сугышып алырлар, шунда тотыгыз, ясагыз Бәкергә суд!

Муса *(аның каршысына торып)*. Әйе, суд. Ә син ничек уйладың? Иптәшләр, шушының белән үзебезнең яшерен комитет исеменнән совет судының хөкем мәҗлесен ачык дип игълан итәм. Безнең яшерен оешмабызның уналты әгъзасын һәм шул җөмләдән мине дә гестапога саткан хыянәтче безнең каршыбызда. Бәкер! Ул кеше — син!

Бәкер *(үзе дә сизмәстән кинәт алга атылып)*. Юк, нигә мин? Нигә Илстан түгел? *(Таянычсыз калып, акрын.)* Қайда дәлил?.. *(Қулын суза.)* Дәлил?

Муса. Суд әгъзалары, шушы язучыкны фаш итүе-

гезне үтенәм! *(Өчпочмаклы кәгазьне чыгарып Илстанга бирә.)*

Бәкер. Алдыйсың!.. *(Бердән ташланып кәгазьне сугып алып кулына йомарлый.)*

Янгир. Шаяртма! *(Көрәш башлана. Янгир аның җилкәсеннән эләктереп ала, ләкин кулында Бәкернең халаты гына кала. Бәкер шуып чыгып бер якка атыла. Аларга аркан торып кәгазьне авызына йотам дигәндә Илстан кинәт аның арттан муенына беләген салып ияген артка каера. Бәкернең хәле китеп, бармаклары ачылып, кәгазь идәнгә төшә.)*

Илстан *(кәгазьне укый)*. «Муса Җәлил язган листовканың үз кулы белән тәзәтелгән гранкасын аның матрацы астына куярмын. Сез шуннан тентеп алырсыз. Бәкер Хайфельберг». Бәкер кулы.

Муса *(кәгазьне алып, Бәкергә)*. Димәк, арест булачак төнне минем матрац астына гранканы син салдың? Әйт, хыянәтең кайчан башланды?

Бәкер *(бөкрәеп сәке башына утырган хәлдә.)* Муса... Концлагерьда без асылырга тиеш идек!.. Син безне... *(Калтырана.)*

Муса. Әйе, концлагерьда. Безнең качуыбызны дошманга син ачтың?

Илстан. Гөлгенәне язучы түгел дип Зәбих байга отвод бирүче кем? Аны Крупп заводына коллыкка сатучы кем? Ул да син бит!

Муса. Кара син, кара бу кешенең пакь йөзенә. Таныйсыңмы? *(Илстанны күрсәтә.)* Син аны нишләттең? Совет ягында син аны милләтче дип саттың! Гитлер ягында син аны коммунист дип саттың. Инде безгә тагы үз урыныңа аны ук тоттырмакчы булдың? Нәрсә өчен? Димәк, сиңа властьның кемнеке булуында бер аерма да юк, син тик үзеңә чин алу өчен аларга кеше сатып көн

итүче? Шуның өчен син хәтта иптәшләреңне, халкыңны, ватаныңны да сатучы!

Бәкер *(ятак өстендә почмакка җыерылып кергән хәлдә калка төшеп)*. Халык? Нинди «халык»? Кайда ул? Руссиядәме? Германиядәме? Юк халык! Чыбыркы кемнеке — көтү шунысы. Мин халыкка түгел, директорга хезмәт итәм.

Муса. Шушының белән үзеңнең ватан һәм халык дошманы икәненне үз телеңнән икърар иттең. Бас аягыңа! *(Көчле итеп.)* Тор! *(Бәкер сикереп тора.)* Син барлык бу авыр жинаятьләреңә өчен безнең совет законнары буенча суд тарафыннан атып үтерелергә хөкем ителдең. Кулыбызда ату коралы булмаганлыктан, буып үтерү кулланырга. Карарыбызны кул күтәрү белән раслыйбыз. *(Кул күтәрәләр.)*

Бәкер. Суд? *(Мусага карап.)* Бәлки, син шушындый комедияләр белән үзеңне аклап калырмын дип уйлыйсыңдыр? Юк, Муса, хәзер эш тәмам, син соңга калдың. Мин инде «Муса сатылды» дип, синең турыңда фронт аркылы үзебезнең якка хәбәр жибәрттем. Бу — бер. Икенчесе — берничә минуттан шушы эшафотта, Муса, сиңа хөкем. Калганнарыгызга — төнге сәгать уникедә. Шулай булгач? Монда юкка үлүнең сиңа да, миңа да, беркемгә дә кирәге юк. Ә мин бит әле сезнең хакыгызга да сөйләшеп карый алам.

Муса. Кул куйдырыргамы?

Бәкер. Әйе. Соңгы минутта бу сезгә мин эшли ала торган бердәнбер яхшылык. Юлымнан тотмагыз! *(Ишеккә юнәлә. Каршысында Янгирны күреп, тукталыбрак кала.)*

Янгир. Ах, йоны коелган эт! *(Аны салып жибәрә. Бәкер шыңшып артка барып төшә.)* Тавышынны гына сыгарып кара! *(Муса белән Илстанга.)* Күрденме һин ул ораторны! Менә шулай гестапода аңа бер генә һуккан-

нар. Ул, эт, шундук шыңшып ике кулын берьюлы күтәргән.

Бәкер *(күркып)*. Сез?.. Иптәшләр...

Муса ике простыняның очын бергә бәйләп, йөзен читкә борып, аңа суза.

Бәкер *(дерелдәп, идәндә тезләнеп шуып)*. Муса!.. Атам хакына!.. Син беләсең, ул гражданнар сугышында кулаклар белән сугышып үлде. Ул бит иң фәкыйрь, көтүче Хәйфуллин иде. Мин...

Муса. Әгәр дә син бай улы булсаң, әле син безгә хыянәт итсәң дә үз сыйныфыңа хыянәт итмәгәнсең дип уйларга юл калыр иде. Бөтен бәла дә шунда: син чыгышың белән дә безнең ышанычыбызны алдадың. Син үз карьераң өчен иптәшләреңне дә, иленне дә, халкыңны да, үзеңне дә — барын да сатучы. Җир күтәрмәс пычрак кеше.

Янгир. Әй, үзем генә буаем шул Гитлер көсеген! *(Муса кулыннан простыняны алып өстенә бара.)*

Бәкер *(сәкегә җитеп)*. Кирәкми! *(Аның кулыннан простыняны ала.)* Миңа тотынмагыз! *(Артта тәрәзә тимерена ябышып, тиз генә әйләнеп, өсләренә карап.)* А... Гитлермы? Ул... Җиңелде... Ләкин... Яратмыйм мин сезне! Җыен плебей! Сарыклар! *(Бауны муенына чала. Табуретканы тибеп җибәрә дә асылган килеш кала. Янгир простыняны битенә каплый.)*

Муса. Энгельман! *(Бер ташны кузгатып, кечкенә, кулда төпләнгән бер дәфтәр чыгара.)* Безнең хәлне үзең күрәсең. Минем сиңа бер үтенечем бар.

Энгельман. Әйт, нинди үтенеч?

Муса Шушы бер учка сыярлык дәфтәр. Бу минем гаиләмә, халыкка булган әманәтем. Бүген — бар Муса шушында Аны синең кулыңа тапшырам, сакла. Әгәр дә

син исән калсаң, сугыштан соң, кайсы илдә генә булса да, син аны безнең Совет консуллыгына кертеп тапшыр.

Энгельман. Муса, күпме айлар буена без синең белән ялгыз да, бергә дә бер камерада утырдык! Син бу дәфтәреңне минем алдымда ясадың, минем алдымда яздың. Мин аны укый белмим. Син яхшы шагыйрьме, начармы — аны да мин белмим. Ләкин мин бер генә нәрсәне беләм — *син яхшы кеше*. Явызлар синең рухыңны бервакытта да җиңә алмадылар, үлем дә сине җиңә алмады. Инде бүген син, шундый кеше, миннән нидер эшләргә сорыйсың икән, аны үтәми калу миңа мөмкин түгел. (*Дәфтәрне яшерә.*)

Тышта быргы.

Муса. Бу миңа, Илстан! (*Күзләренә карап.*) Шул эт хакында соңгы вакытта мин хәтта синнән дә, синең кебек кешедән дә сакланырга мәҗбүр булдым. Бәхил бул! (*Коча, үбә.*)

Илстан. Муса!

Муса (*аларның кулларыннан алып, текәлеп Илстанга карап тора.*) Палач балтасы башымны муенымнан аерганда да күзләремдә сезнең кебек яхшы дусларның сурәте китмәсен!

Тыштан Бурман, Зоммерфильд, ике каравыл керә Ишек ачык кала, анда коридорда төенчек күтәргән Эмилия тора.

Бурман. Аякка басыгыз! (*Кулындагы кәгазьгә карап.*) Номер жиде йөз дә бер! (*Мусага туктый.*) Номерыгызны салыгыз! (*Муенындагы номер бляхасын салдырып ала.*) Хөкем җәзасы өчен төрмә йортына чыгарыласыз. Сез әзерме?

Муса. Әзер.

Бурман. Барлык арестантларга да җәза вакытын-

да йортта булырга! *(Кәгазьне карый.)* Номер ноль дә житмеш ике! Төрмәдән чыгарырга. Кайда ул?

Зоммерфильд. Киемнәрен алыштырырга мөмкин. *(Эмилиягә.)* Фрейлен, керегез. *(Ишектән Эмилия керә.)*

Бурман. Кайда ул?

Янгир. Һоңга калдыгыз, майн гер, әнә ул.

Бурман. Ә? *(Мәче кебек менеп, простыняны ачып.)* Бу ни? *(Зоммерфильд алдына килеп честь биреп.)* Номер ноль дә житмеш ике асылган, майн штурмбанфюрер.

Эмилия *(килеп, Бәкерне күреп)*. Бәкер әфәнде! Ах! *(Һушы китә.)*

Зоммерфильд. Төрмәдә кеше асу?.. Ә? Бу ни?

Муса. Бумы? Аңламыйсызмыни? Бу әле безнең халкыбызның бер дошманы Хәйфуллин бүген шулай үзен асты, иртәгә немец халкының һәм башка халыкларның дошманы булган Гитлер да, аның өере булган сез дә шулай берәм-берәм үзегезгә үзегез кул салачаксыз. Әзерләнегез! *(Ишеккә юнәлә. Ишектә бер каравыл аның иңсәсенә кара плащ яба, һәм ул караңгылыкка кереп югала.)*

Пәрдә

БЕРЛИНДА ОКОП

(Поэмадан өзек)

1

— Сау булыгыз, дуслар, — диден, Муса,
Әкрен генә поезд кузгалды.
Калды Казан, киттең син сугышка,
Ерак иде солдат юллары.

Поезд бара, гөрли тәгәрмәчләр,
Күңел ярсый гудок тавышыннан.
Син карыйсың ачык тәрәзәдән,
Туган кырлар уза каршыңнан.

Алтын башын арыш түбән игән,
Чык тамчысы тама йөзеннән.
Уракчылар нигә килми икән
Таң нурлары салган эз белән?

Хәбәр булган кичә игенчегә,
Тимерчегә корал алырга,
Һәм сиңа да, шагыйрь, ут эчендә
Көне-төне алга барырга.

2

Яулык болгый дуслар сезгә, Муса,
Җиңү теләп авыр сугышта.
Ил солдатка үләргә дә куша,
Курку белми соңгы сулышта.

Юл буенда каен озатып кала,
Сезнең поезд узып барганда.
Чыңлап тора кебек зәңгәр һава,
Кош тирбәлә яшел тагында.

Бер күренә таулар, бер елгалар,
Тын авыллар бакча эчендә.
Күпме рәхәт, күпме бәхет монда
Үз Ватанын сөйгән кешегә.

Сүзләр белән әйтеп булмас кебек,
Туган җирдә күпме матурлык!
Шушы җиргә дошман йөрсә кереп,
Үлемнәрдән авыр бу хурлык!

3

Шул турыда син уйлыйсың, Муса,
Мылтыгыңны кысып кулыңа.
Мылтык кына җитми, йөрәгеңне
Нәфрәт белән кирәк корырга.

*
* *

Ә вагонда синең иптәшләрең —
Украинлы, урыс, мордва.
Бергә кушкан алар йөрәкләрен,
Бирешмәскә авыр кайгыга.

Менә берсе гармун алды кулга,
Бар колачка сузып җибәрде.
Күтәрелде дулкын биек ярга,
Исте кебек Идел җилләре.

Менә берсе тагын биеп китте:
— Их-ма!— диде,— төкер кайгыга...
Күнел ача шулай солдат кеше,
Поезд чаба сугыш ягына.

4

Сынау көне килде безгә, Муса,
Турылыкка Ватан-анага,
Мәхәббәтне саклап якын дуска,
Син әзерме утта янарга?

*
* *

Сугыш бара, җирне төтен каплый,
Күпме кабер туплар казыган?
Җир күкрәген сытып танк атлый,
Утлы телен сузып авызыннан.

Синең кулда ике автомат бар:
Яшен ата берсе дошманга,
Икенчесе — каләм — җырлар белән,
Көч бирә ул арган дусларга.

Шушы корал белән шагыйрь кеше
Гомер буе солдат тормышта.
Бомбаларга тиңдәш жырның көче
Ватан өчен барган сугышта.

5

Кинәт җиргә син егылдың, Муса,
Соңгы минут әллә килдеме?
Күкрәгеңнән әллә кан агамы,
Әллә үлән кызыл идеме?

*
* *

Ах, мин беләм, нинди авыр язмыш
Каршылады сине юлыңда.
Андый язмыш инде миңа таныш,
Ул моң эле яши уемда...

Күзләреңне ачып карадың син,
Кем булганын белми тирәндә.
Бер йотым су бары сорадың син,
Иреннәрең янып көйгәндә.

Синең янда инде ятлар иде,
Дошманнарның йөзен күрдең син.
Агу булса, бәлки, эчәр идең.
— Су кирәкми миңа,— дидең син.

6

Син сагындың туган илне, Муса,
Көндезен һәм кара төнендә.
Ул якларда мин дә булган идем,
Авыр сагыш калды гомергә.

*
* *

Ташлы таулар герман җирләрендә,
Кара болыт йөзә күгендә.
Яңгыр ява, исә җилләр генә,
Авыр уйлар синең күңелдә.

Тау артында шаулый куе урман,
Төн шикелле кара бу урман.
Кошлар очмый хәтта бу турыдан,
Курка алар тоткын булудан.

Кеше килсә бире, кайтмый кире,
Җәнлек йөрсә, эзен югалта,
Китерделәр, Муса, шунда сине,
Туган илең калды еракта.

7

Төн караңгы, сиңа авыр, Муса,—
Ай чыкмыймы әллә бу илдә?
Чагылыр иде, бәлки, бер минутка
Туган яклар айның йөзендә.

*
* *

Тимер чыбык белән урап алган
Лагерьда син хәзер бер тоткын.
Күп дусларның бары исеме калган,
Гомерләрен йоткан бу упкын.

Мылтык тотып сакчы мыштым гына
Ияртеп йөри кыргый этләрен.
Гитлер үзе тимер чыбыкларга
Тезеп куйган очлы тешләрен.

Дуслар сүзе сиңа җитмәс инде,
Сине язмыш ерак ташлады.
Таш өстендә тора герман-иле,
Таш астында кеше башлары.

8

Син хурланып көйдең, яндың, Муса,
Яраң тирән, тамды каннарың.
Уйладың син әле пистолетта
Атылмаган пуля калганын.

*
* *

— Ник алдады,— дидең,— пистолетым?
Үкенечкә калды тормышым.
Илем өчен сугыш кырларында
Тынсын иде соңгы сулышым.

Мин кызганмас идем ул көнемне,
Ник тимәгән пуля йөрәккә?
Мин кочаклар идем үлемемне
Анам итеп изге көрәштә.

Калыр идем яшәп шул чагында,
Онытылмыйча туган илемдә.
Йоклар идем Ватан кочагында.
Туган-үскән кырлар иңендә.

9

Син башыңны уйга салдың, Муса,
Ачу белән тулды йөрәген.
Синең алга дошман икмәк куйса,
Икмәгеннән аның җирәндең.

*
* *

— Мин коралсыз,— диден,— ләкин солдат,
Үлми торып тынмас тавышым.
Кулларыма богау салсалар да,
Богау кимәс минем намусым.

Мин антымны бозмам һичбер кайчан,
Сүнгәндә дә яшәү канымда.
Һич үкенмәм, әгәр үлсәм ачтан,
Тик баш имәм палач алдында.

Азык булыр гәүдәм козгыннарга,
Кем дә күрмәс кабер урнымны.
Тик әйтәсем килә күз йомганда:
Кичер, илем, кичер улыңны.

Әнвәр Давыдов

МУСА АБЫЙ

(Повестьтан өзек)

6. КОТЫЛЫРГА, КОТЫЛЫРГА!

Таң атарга бер ярты сәгатьләр калгач, төннең иң караңгы вакытында совет сугышчылары һөҗүм башладылар.

Частьта исән калган бер танк бар иде. Сугышчылар аңа бик каты улый торган сирена ясап куйдылар. Тагын берничә машинага да шундый ук сиреналар куелды. Алар, төнге урманны коточкыч гөрелдәү, улау белән тутырып, немец позицияләренә таба ыргылдылар.

Шул ук вакытта немецлар ягында көчле атыш башланды. Әле кичә генә үз алларында авыр сугышлардан соң бөтен техникасын, күп коралларын һәм иң мөһиме — кеше көчләрен югалткан, һәлакәткә хөкем ителгән бер төркем совет сугышчылары гына бар, дип торган немецлар җиде төн уртасында, көтмәгәндә бу кадәр көчле тавышлар ишетеп, гаҗәпкә калалар. Элек аларның җаннарын тетрәтеп, блиндажларын сытып үткән танклар гаскәре яңадан кайткан дип уйлыйлар. Алар алда да, артта да, уңда да, сулда да, берни аңламыйча, туплардан, миномётлардан, пулемет һәм автоматлардан тәртипсез ут ачалар. Урман буйларында караңгылык пәрдәсен шул утның ялкыннары тапый. Безнең улап барган танк һәм машина-

лар өстендә, алар артыннан килгән пехота өстендә дә ут уйный. Ләкин алар әле һаман алга баралар. Бөтен уңыш шуңа бәйләнгән — немецларны каушатып, позицияләреннән кузгатып буламы? Әллә алар үзләренең өстенә килгән көчнең чынында бик аз булуын аңлап, мәрхәмәтсез ут белән каршы алырлармы?

Часть бу караңгылыкта көчле бер омтылыш белән алга бара. Тизрәк, тизрәк ут божрасыннан чыгарга, дошман коллыгына төшү куркынычыннан котылырга ашыгып, берләшкән бер бөтен организм кебек хәрәкәт итә. Киң табигать кочагында азат яшәргә өйрәнгән кыю җәнлек капкынга эләксә шулай була, аның бөтен мускуллары тартыла, киерелә, тәненең һәр мускулы хәрәкәткә килә, ул җыерыла, сузыла һәм җаны-тәне белән бер омтылышны гына тоя: котылырга, котылырга!

Тукта! Кинәт тирә-яктагы тавышларга, хәрәкәткә ниндидер үзгәреш кергән төсле булып китте. Муса үзенең йөрәгендә хәвеф аша ниндидер бер тантана хисе күтәрелүен тойды. Әйе, алда, һөҗүм юнәлешендә, немецларның ату тавышлары тукталды. Димәк, алар котылачак. Тик ике якта һәм артта гына немецларның һаман шулай тәртипсез, ләкин көчле ату тавышлары ишетелә. Ләкин иң мөһиме алда бит, үзебезнекеләр ягына юл ачыла торган якта.

Менә снарядлар белән сыдырылып, кыйпылып беткән, тырпаеп торган агачлар өстендә күк йөзе сорылана, яктыра, инде тирә-якны күреп була башлый. Муса танкларның немец окопларына барып җитүен, фашистларның алгы линияләрен ташлап качуларын күрә. Тирә-яктан өскә яуган утның әле һаман көчле булуына карамастан, күңел шатлык, өмет белән тула. Әйе, котылу якын, тиздән үзебезнекеләрдә булу һәм бүген совет кешесе рухының бөек көчен күрсәткән менә шушы искиткеч көрәштә катнашу, бу хакта, мондагы кешеләр турында дөньяга сөйли алу

хисе аны канатландыра. Әйе, халкы белән бергә шушылай итеп бөтен дәһшәтне кичкән шагыйрь бәхетле ул. Бер бүгенге төн турында гына да бөтен заманнарның героик *поэзиясенә тиң булырлык ялкынлы* әсәрләр тудырырга мөмкин бит. Муса бөтен көчен шуңа бирәчәк. Ә котылу якын! Безнекеләр якын. Мусаның йөзенә горур елмаю чыга.

Шул вакытта кинәт нәкъ аның алдында зур бер ут шары күренеп китә. Ул алда барган танклар өстендә дә шундый ук ут көлтәсен күргәндәй була. «Юктыр, юктыр, ялгышамдыр...» Бу аның соңгы уе иде. Ул аңын югалтты...

9. ЧӘНЕЧКЕЛЕ ТИМЕР ЧЫБЫК АРТЫНДА

Мусаны, авыр яраларына карамастан, ниндидер бер авылда плендагылар тутырылган сарайга илтеп ташладылар. Монда аңардан тыш та икенче ударный армия фаҗигасен кичергән яралылар юк түгел иде. Ләкин авыр хәлгә — әсирлеккә төшкән совет кешеләре арасында Муса өчен дә җылы, йомшак куллар табылды, кемнәрдер үзләренең эчке күлмәкләрен ертып, аның яраларын юып бәйләделәр, үз авызларыннан өзеп булса да күбрәк ашатырга, аның тәненә яңадан көч кайтарырга тырыштылар. Муса беренче көннәрдә бер саташып, бер аңына килеп ятты. Караңгы сарайның бер почмагында кичләрен янган коптилка яктысы аңа я һәжүм вакытында шартлаган снаряд ялкыны, я битенә үрелергә тырышучы утлы кул булып, яки таң йолдызы Чулпан булып күренде. Чулпан. Бу исем аның аңына әз генә кердеме, Муса каршында *тагын да яңа күренешләр туа. Аңа бу яктылык нәни кызы* Чулпанның зур зәңгәр күзләре булып күренә. Аларда эре-эре ике яшь җемелдәп тора кебек. Ул аның нигә елаганын белми, янында Әминә дә күренми. Кызының күзен-

дәге яшьләр Мусаның бөтен эчен яндыра, сулышын авырайта, иреннәрен киптерә, ул җан ачысы белән ыңгырашып дәшә:

— Әминә... Әминә...

Ләкин, көн арты көн үтә, кешеләрнең тырышлыгы бушка китми — Муса акрынлап аңына килә башлый, ул үзен туганнарча карап, ярдәм итеп, шушы шартларда да үзләренчә тәрбияләп торган кешеләрнең йөзен күрә, аера башлый. Алар арасыннан берсе Мусаның йөзенә бигрәк еш иелә. Муса өчен бу йөз бик якын, бик таныш кебек тоела, ләкин ул аның кем икәнен тиз генә исенә төшерә алмый. Башта ул үзенең туган абыйсы Ибраһим булып күренә, ләкин ул ничектер буйга бераз ускәнрәк сыман, ә кырыкка җиткән кеше ничек үссен ди инде.

Аннан шунысы гажәпләндерә, бу Ибраһим абый татарча дәшкәнгә ни өчендер бер дә жавап бирми, аңламаган төсле карап тора. Ләкин бер-ике көннән инде Муса моның Ибраһим абыйсы түгел икәнен яхшы күрде. Аннан, тырыша-тырыша, кем икәнен дә искә төшерде: сержант Графов! Мусаның йөрәге ниндидер бер өмет уянуыннан ярсып типте, ләкин үзләренең дошман кулында әсирлектә икәннәрен белгәч, ул үзе өчен дә, Графов өчен дә икеләтә әрнеде.

Ул үзенең яраланган, дошман кулына төшкән вакытларын хәтерләргә тырышты, ләкин ул вакыйгаларны һич тәртипкә китерә алмады. Бераздан ул үзенең баш очына сеңелесе Зәйнәп күзе белән карап торган ниндидер малай килеп басканын тойды. Ул аның чынмы, саташумы икәнен аерырга тырышса да, булдыра алмады. Ничектер йөрәккә кереп калган бу образны күз алдына китерә алмаудан аның эче пошты.

Сержант Графовны тану Мусаның аңы ачылуына, рухы ныгуына бик нык ярдәм итте. Ул инде хәзер бер дә саташмый, үзенең яныннан көне-төне китмәгән Графов бе-

лән алар бертуктаусыз сөйләшәләр. Муса икенче ударный кешеләре трагедиясен сержанттан сорашып ахырына кадәр белде. Ул Графовка үзенең башыннан үткәннәрен, *пленга төшүнең никадәр хурлыклы булуын, әз генә аякка баскач та котылу, котылу юлын эзләячәген сөйләде.* Графов үзенең салмак тавышы белән аны тынычландыра да, авыру шагыйрь күңеленең хыялый талпынуларын чын итә торган ныклы фикерләр дә уята иде. Мусаның тәне дә нигый башлады, бик йончыган кыяфәттә булса да, ул аякка басты...

Берничә көннән аларны бу авылдан алып киттеләр. Мусаның иптәшләре аны култыклап, беренче көннәрне сөйрәп үк диярлек, үз урталарында алып бардылар. Башта бер лагерьга, аннан икенчесенә куа-куа, менә, азгамы-күпкәме, Двинск шәһәре яныңдагы лагерьга китереп туктаттылар. Муса инде монда аягына баскан, хәзер үзе башкалар өчен рухи ярдәм бирә алырлык булып ныгыган иде.

Чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган, почмакларына пулеметлар өчен каланчалар ясап куелган йорт дисеңме моны, мәйдан дисеңме — барыбер. Чын исеме аның — коллык! Уртасында түбәләре һәм кечкенә ярым тәрәзәләре җирдән аз гына калкып торган озын-озын подваллар. Алар әлек бәрәңге склады булган. Идәннәрендә пычрак, ватык тәрәзәдән кергән көзге салкын һава подвалдагы сасы юешлекне сөякләргә кадәр үтәрлек итә.

Бераз авырып торганга, Мусаны бүген иптәшләре, лагерь сакчыларыннан үтенеп, өйдә калдырдылар, ә үзләре — кайсы кая — бәрәңге алыргамы, окоп казыргамы куылдылар.

Муса юеш сасы подвалда озак ята алмады, әкрен генә тышка чыкты. Караңгы көзге төн. Болытлар тузгый-тузгый, ертыла-сүтелә түбәнтен генә каядыр агылалар. Сө-

зәк калкулыклар, тапталып, снарядлар белән чокылып беткән иген кырлары, яшелчә җирләре — бар да, бар да моңсу, кыйналган, кимсетелгән кебек. Тик якындагы инде бераз шәрәләнә башлаган урман гына, анда-монда снарядлар белән сыдырылган шәрә кулларын тырпайтып, горур басып тора, үзенең эчендә ниндидер дәһшәтле серләр саклап, кемнедер кисәткән кебек әкрен генә селкенә. Шагыйрь аңа сихерләнгән кебек карый, күңеле шул урман белән бергә кушыла, йөрәге кыю уйлар белән талпына. Ул күкрәгендә нидер кузгалганны тоя, колакта ниндидер моң яңгырый башлый, сүзләр мәгъруранә ритмнарга оешалар:

Урман, урман, мине синнән аера
Чәнечкеле тимер коймалар.
Аерса да тәнне, коллык сөймәс
Мәгърур күңелем өчен юк алар.

Урман, урман, миңа чиксез авыр
Бу хурлыклы түбән әсирлек!
Әйт син миңа, илдәш дусларымны
Кайсы почмагыңа яшердең?

Әйе, Муса күңеле шунда омтыла. Бәлки, тиздән-тиздән бу омтылыш тормышка да ашар. Бүген бик зур мәсьәлә хәл ителергә тиеш. Өзлексез сөйләшеп йөри торгач, алар Графов белән бер карарга килгәннәр һәм шактый көннәр инде моңа хәзерлек тә алып барганнар иде. Алар бер төркем әсирләр белән лагерьдан качарга тиешләр. Менә инде берничә көн буена әсирләрне моннан 3—4 километрдагы басуга бәрәңге алырга йөртәләр. Бу группада Графов та бар. Аларның сакчылары арасында җайлы гына немец табылды. Беркөнне эштән кайтканда, урман турысына җитәрәк, бер-ике минутка туктар өчен, качарга билгеләнгән кешеләр ниндидер сәбәп табарга тиешләр, әнә шул немец аларны саклап кала һәм, колонна ераграк киткәннән соң, тегеләр сакчыны ныклы кына

йтеп бәйлиләр дә урманга качалар. Колонна лагерьга кайтып житеп, артта калганнарны бераз көткәннән соц гына эзләргә чыгалар, алар урман авызына килеп житкәнче, шактый гомер уза, шул арада качкыннар кара урман эченә кереп яшеренергә тиешләр. План бик гади дә, утәрлек тә.

Бүген Графов теге немец белән дә, иптәшләре белән дә барысы турында сөйләшеп, килешеп кайтырга тиеш. Мусаны калдырганда да иптәшләре аның качу өчен бераз хәл алуын күздә тоттылар. Шагыйрь хәзер озакламый үзенең ирек алачагын дулкынланып уйлый, ләкин сузылып киткән озын подвалларга, тирә-яктагы ямансу, кимсетелгән кырларга карап, йөрәге әрнеп кысыла иде. Ул сакчылар күзеннән саклана-саклана күрше баракка юнәлде. Аның ишеге төбендә, корырак җиргә ышыкланып, бер пленный сузылып ыңгырашып ята иде.

Аның чүпрәк урап бәйләгән аягы гөбе кебек шешенгән. Битләре дә, эрен тулы шеш кебек саргаеп, ялтырап торалар. Күзләре әллә нинди сәер сагыш белән ялтыраиллар. Муса бу кешенең татар булуын, фамилиясе Хафизов икәнен ишеткән иде. Аның бүгенге төсе Мусаның башка уйларын оныттырды, ул ашыгып яктаны янына чүгәләде:

— Туганкай, ни булды сиңа?

Хафизов азапланып елмаерга тырышкан булды, ләкин күзләрендәге сәер сагыш һәм йөзенең куркыныч шеше бу елмаюны коточкыч итеп күрсәтте...

— Ачлык...

Муса, ашыгып, иртәгә көч җыяр өчен дип саклаган зур телем ипиен кесәсеннән чыгарды да Хафизовка сузды, аны кочаклап утырды.

— Аша, туган.

Бу куркыныч күренеш Муса күңелендә әсирлеккә тагын да каты нәфрәт, иреккә омтылу хисе уятты, ләкин

инде иртәгә моннан котылачагы турындагы уе аның йөрәген саф шатлык белән тәлпындырмады, ул бу хакта уйлап алганда никтер оялган кебек кызарып куйды...

10. ШАГЫЙРЬ УРЫНЫ КАЙДА?

Әмма бүгенге кич барыбер яхшы хәбәрләр алып килде. Графов эштән кайтты, иптәшләр белән дә, немец белән дә сөйләшүнең бик уңышлы булуын әйтте. Иртәгә бар да алдан уйлап куелганча эшләнәчәк. Муса ирекле булып, кара урман кочагына ташланачак. Ирек!

Юк, барсыннан да элек
Тик булса иде ирек,
Кылычым булса кынымда,
Карабиным кулымда,
Сине саклап, туган җирем,
Мин ирләрчә үләр идем
Данлы сугыш кырында.

Графов, татар телен аңламаса да, Мусаның илһам белән пышылдап сөйләгән шигырендә зур көч тойды. Ул аңа аталарча сокланып карады. Аннан аның йөзенә моңсулык чыкты:

— Муса, — диде ул әкрен генә, — иртәгә син безнең иптәшләрне иреккә алып китәрсең. Син аларны үзебезнекеләргә алып чыгарсың. Сез тагын Ватан өчен көрәшчеләр сафына басарсыз... Бәлки, яңадан минем туган Ленинградым өчен сугышырга туры килер. Рәхмәт сезгә, алдан ук рәхмәт әйтеп куям... Сина үтенечем, Муса: сугыш беткәч, Ленинградка кил, Васильевский островта ике катлы йортның бишенче квартирасын эзләп тап. Бәлки, мин сина каршы чыгармын, ә чыкмасам... син барысын да, барысын да сөйлә, Муса, яме?

Муса аптырап Графовның күзенә карады. Ул күзләрдә дым аша тантана чаткысы ялтырый иде. Муса кинәт аңлап алды:

— Сез... сез, Василий Михайлович...

— Әйе, мин сезнең белән китә алмыйм, Муса. Әнә Николай да тагын авырып кайтты, аны кем карар? Аннан мин карт кеше инде, үзебезнекеләргә кадәр барып җитәргә көчем дә җитмәс.

— Юк, бу мөмкин түгел.

Муса аркасына әйләнеп ятты да, түбәгә күзен төбәп, тынып калды. Ләкин Графов бу тынлыкның тыштан гына булуын, Мусаның эчендә океан дулкыннары кебек көчле хис кайнавын, аның уйлары давыл кебек айкалуын сизде.

— Борчылма, Муса, бар да сөйләшенгән. Ял ит. Сиңа көчле булырга кирәк. Син — коммунист, син группаның җитәкчесе булачак кеше.

Муса, җавап бирмичә, бер хәрәкәтсез ятуында дәвам итте. Аның башына, дөньяда тиңе булмаган тизлек белән, төрле уйлар килә. Менә ул иртәгә иптәшләре белән лагерьдан качты һәм үзебезнекеләр ягына уңышлы гына чыгып җитте, ди. Әлбәттә, аны шатланып каршы алырлар, бәлки, бүләкләрләр дә. (Муса ни өчендер соңгысын уйлаганда ирония белән елмаеп куйды...) Аннан ул, редакциясенә кайтып, тагын фронтка ашкыныр. Әлбәттә, ул үз бурычын намус белән үтәр, сугышларда катнашып, дошманнан үч алыр.

Ләкин гаҗәп, хәзер аңар бу бәхет ничектер тулы булмас кебек күренде. Менә шушы сасы подвалларда үзләренең кешелек дәрәҗәләрен саклап калырга тырышучы, көн саен явыз дошман тарафыннан хайваннарча кимсетелеп торучы меңләгән кешеләрне уйлаганда, шагыйрь күңеле иректә үзен бәхетле тоярмы?

Үзең иреккә чыгып, бу кешеләрнең кайгы-хәсрәтен, омтылышларын язарга мөмкин, әлбәттә. Бу табигый дә булыр иде. Ләкин Муса күңеле моның белән килешә алырмы? Җаның-тәнең, уең-җырың белән шушы кешеләр янында ахырына кадәр булу, аларның бөтен газапларын уртаклашу, аларның кешелек хисләрен саклап калу гына түгел, җыр белән канатландыру, дошманга каршы күзгә-күз торып, кешелек өчен рәхимсез көрәшкә оештыру — шагыйрь һәм коммунист эше шушы түгел микән?

Ашкына уйлар, ташый уйлар.

Ярты төндә Муса Графовны уятты:

— Василий Михайлович, Василий Михайлович, уяныгыз. Бик тиз киңәшергә кирәк. Ишетәсезме, мин иртәгә китә алмыйм.

Графов башта ни әйтергә дә белмәде.

— Шаярмагыз, Муса,— диде ул. — Сез — коммунист. Заданиене үтәргә тиешсез. Аннан соң, шагыйрь, сез халкыгыз белән булырга тиеш.

— Әйе, мин коммунист һәм шагыйрь. Шуның өчен дә мин китә алмыйм. Монда да минем халкым, халкымның иң авырткан, иң әрнешле урыны монда. Василий Михайлович, ачык әйтәм: мин китмим. Минем урынга Диманы билгеләргә кирәк. Ул коммунист, аннан сугышчан командир. Ул бу бурычны бик шәп итеп үтәр.

Муса тынды. Графов та бер сүз дәшми торды. Аннан Мусага таба борылды да аны кысып кочаклады. Урыныннан торып китте. Берәр сәгать үткәннән соң гына кире килеп ятты. Мусаның да һаман йокламавын күреп, Графов аның кулын алып кысты:

— Дима риза, — диде.

Алар икесе дә шулай иртәнгә кадәр йокыга китә алмый яттылар...

Ныклы карарга килү Мусаның көчен арттырды, ул алдагы көндә хәлсезләнебрәк торуына, төнне йокысыз

уздыруына карамастан, иртән урынныннан җитез кузгалды, башкалар белән бергә эшкә китте. Бәрәңге казыган җирдә бүген качарга тиешле кешеләр белән үзе тагын бер кат сөйләшеп чыкты.

Бик гади һәм беркатлы уйланган план төп-төгәл итеп, шоп-шома итеп үтәлде. Бәйләп калдырылган сакчыны табып, этләр өрдереп, шау-шу килеп, ярты төнгә кадәр эзләгәннән соң тирә-яктан беркемне дә таба алмагач, немецлар резин таяклар белән кыйный-кыйный кешеләрне подваллардан куып чыгардылар, аларның борын төпләрендә йодрыклар уйната-уйната, тагын кыйный-кыйный, санап чыктылар. Биш кешенең качканы беленде. Аннан кыйный-кыйный тагын подвалларга кудылар. Урыннарга яткач та әле кешеләр өстендә резин таяклар уйнап торды. Аска җәйгән саламнарга борыннардан, биттәге яралардан кан тамды. Ә кешеләр мәгъруранә тынлык сакладылар. Биш иптәшнең хәзер кайдадыр иректә, туган ил табигате кочагында, үзебезнекеләргә, чын азатлыкка таба ашыгып баруларын күз алдына китерү аларга көч бирә иде.

Икенче көнне кичен Муса тагын Хафизов янына килде һәм аңа бер телем ипи төртте. Яралының шешенүе кайтмаган булса да, күз карашы жанланган иде. Муса аның белән озак сөйләшеп утырды, шигырьләрен укыды. Йөрәкне әрнетә дә, җилкендерә дә торган дөрес сүзле көчле шигырьләр Хафизовны таң калдырды.

— Нинди әйбәт шигырьләр бу, иптәш Гумеров? Каян алдыгыз?

— Бу, Гариф, минем үз шигырьләрем, татар шагыйре Муса Җәлил бит мин, ләкин мин үземне Гумеров дип йөртәм. Моны беркемгә дә әйтмә, бик нык ышанганга гына сиңа серемне ачтым.

Беркөнне Муса озынча шадра йөзле, хәйләкәр соры күзле, гел шаярырга ярата торган Хөсәенов дигән пле-

ный белән танышты. Шулай итеп, аның дуслары — күңел таянычлары һаман арта барды.

Кичләрен Муса лагерьның төрле почмакларында күренә. Бер җирдә татар пленныйлары арасында шигырьләр укый, икенче урында русча сөйләшә. Әкренләп кешеләр аңа аерым бер игътибар белән карый башлыйлар. Ул да аларның уйларын, омтылышларын күбрәк белә, туплый бара һәм, ниндидер зур эшкә хәзерләнгән кебек, барын да күңеленә җыя иде. Кинәт Мусаның башына яңа бәла, яңа хәсрәт килде. Аның якын дусы, киңәшчесе, Ленинград эшчесе сержант Графов, лагерь тормышының авырлыгына түзә алмыйча, йөрәк авыруыннан үлде.

11. АХТУНГ, МУСА ҖӘЛИЛОВ КАЙДА?

Җил улап торган көзге көннәр... Күктә калын-калын алама болытлар бертуктаусыз агып торалар. Кайчагында аларның бер җирендәге сәләмәләре җиргә сөйрәлеп үтә — вак-вак яңгыр сибәли. Шундый бер иртәне, эшкә куар алдыннан, бөтен пленныйларны лагерь уртасына тезделәр. Лагерь начальнигы, офицерлар килде...

Зур зәңгәр күзле, кылыч борынлы, сары чәчле, урта яшьләрдәге купшы офицер башта немец гаскәрләренең бөек бурыч үтәүләре, гуманизм һәм тагын нәрсәләрдер турында буталчык кына речь тотты, тәрҗемәче аны тагын да буталчыграк итеп аңлатырга маташты, ләкин сүзләреннән бернәрсә ачык сизелә иде: немецларга буйсынырга, кол булып хезмәт итәргә теләмәгән кешене алда газаплар һәм үлем генә көтә. Аннан бераз пауза ясады да офицер:

— Ахтунг! — дип кычкырды.

— Ахтунг! Пленный Муса Җәлилов, өч адым алга!

Муса моны һич көтмәгән, уйламаган иде. Шуңа күрә ул кинәт талпынып куйды, алга чыгып басудан көчкә

тынлып калды. Тәне буйлап әллә нинди салкын йөгерде, йөрәге туктап калгандай булды. Бу ни дигән сүз? Аның монда икәнен кем әйткән? Лагерьда 2—3 кенә кеше аның татар шагыйре Муса Җәлил икәнен белә. Шулай ук аларның берәрсе сатлык җан микәнни?

Немец офицеры озак кына көтеп торганнан соң тагын кычкырды:

— Ахтунг! Муса Җәлиловны күргән-белгән кешеләр ике адым алга! — Мусаның йөрәге еш-еш тибә башлады, тамак төбенә ниндидер төер килеп тыгылды, сулышы кысылды: «Кем алга чыгар икән? Сатлык җаннар табылырмы?» Аның киләчәктә эшләячәк эшләренә өмете, хыяллары шуңа бәйләнгән. Йөрәк бөтен лагерьга ишетелерлек итеп кага. Менә шул вакыт сузылып киткән тигез сафларның алдына бер пленный чыгып басты. Бар икән сатлык җаннар! — дип уйлады Муса. Тукта, кем соң ул? Хөсәенов түгелме? Гел иптәшләренең күңелен күтәрергә тырыша торган, кешегә игътибарлы булып күренгән, Мусаның шигырьләрен яратып тыңлаган Хөсәеновмы? Тыштан гына шундый булып кыланды микәнни, эчтән пычрак җан булганмы?

Немец офицеры соңгы команданың да үтәлүен көтмәгән, күрәсең, башта бер сүз дә әйтә алмый торды. Аннан Хөсәеновка якынрак килеп сорады:

— Димәк, сез Муса Җәлиловны таныйсыз?

— Бик яхшы таныйм, герр офицер.

— Сез аның кем икәнлеген дә беләсезме?

— Беләм, бик яхшы беләм.

— Әйтегез әле, кем ул?

— Ул, герр офицер, коммунист.

Мусаның йөрәген ачыну хисе әрнетеп үтте. Чынлап та алданган икән ул.

Офицер җанланып китте һәм Хөсәеновка тагын да якынрак килде:

— Коммунист?

— Әйе, коммунист, карт коммунист ул.

— Әһә, тагын, тагын кем?

— Карт коммунист, безнең «Яңа тормыш» колхозының сыйфат инспекторы булып эшли ул, герр офицер.

Муса гажәпләнергә дә, шатланырга да, сокланырга да белмәде. Әсирләр сафында чак кына сизелерлек хәрәкәт дулкыны үтте, йөзләргә яшерен елмаю чыкты.

Офицер бу хәйләкәр күзле шадра татарның үзен мыскыл итүен аңлый башлады, аның йөзе кызарды, күзләре канланды, ләкин әле ул нәрсәгәдер өметләнә иде һәм бераз тынлыктан соң үзенең хәлиткеч соравын бирде:

— Ә хәзер, хәзер кая соң ул?

Сафлар катып калды. Муса, тынын да алмый, яңадан көтә башлады. Ә Хөсәенов бу юлы җавап бирергә ашыкмый, тирә-ягына каранып куя. Бу — офицерны тагын да өметләндерә:

— Я, хәзер кая соң ул?

Хөсәенов тагын бераз дәшми торды да:

— Минемчә, — диде әкрен генә, — хәзер ул... үзләренең өйләрендә, мич башында ятарга тиеш, ник дисәң, аның аягында ревматизм, мондый яңгырлы көннәрне ул...

Сафларда шаулап көлгән тавыш ишетелде.

Офицерның күзләре атылып чыгардай булды. Матур йөзе бер секунд эчендә ерткыч җәнлек танавы булып үзгәрде. Ул, бик каты кизәнеп, Хөсәеновны сугып екты, котырынып типкәләргә тотынды, аңа ярдәмгә унтер-офицерлар ташланды.

Лагерь начальнигының ачы тавышы яңгырап китте. Ул әсирләрне эшкә куа иде. Сакчылар әсирләргә резин таяк белән кундыра-кундыра аларны куып алып киттеләр.

Кыйналуга, авыртуга да карамастан, кайберәүләр һаман көлүдән тыела алмыйлар иде әле. Моңа кадәр Муса-

га бик начар күз белән карап йөргән бер унтер-офицер хәзер резин таяк белән суга-суга:

— Гумеров, ашык, шнелль, шнелль! — дип, аның янында акырынып бара. Муса көлми дә, әмма кыйналуны да артык тоймый кебек. Ул бик дулкынланган, бу дулкынлану аның уйларын әллә кая алып киткән иде. «Кешеләр нинди матур жанлы! Шушы бараклар сазлыгында күпме рухи көч тоткында ята. Күтәрергә, күтәрергә аларны. Моңардан да изгерәк бурыч бармы?..»

Берничә көн узгач, Мусаны бу лагерьдан алып киттеләр. Соңгы вакыйгадан ул үзенең пленда икәнен немецларның белүе һәм, ни өчендер, аларның шагыйрьне табарга тырышуларын сизеп алды. Ләкин хәзер аны бу хәл һич куркытмый иде. Нинди юллар белән булса да, дошман белән көрәшне дәвам итү турында көне-төне уйланды. Баштарак, туган ил территориясенә урнашкан лагерьларда яшәгән вакытында, ул болайрак уйлый иде: мөмкин кадәр күбрәк әсирләрнең — кимендә бер бөтен лагерьның баш күтәрүен, коралланuын оештырырга да я партизаннарга кушылырга, я сугыша-сугыша үзебезнекеләр ягына таба хәрәкәт итәргә. Ләкин бу эшне башлап жибәрү өчен дуслар, ышанычлы кешеләрне туплый гына башлауга, аны икенче лагерьга күчерәләр, Ватаннан һаман ераккарак, дошман өненең эченә табарак алып китәләр.

Муса Җәлил бу хәлгә бик әрнеште, ачынды, шул ук вакытта бу күченеп йөрүләр аны көрәшнең яңа формаларын уйларга мәжбүр итте. Бу көрәш инде искиткеч зур һәм аяусыз булачак, аның масштаблары үзгәрәчәк, куркынычы бермә-бер артачак. Ләкин ул хәзер коммунист шагыйрь йөрәге өчен бердәнбер юаныч, бердәнбер юл.

Бу көрәш нинди юллар белән барыр, ничек оештырылыр — моны әле Муса ачык белми. Тик шагыйрь шагыйрьлегеннән тыела алмый, үзенең нәфрәтле, ачынулы

уйларын җырга сала, аларны үзе булган лагерьларда, төрмәләрдә кешеләргә укый, һәм бу җырлар, телдән телгә, лагерьдан лагерьга күчеп, кешеләрнең йөрәкләренә үтә, аларның күңелендә зур омтылышлар уята, аларны Муса үзе омтылган зур максатка әзерли иде.

12. ДЕМБЛИН КРЕПОСТЕНДА

Декабрь аеның салкын җилле бер көнендә Мусаларны Польшаның Висла елгасы буена урнашкан Демблин крепостена китерделәр. Крепостьның кирпеч стеналары бер яктан, текә яр булып, Висла елгасына төшә, калган яклардан ул тирән-тирән чокырлар белән уратып алынган.

Ачы җилдә озак килгәннән соң да әсирләр сафын тиз генә таратмадылар, берәр ышыкка керергә дә ирек бирмәделәр, нәрсәдер тикшерделәр, сүгенә-сүгенә ниләрдер аңлаттылар. Аннан кычкырына-кычкырына бараклларга тараттылар.

Кереп урнашкач, өстенә солдат телогрейкасы кигән уртача гына буйлы бер кеше Муса янына килде. Ул бик таныш кебек иде, ләкин шагыйрь аны капылт кына исенә төшерә алмады. Қилүче дә, Мусаны танып бетерергә тырышкан кебек, берничә секунд дәшмичә карап торды. Тирән уйлар уйлагандай, җыерылып бергә тоташа язган шактый куе кашлары һәм, киң булмаса да, ничектер калкыбрак торган маңгае беренче карашта ук күзгә ташлана иде. Болар әз генә кысылып торган коңгырт күзләр белән бергә ниндидер үзсүзлелек тәэсире калдыралар. Муса элек кемгә карап шулай уйлый иде соң әле? Баттал, әйе, бу шагыйрь Салих Батталның энесе бит! Бу Батталларның үзләренә генә хас йөз сызыклары!

Ул шулай уйланып торган арада, теге кеше, кулын сузып:

— Муса, — дип дәште.

— Әйе, мин! Син Абдулла бит, әйеме. Бераз үзгәргәнсең, ләкин Батталлар әллә каян таныла. Онытканчы әйтим әле, мин — Гумеров, хәтерендә тот, мин — Гумеров.

— Ничек монда килеп чыктыгыз, Муса, нинди җилләр белән?

— Җилләре билгеле инде, Абдулла. Мин сиңа барысын да соңыннан сөйләрмен әле. Ә хәзергә син сөйлә, син. Хәлләрең ничек? Нинди урын бу? Кемнәр бар монда?

— Нинди урын дисеңме? Җәһәннәм бу, Муса. Дөресрәге, теге дөнья бу, җәһәннәме дә, оҗмахы да бар. Монда ачлыктан, фашист җеннәренең кыйнавыннан көн дә йөзләрчә кеше үлә. Хәзер бу дөньядан күп җиңелрәк булып калган теге дөньяга ычкына. Крепость янындагы озын калкулыкларны күргәнсеңдер. Анда меңнәрчә-меңнәрчә кешеләребез күмелгән. Ә монда калганнар ачлык, туңу, кыйналу, мыскыллану кичерәләр. Оҗмахы да бар барын. Җанын Гитлерга сатарга риза булганнарны анда алалар. Анда көненә өч мәртәбә болганчык шулпа ашап, көне буе маршировать итеп, үз туганнарыңа каршы сугышырга өйрәнеп, рәхәтләнеп яшисең. Легион диләр аны.

Соңгы сүзләрне Абдулла аеруча ачыну белән әйтте. Аның күз алдыннан совет гаскәрләре сафында сугышып йөргән туган абыйсы белән энесенең шәүләләре узды, күрәсең.

Бу юлы якташларга иркенләп сөйләшергә ирек бирмәделәр, бер сакчы кереп, Батталовны каядыр алып китте.

Батталов акрынлап Мусага бик күп нәрсәләрне ачып бирде. Әллә ничә блокка бүленгән бу крепостьта меңләгән совет пленныйлары яши икән. Татарлар да аз түгел. Әсирләр, газап чигүләренә карамастан, үзләрен ныклы тоталар. Бик күпләрнең йөрәге көрәш дәрте белән яна.

Абдулла лагерьда рус пленныйларының нинди дер бер оешмасы булырга тиешлеген, татарлар арасында да оешырга омтылу барлыгын Мусага әйтте. Төрле кешеләр белән таныштырды. Шулардан матур кара күзле Гайнан Курмаш тиз арада Мусаның якын дусты булып китте.

Дуслар мөмкинлек булган саен очрашалар, Муса аларга үзенең шигырьләрен укый, иреккә хыяллары белән дәртләндерә, оешу юлына тарта. Алар исә, Мусаның шигырьләрен, сүзләрен, телдән телгә йөртеп, башкаларга җиткерәләр, шулай итеп, әсирләр күңелендә якты хисләр уяталар. Ватанны сагыну, аның көчен тою, аңа кайту өметләренең чын булуына ышанычны көчәйтәләр.

Татар әсирләре арасында Муса тагын бер кешегә игътибар итте. Аз гына күтәрелебрәк торган кашлы, тере кара күзле, *юка иренле бу йөздә тәвәккәллек тә, шаянлык та*, кыюлык та күренеп тора иде. Бу кеше гел җитез хәрәкәттә — үзенең ачуын яки соклануын һәрвакыт кычкырып әйтә. Я моңаеп җырлый, я лагерьны нәләтләп сүгенә. Бу егетне Дим дип йөртәләр иде. Беркөнне кичен Дим, авыр эштән кайткач, гадәте буенча язмышын нәләтләп алды да кычкырып җырлап җибәрде.

Үләрмен дә онытырлар, диеп,
Юкка гына йөрәк янасың,
Тамбов урманнары сагыныр әле
Үзе үстергән бунтарь баласын.

Аның матур тавышы, Такташның искиткеч тирән мәгънәле сүзләрен йөрәккә салырлык итеп моңлы җырлавы Мусаны иректән үзенә тартты. Ул Дим янына килеп утырганын сизми дә калды.

— Җырла, дус, җырла әле! Тагын нинди җырлар беләсең?

Икенче көнне кичен Муса Димгә үзенең шигырьләрен язып бирде һәм мондагы һәрбер совет кешесенең хисләр-

рен, омтылышларын үзенә туплаган бу шигырьләр хәзер, Димнең моңлы җыры булып, йөрәкләргә үтә башлады.

Дим Муса өчен бик кадерле кеше булып китте. Ул, матур җырлавы өстенә, шигырьләрне бик тиз ота һәм жан тетрәткеч көч белән сөйләп тә бирә ала. Муса аңа карап канатлана, шигырьнең кешеләрне көрәшкә уятудагы көченә горурлана һәм үзенең зур омтылышлары эшкә ашачагына ныграк ышана бара.

Алда нинди көрәш тора! Крепостьта режим катыланганнан катылана бара: адым саен сакчылар, иркенләп сөйләшергә, киңәшергә дә юк. Ачлык, ялангачлык кешеләрнең күңелен үтерә, аның өстенә кыйнаулар, җәзалаулар. Кечкенә генә гаеп өчен дә азаплы үлем көтә. Шуңа күрә эшне бик сакланып алып барырга туры килә.

Беркөнне Муса лагерьдан кинәт юкка чыга. Бу аның бөтен ипгәшләрен шомландыра: кая китте ул? Нишләттеләр, кая куйдылар аны фашистлар? Берсеннән-берсе шомлырак имеш-мимешләр сөйләнә.

13. КЫЗЫКЛЫ ҮЗГӘРЕШ

Ә бу вакыт Муса гажәп кызык хәлләр кичерә иде.

Аны, поездга утыртып, Берлинга алып килделәр. Вокзалдан төшкәч, ике катлы ниндидер бер йортка илттеләр. Сырлы баскычлардан менеп, бормалы-бормалы коридорларны үтеп, бер бүлмәгә алып керделәр. Тар кровать, борынгы күн диван, борынгыча сырлап эшләнсә дә, аяклары какшап беткән өстәл — болар пөхтә яшәргә тырышкан ярлы студент бүлмәсен хәтерләтәләр. Ләкин бирегә Мусаны, төрмә камерасына керткән кебек, төрткәләп кертеп ташладылар. Бераздан немец офицеры керде. Ул, югарыдан биргән әмергә буйсынып булса кирәк, ачуын тыя-тыя, Муса белән әдәплерәк сөйләшергә тырышты:

— Шинельләрегезне салыгыз, яхшылап юыныгыз, әйдәгез, мин сезгә юыну бүлмәсен күрсәтәм.

Коридор белән барып, бер ишекне ачты да Мусаны шунда төртеп кертте. Үзе сакчы кебек ишек төбенә басты. Монда умывальник, бер таз, сабын, щетка кебек нәрсәләр һәм кырыну приборы бар иде. Муса башта иркенләп кырынды, аннан чишенеп, рәхәтләнеп юынды. Мондый мөмкинлекне аның инде күптән күргәне юк иде. Алда нәрсә көтә, анысын да белми, җәзамы, үлемме, барыбер, моңа кадәр күрелгән хурлыклардан авыррак булмас әле, ни генә әйтсәң дә, тәннең сафлыгын тою рәхәт. Ул шуңа күрә ашыкмады. Ә немец офицеры түземсезлек белән инде берничә мәртәбә ишекне ачты, бирелгән инструкцияне үтәргә тырышты, елмаеп кына карады, ләкин ахырда түзә алмады:

— Шнелль, шнелль, доннер Веттер! — дип кычкырды.

Муса көлемсерәп куйды да үзенекен дәвам итте. Юынды, чәчләрен щетка белән ипләп тарады, аннан чирканып кына керләнгән күлмәген кия башлады. Шул вакыт ишек ачып караган офицер тагын кычкырып җибәрде:

— Ташлагыз ул пычракны, шнелль, шнелль!

Йөгереп килде дә Мусаның кулындагы киемнәрен читкә ыргытты, аның үзен шәрә килеш коридорга алып чыкты, аннан баягы бүлмәгә китереп ишекне ачты да:

— Рәхим итегез! — дип, төртеп кертте.

Муса бернәрсә дә аңламыйча аптырап торды. Шунда немец офицеры, йөзенә ниндидер бер һавалану һәм шул ук вакытта үкенү билгесе чыгарып, Мусага диванда яткан чиста киемнәрне күрсәтте:

— Әнә, болар бар да сезгә!

Бу «пычрак русиш пленныең» мондый әйбәт киемнәргә киендерүнең нигә кирәклеген офицер үзе дә аңлый алмый иде, күрәсең.

Әйе, чыннан да гажәп — диванда чиста белье, ак күлмәк, галстук, кара костюм бар иде. Ә идәндә бер пар штиблет тора. Шагыйрь, аптырап, тирә-ягына каранса, стенадагы чөйгә эленгән бер көзге пальто да күрә. Муса беравык, нишләргә белмичә, аптырашлы уйлар кичерде, аннан, ни булса да булыр дигәндәй, киенергә тотынды.

Берничә минуттан инде немец офицеры алдында «пычрак русиш пленные» түгел, ә матур һәм пөхтә бер әфәнде басып тора иде. Немец офицеры моны күреп аптырап калды. «Моның белән каты кыланырга ярамаган, ахры, бу юри пычрак киемнәр киенгән зур начальство түгелме соң?» — дигән уйлар да аның башына килде. Ул инде үз карьерасының киләчәгә турында бераз кайгыра да башлады. Шуңа күрә, бер ханым поднос күтәреп Мусага ашарга китергәч, ул тавышына моңа кадәр ишетелмәгән төчелек чыгарып:

— Ашагыз, ашагыз, әфәндем... бу сезнең өчен, — диде.

Озакламый ишектән тагын бер немец офицеры килеп керде, аның зуррак дәрәҗәдә икәне күренеп тора. Мондагы офицер ашыгып аңа честь бирде:

— Хайль Гитлер! — дип акырды ул. Ләкин керүче артык игътибар биреп тормады. Мусага таба ашыкты:

— Ә, Җәлилов әфәнде, исәнмесез, ничек килеп җиттегез?

Муса хәзер инде немецлар тарафыннан танылуын аңлады, ләкин моңа бик исе китми, тик «шагыйрь Муса Җәлил — немец әсире» дигән сүзнең халыкка ничек тәэсир итүен уйлый да, йөрәге жу итеп китә. Шуңа күрә немецлар авызыннан «Җәлил» дигән сүзне ишетү дә аның күңеленә көчле әрнү, ачу дулкыннары кузгата.

— Сез ялгышасыз, Җәлилов түгел мин, герр офицер, ә Гумеров!

— Ярый, ярый, бик яхшы, Гумеров әфәнде. Сез әзердер дип уйлыймын. Машина — аста. Доктор Розенберг безне көтә торгандыр инде.

Мусага ныграк тәэсир итсен өчен ул соңгы сүзләрне бераз тантана белән әйтте. Ләкин шагыйрь, эченнән бераз гаҗәпләнсә дә, тыштан бер дә үзгәрмәде. Бу сүзләрнең иң нык тәэсире бая гына Мусаны төрткәләп йөрткән офицерга булды. Аның күзләре шар кебек ачылды, башыннан меңтөрле уйлар узды. Доктор Розенберг зарыгып көткән бу кешегә начар мөгамәлә кылып, үз башына бәла алганлыгына ул хәзер шикләнми иде. Җәлил үзенең мәһабәт тынычлыгын саклаганда, бу ахмакның юктан шулкадәр куркуы, бернәрсә дә аңламавы өлкән офицерның ачуын китерде. Ул кирәгеннән артык кычкырыбрак:

— Лейтенант Вальденау, сез безнең белән барачаксыз, машина янына төшә торыгыз, — диде.

Лейтенант ук кебек атылып чыгып китте, аның артыннан Муса белән майор кузгалды. Мусага таныш булмаган маркалы яңа машина, урынынан салмак кына кузгалып, чатлардан борыла-борыла, Берлин урамнары буйлап җилдереп китте.

14. ЮККА ӨМЕТЛӘНӘСЕЗ, ГЕРР ДОКТОР!

Розенбергның болын кебек иркен бүлмәсенә шактый кеше килгән иде. Зур өстәл артында хуҗа үзе утыра. Аның каршындагы креслога доктор Унгляубе урнашкан. Икенче креслодагы профессор Менде, урынынан бераз күтәрелә төшеп, ашыгып-ашыгып Розенбергка нидер сөйли. Татар шагыйре Муса Җәлилнең пленга эләгүен белгәннән бирле, ул берничә ай эчендә Муса турында матбугатта чыккан һәрбер сүзне, аның бөтен басылган әсәрләрен, эмигрантларның газеталарында татар әдипләре турында еллар буена язылып килгән бөтен гайбәтләрне

өйрәнде. Шул мәгълүматларны ул шефы Розенбергка да мөмкин кадәр тулырак аңлатырга тырышты.

Бүлмәдә хәрби һәм гражданнар киемендәге башка кешеләр дә бар иде.

Муса белән килеп кергән майор, честь биреп, бөтен кәгыйдәсенә туры китереп, хәбәр итмәкче иде, Розенберг кул гына селекте һәм Мусага ихтирам белән мөрәҗәгать итте:

— Рәхим итегез, Җәлилов әфәнде!

— Гафу итегез, Җәлилов түгел, Гумеров.

— Ярый, рәхим итегез, Гумеров әфәнде! — Бу юлы Розенбергның тавышында ирексездән ниндидер ирония яңгырап үтте.

Профессор Менде, ашыгып башын ия-ия, Мусага урын бирде. Бүлмәдә утыручылар арасында: «А, Муса әфәнде, хөрмәтле Муса әфәнде!» — дигән татарча сүзләр дә ишетелеп китте.

— Гумеров әфәнде, без сезнең хакта кирәк кадәр беләбез. Үзегезнең кем икәнлегегезне ни өчен яшерергә тырышасыз? Ләкин юкка. Дан дигән әйбернең бик күп яклары бар бит аның. Бер ябышса, котылуы кыен. Менә сез, алама киемнәргә, ят фамилиягә яшеренеп, аңардан качмакчы булдыгыз, ә ул юк! Барыбер эзләп тапты үзегезне. Ул сезне хәзер яңа матур юлга чакыра.

Муса Розенбергның бу сүзләренә ни дип тә җавап бирмәде, ләкин дошманның соңгы сүзләре белән килешергә туры килә: әйе, аны алда яңа юл көтә, Розенберг уйлаган матур юл түгел, әлбәттә. Ул — авыр юл, ләкин туры һәм бөек юл.

Розенберг, бераз пауза ясап, Мусага карап торды. Гажәп көчле бер рухи броня белән үзенең күңеленә үтеп керүчеләрдән кыю сакланып килгән бу кешене ничек йомшартырга, нәрсә белән кызыктырып, аның йөрәген ачарга мөмкин? Менденың сөйләвенә караганда, ул ти-

рән хисле шагыйрь. Үзенең иле, яшьлеге турында күп шигырьләр язган. Менде Мусаның мәхәббәт шигырьләрендә хиссиятлелек, нечкәлеккә омтылу күргән. Мусаның шактый калын иреннәрендә, әле һаман очкынланып торган күзләрендә дә шул хислелек күренә. Бу кеше дөньяда шат яшәүдән баш тартмый торган булырга тиеш.

— Белә торгансыздыр, Гумеров әфәнде, мин үзем дә сугыш кешесе түгел бит. Шуңа күрә шагыйрь жанының бу сугышта чиккән газапларын аңлыйм мин... Менә шул хис ищетү белән үк сезнең хакта кайгыртырга мәҗбүр итте дә. Әлбәттә... хи-хи... мин сезгә хәзер үк шагыйрьгә лаек булган бердәнбер тормыш — вино, ләззәт белән генә тулы тормыш вәгъдә итә алмыйм. Анысы киләчәктә. Моның өчен әле хәзер бик күп эшлисе бар. Без — чын гуманистлар, без һәр кешенең шәхесен тулысынча азат итү өчен, һәркем, ничек тели, шулай ләззәтләнеп яши алсын өчен сугышабыз. Минемчә, бу омтылыш шагыйрь күңеленә бик туры килергә тиеш. Менә шул тормышны хәзерләүдә без сезгә тулысынча ирекле булып катнашырга мөмкинлек бирергә уйлыйбыз.

— Гафу итегез, герр доктор, мин сездән андый ирекне сораганым юк бит.

— Әйе, әйе, анысы дөрес. Без сезне үзебез чакырабыз. Тулы хокуклы булып, югары омтылышлар өчен көрәшергә.

— Онытмагыз, герр доктор, мин бит азиат. Сезнең мәкаләләрегездә язылганча, бетерелергә тиешле түбән раса кешесе, ярым кешеләр расасыннан бит.

Бу вакытта бүлмәдә утыручыларның берсе татарчалап: «Я алла, я алла!» — дип пышылдап куйды. Муса аңа борылып карады һәм кызыл йөзле, сары мыеклы бер кешене күрде. Бер мизгел генә: «Әллә таныш? Кем бу?» — дигән уй үтте, аннан Розенбергка борылып, тагын аның сүзен тыңлый башлады.

— Сез, Гумеров әфәнде, артык кискенләштерәсез. Ул мәкаләләрдә минем үз фикерләрем генә. Гомуми көрәшебез — дөньяга тынычлык китерү.

— Шул сезнең фикерләрегез буенча миллион кеше үтерелә, бала-чагалар штыкка тотыла, танклар белән таптатыла түгелме соң? Йөзләрчә лагерьларда ачлык-ялангачлык, кыйнау, мәсхәрәләү белән, ә ахыр чиктә пулялар яудырып меңнәрчә кешеләрне үтерү дә сезнең үз фикерегез буенча эшләнә түгелме?

— О, юк, хәзер бит эшләр башкача тора, фюрер үзенең изге көрәшенә өлеш кертергә бөтен милләтләргә рөхсәт бирде. Хәзер һәрбер кеше, һәр әсир, авыр лагерь тормышын ташлап, бөек империя өчен көрәшә ала, легионнарда аларга рәхәтләнеп яшәргә мөмкин.

— Кешеләрне бер телем ипигә сатып алып, туганнарына каршы сугышка җибәрмәкчесез. Ләкин бу көчегезне күрсәтми бит, герр доктор. Сез үзегезнең «изге» эшегезне хәзер теләсә кем кулы белән эшләргә дә риза, ләкин сезгә кем дә ышанмас.

— Гумеров әфәнде, мин сезнең убеждениеләрегезне беләм, ләкин сез эшләп карагыз әле безнең Европа шартларында — иректә яшәп карагыз. Бәлки, аннан...

— Герр доктор, юкка өметләнәсез. Мин Ватанымны сатмам, дус халыкларыма карата сезнең кебек пычраклар ташламам, аларның каннарына сусамам...

Розенбергның битенә кан йөгерде. Артта теге кеше тагын: «Я алла, я ходай, нишли бит», — дип пышылдады. Мусаны алып килгән майор сикереп торды да, әмер көтеп, Розенбергның йөзенә карады. Ләкин Розенберг үзенүзе кулга алды. Майорны ишарә белән тынычландырды да Мусага елмаеп әйтте:

— Ярый, Гумеров әфәнде, бу юлы мин сездән кискен җавап сорамыйм, уйлагыз, уйлагыз. Монда сезне белүчеләр, яратучылар җыелган. Менә доктор Унгляубе — ул

сезнең белән гел бәйләнештә булыр, үз теләгегезне миңа аның аша җибәрерсез. Әнә монда якташларыгыз, мөселманнар да бар, алар да сезгә ярдәм итәр. Мин сүзегезне көтәрмен, ә хәзергә хушыгыз. Хушыгыз, господа.

Бар да урыннарыннан кузгалдылар. Муса борылып чыга башлады, аңа доктор Унгляубе белән үзен алып килгән майор иярде. «Я алла!» — дип утырган татар алгы бүлмәдә ашыга-ашыга Муса янына йөгереп килде һәм төкерек чәчә башлады:

— Я, Муса әфәнде, нишлисез сез, нигә болай кыйланасыз, шундый хөрмәт, шундый ихтирам, безнең бөтен мөселман халкы өчен бер дәрәҗә бит бу, ә сез, ә сез... Үзегезне әз генә харап итмәдегез бит, уйлагыз, Муса әфәнде, акылга килегез...

Муса бу кешене әкрен генә этәрде дә ишеккә таба китте, аның артыннан Унгляубе һәм майор ашыктылар.

Коридорда Унгляубе Мусага:

— Гумеров әфәнде, мин сезнең фикерегез үзгәрүне чын күңелдән телим һәм... моның өчен кулымнан килгән кадәр ярдәм итәчәкмен, — диде дә икенче якка борылып китте. Аның бу сүзләре ишек төбе саен сакчылар басып торган коридорда никтер шомлы булып яңгырадылар...

15. СУДАН УТКА, УТТАН СУГА...

Муса белән майор чыгып машинага утырдылар, анда *аларны баягы лейтенант көтеп тора иде.*

Муса машинада килгәндә, тормышындагы, дөресрәге, тышкы кыяфәтендәге үзгәрешне, сәләмә әсирдән кинәт кенә «джентельмен»га әверелүен уйлап, ирония белән елмаеп куйды.

Ләкин аны тагын да гаҗәбрәк үзгәрешләр көтә иде әле.

Менә машина туктады. Ләкин бу баягы йорт түгел иде. Ниндидер капка, аңа будка кебек әйбер тоташкан. Капка ачылып, машина йортка керде, майор, Муса, лейтенант машинадан чыктылар. Майор лейтенантка нидер әйтте дә үзе бер ишеккә таба юнәлде. Лейтенант аның сүзенә бераз гажәпләнеп торды да кинәт Мусага:

— Шнелль, марш! — дип төртеп җибәрде.

Мусаны таш стеналардан башка бернәрсәсе булмаган бүлмәгә китереп, лейтенант:

— Чишен, шнелль, шнелль, — дип акырды.

Мусаның бөтен киемнәрен тартқалап чишендерде дә, шәрә килеш коридор аша алып барып, иңе-буе бер метрлык таш бүлмәгә төртеп кертте.

— Карцер, 5 тәүлек! — дип акырды ул, рәхәтләнеп— үзенең әле генә бу кеше алдында бераз шүрләп калуының ачуын кайтарырга тырышты.

Ишекне ябып бикләделәр. Муса кечкенә генә таш тартмада берүзе калды. Стеналарына кагылсаң, стеналары шабыр су, түбәдән шәрә тәнгә тамчы тамып тора. Бу беренче тамчылар бик газаплы булды Мусага. Бераздан килеп ишекне ачтылар, аңа сәләмә күлмәк-ыштан ыргыттылар. Кысрыкта, терсәкләрен таш стенага сыдыра-сыдыра, шагыйрь аларны көчкә генә киде. Ул тагын елмаеп куйды: әкияттәгедәй тиз үзгәрешләр. Хәерчедән принцка, принцтан хәерчегә әверелү. Ләкин ул принц кебек киенгәндә дә үзен рәхәттә тоймады, ул чакта үзен ут эчендә тойды, хәзер менә суга китереп ташладылар. Бер утка, бер суга. Корычны шулай чыныктыралар түгелме соң? Әйе. Бу корыч чынлыгып җитәр һәм явызларга хәнҗәр булып кадалыр әле!

Муса басып тора, ә уйлар бертуктаусыз агалар. Алда чиксез вакыт диңгезе. Биш тәүлек, — миенне тишәрдәй булып тамган шушы тамчылар астында, утырырга да мөмкин булмаган шушы тар, юеш таш тартмада. Вакыт

шулкадәр акрын уза. Уйлар, уйлар гына монда аңа ярдәмче дә, юатучы да. Менә алар шагыйрьне моннан алып чыктылар да секунд үтүгә туган илгә, Казан каласына кайтарып житкерделәр. Хәзер төн. Менә Зур Галактионов урамындагы йортның бүлмәсе. Балалар кроватенда аның нәни Чулпаны ята. Әминә йоклый. Нинди төшләр күрә икән алар? Муса турында ниләр генә уйлап бетерде икән Әминә? Хәбәрләшмәгәнгә күпме ай үтте инде. Тик, Әминә, мин синең көтүеңә ышанам, син көтәсең мине, Чулпан көтә, илем көтә, ышанам — шуңарда минем көчем, шуңа күрә мин бу газапларны да жиңәрмен...

...Вакыт акрын гына үтә. Карангы таш тартмада көнне дә, төнне дә белеп булмый. Тик көненә бер мәртәбә килгән сасы шулпага карап кына тәүлек үткәнен чамалап була. Су бирмиләр. Муса стенадагы дымны ялый. Инде ике көн үтте бугай. Буыннарның хәле бетте кебек. Ул еш кына баскан килеш йокыга китә, шап итеп таш стенага бәрелә дә уяна.

Өченче көн. Хәл бөтенләй бетә. Түзеп булмас кебек. Уйлар вакыт-вакыт бөтенләй буталып китә. Муса, хәлдән таеп, ишеккә ава да башы бәрелә. Тезләре калтырап бөгелә. Ләкин, коридорда аяк тавышы ишетелеп, карцер ишеге ачыла башлау белән, ул, бөтен көчен жыеп, тагын торып баса. Тезләренең калтыравын дошманга күрсәтмәскә тырыша. Эчкә баткан һәм янып торган күзләре ишектән кергән фашистларга төбәләләр дә ут кебек пешерәләр. Маңгаена, битенә борчак-борчак салкын тир чыга...

Дүртенче көн. Баш һаман томанлана бара. Ләкин Муса бирешмәс!

Бишенче көн... Соңгы минутларда, фашистлар аны чыгарырга киләчәк минутларда йомшап калмас өчен, Муса, стеналарга сыенып, бераз булса да хәл жыярга тырыша. Бер йокыга китә, бер уйлары буталып, әллә

нинди упкынга төшә. Менә аяк тавышлары. Карцерны ачалар. Муса төз басып фашистларга карап тора. Ул горур елмая, һәм тәмуг азабы кичергән бу кешенең шушы елмаюы дошманнарга куркыныч булып күренә. Алар, үзләре дә сизмәстән, артка чигенеп куялар, аннары:

— Тизрәк, тизрәк, — дип кычкыра-кычкыра, аны ике яктан төрткәләп, өстерәп, ялгыз камерага илтеп ташлыйлар.

Бер сәгать тә үтми, тагын ишек ачылды, аның янына майор килеп керде:

— Сезнең доктор Унгляубега әйтәсе сүзегез юкмы әле, Гумеров әф-фән-де? — Соңгы сүзенә ул үзенең пычрак җанындагы бөтен мыскыллау көчен салды.

— Юк, — диде Муса.

Майор чыгып китте.

Икенче көнне Мусаны аннан-моннан киендерделәр дә (гимнастеркасы урынына каешланып беткән ниндидер френч, үзенекеннән дә аламарак шинель, пилотка), машинага утыртып, тагын каядыр алып киттеләр.

Алар килеп кергән бүлмәдә теге кызыл татардан башка бер кеше дә юк иде. Муса кергәч тә, ул аңа каршы омтылды һәм тагын төкерек чәчә-чәчә сөйли башлады:

— Их, Муса әфәнде, Муса әфәнде, ничек сез үзегезне бу кадәр кызганмыйсыз? Бөтен мөселман дөньясы үзегез өчен кайгыра, яхшылык тели. Ә сез, алдыгызда торган рәхәт, җиңел юлга кул селтәп, тәмуг газаплары кичерүне өстен күрәсез.

Ул, Мусаны култыклап, бер креслога утыртты, һаман төкерек чәчеп сөйли бирде. Муса аңа бер җавап та кайтармады, ялган хәсрәтләнүләренә колак салмады, тик үзен кызыксындырган сүзләр ычкынганда гына аларны күңеленә ала барды. Шулай итеп, бу кешенең элеккеге Оренбур спекулянты Шәфи Алмаз булуын, немецларның Идел белән Урал арасында *төзибез дип вәгъдә ит-*

кән «Идел-Урал» дигән татар милли «дәүләтендә» нин-дидер бер чиновник икәнлеген, хәзер төзелә торган татар легионнарын фронтка җибәреп, анда уңышлы гына эш барса, Россиядәге татарларны да Советка каршы күтә-ргә мөмкин булыр дип, тузга язмаганны хыялланып йөрүче икәнен белде.

Бераздан бүлмәгә доктор Унгляубе керде. Ул да Мусаны үгетләвен дәвам итте. Аның сүзләреннән дә Муса легионнарга немецларның зур өмет баглауларын аңлады. Алданган меңнәрчә кешеләрнең фронтта үз туганнарына каршы сугышулары күз алдына килгәч, ул тетрәп китте. Хәзер ул шушы күренештән, ничек шуны булдырмаска дигән уйдан башка бернәрсә дә уйлый алмады. Унгляубе-ның сорауларына да тегеннән-моннан гына җавап бирде. Шуңа карап, Унгляубе Мусаның фикере бераз үзгәрде ахры, дип белеп, шактый канәгать калды.

— Ярый, Гумеров әфәнде, сезнең белән тиздән очра-шырбыз, очрашырбыз гына түгел, хәтта килешербез дип тә уйлыйм мин. Аннан... бәлки, шушы көннәрдә сез үзе-гезнең якташларыгыз, хәтта... фикердәшләрегез белән очраша алырсыз. Алар белән киңәшкәндә дә, ышанам, туры юлның бердәнбер булуын истә тотарсыз...

Унгляубенең сүзләре бар да диярлек дөрескә килде. Бераздан соң Мусаны лагерьга алып киттеләр, бу Дем-блин түгел иде инде. Берлин янындарак кына бүтән лагерь иде. Монда Муса чынлап та үзенең якташларын, алай гына да түгел, якын иптәшләрен очратты. Тирән әрнү катыш шатлыктан күзләренә чыккан яшьләрен сөртә-сөртә, алар Абдулла Алиш белән кат-кат кочаклаштылар, бер сөйләшеп алдылар да, тагын шул тирән кайгылы шатлык хисләренә бирелеп, кочаклашып сүз-сез калдылар.

Мәскәүдәге дусты, яшь татар журналисты Симаев Мусаны тыны кысылганчы кочаклады.

Көннәр буена аерыла алмыйча сөйләшсәләр дә туймадылар.

Унгляубеның башка сүзләре дә дөрес булды. Берничә көн үтү белән, Муса аларның тәкъдимен кабул итте: «Менә, әйттем ич мин сезгә, ялгышасыз, дидем». Икенче очрашуда Унгляубе аны шул сүзләр белән каршы алды. Ләкин кем ялгышканын хәл итәчәк көннәр әле алда иде.

БЕЗНЕҢ МУСА

(Поэмадан өзек)

Дөньяда шулай итеп яшәргә кирәк,
үлгәннән соң да үлмәслек булсын...

Муса Җәлил.

1

Таш коймасы биек Моабитның,
Капкалары аның тимердән.
Варфоломий төне [1],
Үлем төне
Кабатланып тора биредә.

Муса утыра ялгыз камерада;
Тар камера тынчу һавалы.
Конвойчылар йөри коридорда,
Итекләре тимер дагалы.
Сугенәләр... Хурлау тавышлары
Көн-төн синең колак төбендә.
Таш идәндә тынмый чыңгылдаган
Шул дагалар белән бүген дә,

[1] 1572 елда Франциядә католикларның гугенотларны суйган төне.

Әйтерсең лә алар тоткыннарның
Йөрәкләрен изеп үтәләр.
Кемнең суга соңгы минутлары,
Кемнәр таңда җәза көтәләр...
Ява тышта көзге карлы яңгыр,
Һәм туктаусыз улый җил генә.
Муса күңелен кайгы-хәсрәт талый,
Тормышка һәм туган җиренә
Шушы кадәр көчле мәхәббәтне
Һәм яшәүгә шундый теләкне,
Шушы кадәр тирән әрнү белән
Өзгәләнгән чагын йөрәкнең
Кисәкләргә телгәләнгән чагын
Ул белмәгән иде моңарчы, —
Туган илең, якыннарын җуеп,
Чит җирләрдә тоткын булганчы...

Исенә төшә башы ерак юлның,
Тирән сагыну хисе уятып,
Сагыш белән,
Өмет белән тулы
Күпме күзләр калды озатып.

Күпме күзләр...
Күпме яшьле күзләр...
Алар аны озак көтәрме?
Әйтелмичә калган соңгы сүзләр
Җырга гына сыеп бетәрме?

— Гөл бакчага кердеңме лә,
Гөл чәчәген өздеңме?
Гөл чәчәген өзгән кебек,
Аерылыштык,
Аерылыштык,

Аерылыштык,
сизденме?
Агылдылар көн-төн эшелоннар...
Юл буенда язны сагынган
Ак каеннар,
Бәсле ак каеннар
Онытылмыйлар... Алар янынан
Юлы аның кабат уза сыман;
Күчә күңеле сугыш кырына;
Походтагы Муса,
Солдат Муса
Баса гүя үзенең урынына.

4

Сугыш кызды таңда яңадан;
Ут шәүләсе Волхов өстендә.
Тирә-яктан дошман камаган,
Безнекеләр божра эчендә.

Бомба, мина яуды һәр яктан;
Ачы төтен кисте күзләрне.
Үлде дуслар... Канлы туфракка
Куеп үлде алар йөзләрен.

Яраланган шагыйрь күкрәге;
Карашында — соңгы өметләр:
— Туздырылыр козгын өере,
Ояларын бирмәс бөркетләр.

Әрнү телә бәгырен Мусаның:
— Тели язмыш миннән көләргә.
Чакыра каны солдат дусларның
Керсез намус белән үләргә!

Ул чайкалып алга атлады,
Шулай кушты аңа йөрәге.
Чигәсенә китереп төбәде,
Пистолеты ләкин атмады.
Соңгы адым... Соңгы талпыну...
Ышанычы — соңгы юлдашы:
— Юк, кол булмас безнең халкыбыз;
Каплый алмас һичкем кояшны!

Хуш, онытма, газиз Ватаным!
Хуш, онытма, кызым — Чулпаным!
Ул бераздан аның югалтты,
Кочкан килеш Волхов туфрагын...

5

Артта калды янган сугыш кыры;
Куып китте дошман ераккә.
Шауламыйлар Волхов дулкынары,
Башка сулар ага бу якта.

Күз төбәгән Муса көнчыгышка,
Басып тора лагерь эчендә.
Басып тора. Тир-тузанга каткан
Гимнастерка аның өстендә.

Тоткында ул. Азат тормышыннан,
Ул иркеннән мәхрүм биредә.
Бөтен күңеле,
Сулар сулышы да
Тарта аны туган иленә.

Калын урман беткән ботарланып;
Корып көйгән яшел аланнар.

Наратларның сынган ботаклары
Тырпаешып катып калганнар.

Читтә лагерь. Тимер чыбык белән
Алынган ул урап, киртәләп.
Тоткыннарны
фашист-конвойчылар
Уяталар таңда типкәләп.

Нагайкалар чыжлый җилкәләрдә;
Кайда вакыт ашап-эчәргә;
Прикладларны ходка җибәрәләр
Һәм куалар урман кисәргә.

Таралмаган әле саз томаны.
Дүрт-биш тоткын эшли бер читтә.

— Дусларым, — ди Муса, — туганнарым,
Без җиңәргә тиеш ничек тә.
Безне, — ди ул, — кем коткарыр моннан,
Үзебез көрәш алып бармасак?
Фашистларның нәләт коллыгыннан
Кешеләрне йолып алмасак,
Нәрсә өчен соң без коммунистлар?
Бу хакыйкать җитсен меңнәргә:
Юл бер генә безнең, якын дуслар,
Яки ирек, яки үләргә.

*
* *

Саубуллашу бик-бик кыска булды:
— Ярый, дуслар, исән калыгыз!
Яхшы узсак әгәр авыр юлны,

Без яңадан корал алырбыз.
— Дуслар, — диде Муса, — хәерле юл!
Очрашырбыз, исән-сау кайтсак.
Онытмагыз, илгә турылыкны
Үлемебез белән аңлатсак.

Бер минутта куллар кысылдылар, —
Һәркем күңеле юлга ашкынган.
Шуыштылар алар саклык белән,
Урын җайлап койма астыннан.

10

Ничек бетәр соңы качыруның?
Төшмәсләрме шагыйрь эзенә?
Кичә кичен лагерь начальнигы
Чакырып алды аны үзенә.

— Сез бит шагыйрь Муса Җәлил икән,
Инде, — диде, — ачык белдек без;
Сез бит безгә бик кирәкле кеше,
Сезне күптән эзли идек без.

Әйе, — диде, — хәзер башка заман,
Кешеләр дә бездә башкалар.
Сез сугышны, — диде, — оттырдыгыз,
Руслар тиздән корал ташларлар.

Без Берлинга сезне күчерәбез,
Газетада, — диде, — эшләрсез;
Бөтенесе булыр сезнең өчен,
Һәм кешечә итеп яшәрсез.
Акыл белән уйлап карагыз,
Тормыш яки үлем — сайлагыз...

Уртасында шагыйрь ике утның,
Җайласын ул ничек эшләрен?
Ике кулы белән башын тотып,
Шыкырдатып кыса тешләрен.

Нишләсен ул, тукта? Шулай кереп
Тормыш сазлыгына батсынмы?
Туган илен тузан бөртегедәй
Сансыз гомере өчен сатсынмы?

Унөч яшьтә комсомолда иде;
Ә егерме яше тулганда
Партиядә иде. Инде бүген,
Иң дәһшәтле минут туганда,
Ваз кичсен дә моның һәммәсеннән,
Әйләнсенме тирес кортына?

Тормыш дусты, әгәр моны белсә,
Кабул итмәс аны йортына.
— Син юк, син юк, — дияр, — йөрәгемдә,
Йөрәгемдә сиңа урын юк;
Синең белән уртак теләгем юк,
Синең белән уртак юлым юк.

«Улым» димәс аңа туган иле,
Кызы әйтер: әткәм түгел син.
Шулай булса, нинди йөзе белән
Ул иленә кайтып күренсен?

15

Борһан абый таңда эштән кайтты;
Төне аның бушка үтмәгән.
Мусадагы яңа листовканың

Буявы да киҗеп җитмәгән.
«Ватандашлар! Легион әсирләре!
Сезнең өчен сыкрый күңелебез;
Кол итәргә теләп Россияне,
Дошман алдый сезне, белегез:

Үтермәкче сезнең куллар белән
Якыннарны безнең, дусларны;
Яндырмакчы сезнең куллар белән,
Көл итмәкче туган йортларны.

Дошман алдый, сезне мәҗбүр итә
Иң мәкерле эшне үтәргә.
Ата-анаң, балаларың әйтә:
— Безгә каршы корал күтәрмә!
Бер пуля да атма безгә каршы,
Бер пуля да!! — Шуны онытма!
Күзебезне кан-яшь капламасын;
Кәннәребез кара болытка
Капланмасын!
Легион тоткыннары,
Алданмагыз, уяу булыгыз!
Нык булыгыз, дошман коралларын
Үзләренә каршы борыгыз!»

*
* *

Ишетте ул кичә яшерен хәбәр
Һәм Алишка шушы турыда
Сөйләп бирде: әле күптән түгел
Көнчыгышка, сугыш кырына
Озатылган «легион» солдатлары
Мәсьәләнең кыю чишкәннәр —

Сиздермичә үтереп башлыкларын,
Үзебезнең якка күчкәннәр.

— Җиткән, димәк, көче хакыйкатьнең
Штыкларны кире борырга.
Алда безне яңа бәрелеш көтә,
Кирәк моңа хәзер булырга.

Юкка чыкты ничек листовкалар,
Кем чамалап йөргән уңаен?
Куркак кеше, диләр, утка сала,
Бу Исмәев эше, мөгаен.

— Бөтенесен, әйе, аңлыйм, дускай!—
Алиш кулы — Муса кулында. —
Ни күрсәк тә,
соңгы сулышкача
Без калабыз бәрелеш кырында...

17

Таш коймасы биек Моабитның,
Чикләгән ул һәркем карашын;
Киртәләгән шушы үлем йорты
Тормыш белән тоткын арасын.

Күрми шагыйрь таң һәм кояш нурын;
Таш идәнгә каны чәчрәгән.
Юк иңендә кулы Чулпанының, —
Мәхрүмме ул бөтен нәрсәдән?

— Мин югалдым дуслар арасыннан,
Оныттымы инде күбәүләр?
Юк, юк,

Мине сөя, сагына, көтә торган
Йөрәкләр бар... Алар меңәүләр.
Йөз меңәүләр алар... Шушы тойгы
Хәтерләрдә күпне яңарта.
Укучылар алар... Һәркайсының
Йөрәгендә мина карата
Очкын кадәр сөю сакланса да,
Мин тормышта калмам югалып.
Һәм аларның күңеле уртасыннан
Узар җырым үзенә юл салып.

Ява тышта көзге җилле яңгыр.
Тынгы бирми уйлар Мусага.
Бәреп тора юеш таш салкыны,
Кая гына башын куйса да,

Почмагына тынчу камераның
Пәрәвезләр корган үрмәкүч.
Борчучы юк, урыны җайлы аның;
Ара-тирә чыгып иртә-кич,
Тыныч кына шунда яши бирә,
Карацгыда,
качып яктыдан.
Аяклары күбәү; үрмәли ул
Чебеннәрнең куып артыннан.

Бар алардан ике аяклылар,
Арабызда йөри болары —
Түбән җанлы хаин Исмаевлар,
Гестапоның мескен коллары.
Тәрәзәдән үрелеп карый шагыйрь,
Тәрәзәсе тимер челтәрле.
Кемдер анда авыр ыңгыраша,
Буа аны канлы ютәле.

Кемдер җырлый аръяк камерада
Ерактагы сугыш кырында —
Ак томанлы Карпат тауларында
Яраланган бөркет турында;
Сагынып җырлый иректәге чагын,
Сызлый күнеле, яна, борчыла.
Гүя шаулап Прага каштаннары
Җырларына аның кушыла.
Ишек шакый килеп надзиратель:
— Кем арзанга куя үз башын?
Тынмасагыз әгәр, авызыгызга
Койдырырмын утлы кургашын...

Күп тә үтми, яңа җыр башлана,
Юлы аның — авыр, кыска юл:
Таш стена аша,
Үлем аша
Күнелләрне бергә куша ул.
— Коралдаш иптәш,
Тоткын көрәштәш,
уйлыйбыз сезне.
Юеш подваллар,
Таш камералар
аерган безне.
Ләкин йөрәкләр,
Сусап иреккә,
тибәләр бергә.
Хакыйкать җиңәр,
Яктылык җиңәр,
яз килер җиргә.
Булырбыз без дә
Тиздән иректә,
ышанып көтик.
Авыр сынауны

Башны югары
күтәреп үтик!..

Камерада Муса ялгыз һаман;
Тагын озак газап чигәрме?
Кая язсын? Соңгы җырлары да
Үзе белән бергә үләрме?

Юк, үлмәсләр! Аның бу җырларын
Аңлый торган дуслар табылыр.
Күңелләрдә алар тормыш булып,
Шагыйрь гомере булып кабыныр.
Таңнан торды Муса. Күңеле аның
Нидер эзли, нидер юксына.
Якты өмет, якты хыялларын
Уртаклашып, Алиш дустына
Атап язган яңа шигырен укый,
Ялкын тулы шигырь юллары.
Калын таш стена тора аерып,
Ишетмәс тә бәлки ул аны.

— Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә, диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда...

Укый Муса. Тирән борчулы ул.
Керфегенә чыклар кунганнар.
— Керфекләрнең яшькә чылануы
Көчсезлектән түгел, туганнар.
Диңгезләрне йөзеп кичәр идем,
Илтсә юлым туган илемә.
Тамчы булып ташны тишәр идем,
Тамсам әгәр халкым күңеленә...

Һәр көн килә борчу, сагыш алып;
Тумый монда якты иртәләр.
Хәл ителгән: таңда Мусаларны
Дрезденга судка илтәләр.

Ә ул тыныч; чөнки ни буласын
Белеп көтте айлар буена.
— Андре, — ди ул, — бәлки озакламый
Бау салырлар минем муеныма;
Яки башым подвал идәнендә —
Салкын, юеш ташта тәгәрәр;
Каным кибәр палач бүкәнендә...
Тиздән шулай булса бу әгәр,
Сүзем шушы сиңа: бергә үттек
Иң авырын сынау юлының.
Дусты итте сине,
Туган итте
Олы җанлы кеше булуың.
— Рәхмәт, Муса! Безнең арабызны
Якынайтты баштан узганнар.
Без туганнар булып аерылабыз.
— Әйе, Андре, якын туганнар.

Нидер яза Муса, саубуллашып,
Җыенганда соңгы юлына:
«Якын иптәш! Минем бу җырларым
Әләксәләр синең кулыңа;
Таный белсәң, акка күчереп яз
Һәм аларны туган илемә
Җиткер, иптәш!
Дәфтәр битләреннән
Күчсен алар халкым күнеленә.
Бу юлларны язды тоткын шагыйрь,
Бәлки аны син дә белгәнсең.

Үзе үлә ирек, хак эш өчен,
Тик җырлары аның үлмәсен».

Төн уртасы инде бара узып,
Ә син, күңел, нәрсә көтәсең?
— Озакламый калкыр таң йолдызы;
Без аерылабыз... Нихәл итәсең...

Аерылабыз... Вакыт җитә, дустым,
Күрик инде моның хәстәрен.
Сузды шагыйрь сары катыргы тышлы
Уч төбедәй куен дәфтәрен.
— Җырларым бу. Андре, син беләсең,
Безнең яшерен, авыр көрәштә
Россиям дә,
Бергә синең белән
Бельгияң дә сыйды йөрәккә.
Төбәлделәр алар бер-берсенә
Шундый җылы, шундый ягымлы,
Һәркайсының уйчан күзләрендә
Күңел яктылыгы чагылды.

— Ышан, Муса; исән чыксам моннан,
Тапшырырмын, дускай, ничек тә.
Кочаклашты алар.
— Я, хуш, туган!..
Йозак тавышы инде ишектә...

ҮЛМӘС ҖЫР

(Героик драмадан өзек)

Халкыбызның бөек шагыйре — Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилгә һәм аның белән бергә җәзаланып үтерелгән Габдулла Алиш, Әхмәт Симаев, Гайнан Курмашев, Фоат Булатов, Габдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов, Гариф Шабаев һәм Фоат Сәйфелмөлеков иптәшләргә багышлыйм.

Автор.

КАТНАШАЛАР

Муса Җәлил — шагыйрь, 35 яшендә.
Габдулла Алиш — язучы, 32 яшендә.
Янгузов Шәкүр — редактор, 38—40 яшьләрдә.
Алексеев Алексей Федорович — *журналист*, 40 яшьтә.
Батыршин Кәрим — 20 яшьтә.
Сәйфуллин Шәрәф — 25 яшьтә.
Хәсәнов Зиннәт — 32 яшьтә.
Мәхмүтов — 40 яшьтә.
Салмеев Нәфыйк — 27 яшьтә.
Андрэ Тиммерманс — Бельгия партизаны, 32 яшьтә.
Алмашев Гайфи — ак эмигрант, татар легионының *житәкчесе*, «Идел-Урал» газетасы редакторы, 55 яшьтә.
Фон Унгляуб — аның ярдәмчесе, 45 яшьтә.
Клаус — лейтенант, 25 яшьтә.

Грабе — полковник, гестапода өлкән следователь, 50 яшьтә.

Эльза — 22 яшьтә.

Анна-Мария — 18—19 яшьләрдә.

Вакыйга Бөек Ватан сугышы көннәрендә, 1941—44 елларда бара.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

АЛТЫНЧЫ КАРТИНА

Төн. Берлинның зур урамнарының берсенә чыга торган кечкенә аулак урам. Зәңгәр фонарьлар яна. Өйнең бер почмагы күренә. Парадный ишек алды. Патруль үтеп китә. Радиода музыка матур бер көй уйный. Ут кабына. Муса бүлмәсе. Ул кечкенә, ләкин җыйнак. Муса ялгыз. Ник борчулы.

Муса. «Хаин!..» Әлбәттә, алар хаклы... Иртәгә тагын чыгыш ясарга, йөрәгеңне, бөтен яшьлегеңне биргән... синең өчен ин изге булган нәрсәне пычратырга, үз Ватаныңа яла ягарга?.. Юк! Җитте! Булдыра алмыйм... Кадерлеләрем минем... Нинди авыр газаплар чиккәнемне белсәгез иде сез! *(Пауза.)* Ә шулай да кирәк. Кирәк. Чыгыш ясамыйча булмый. Мин сөйләрмен аларга... *(Өстәл янына утыра да яза башлый.)* Сөйләрмен...

Ишек шакыйлар.

Муса *(язуында дәвам итеп)*. Керегез.

Сәйфуллин *(кереп)*. Мөмкинме?

Муса. Нигә сонладың?

Сәйфуллин. Көчкә килеп җиттем. Адым саен патрульләр. Телеграф янына тагын ике зенитка куйганнар.

Муса. Беләм. Син әзерме?

Сәйфуллин. Әзер.

Муса *(документ биреп)*. Мә ал һәм хәзер үк юлга чык.

Сәйфуллин *(укый)*. «Шәрәфетдинов Касыйм...» *(Мусага.)* Бу минме инде?

М у с а. Әйе.

С ә й ф у л л и н *(укуын дәвам итә)*. «Газета корреспонденты... Татар легионы частьларына... әлемтә өчен... Алмашев». Нинди матур кул куйган.

М у с а. Кайчан китәсең?

С ә й ф у л л и н. Биредән туп-туры вокзалга.

М у с а. Үзеңне сакла. Дусларыңның язмышларын исеңдә тот. Безнең яшәү-яшәмәвебез турында гына сүз бармый. Кирәк икән, без үләрбез. Ләкин сатлык исемең күтәреп үлүе авыр.

С ә й ф у л л и н. Мин сак булырмын. Бик сак булырмын. Фронт сызыгын чыккан чагымда тын да алмам хәтта. Ачка интегермен, әмма тотылу хәвефе булган җиргә аяк атламам.

М у с а. Бәхетле син, Шәрәф.

С ә й ф у л л и н. Әйдә, бергә китәбез, Муса.

М у с а. Юк, Шәрәф, мөмкин түгел бу. Мин монда кирәк хәзер. Алмашевларның мәкерле планнарын өзү өчен кирәк. Иртәгә дүртенче батальонга барам. Алмашев белән барабыз. Чыгыш ясаячакмын... *(Пауза.)* Мин аларга әйтәчәкмен: «Безнең илебезне көчле һәм куәтле итәргә вәгъдә иткән бөек Гитлерга хөрмәт һәм дан!» Шуннан тыңлаучыларны югарыга, зәңгәр тасма булып сузылган Идел өстенә күтәрермен. Аларга мин авыллар, шәһәрләребезне, кырлар һәм күлләребезне, чәчәккә күмелгән болынларыбызны күрсәтермен. Әйтермен: «Күрегез, нинди бай һәм гүзәл ул безнең туган ил. Бер чигеннән икенче чигенә кадәр меңнәрчә километр. Ул безнең тырыш, хезмәт сөюче кулларыбызны сагына... Туган илебез өчен сугышка әзер булыйк. Тешләрегезне кысыгыз да коралларыгыздан яхшы итеп атарга өйрәнегез... «Шуннан мин аларны кулларыннан җитәкләп өйләренә алып кайтырмын, бакчаларына алып кереп, балалары үстергән алма агачы төбенә утыртырмын да яннарына балаларын, ха-

тыннарын һәм барлык туганнарын алып килермен. Әйтермен: «Менә кемнәр көтә сине. Алар өчен җанны да аямаска мөмкин. Нык булыгыз, дуслар, дошманны танырга һәм аны рәхимсез рәвештә кыйнарга өйрәнегез. Фюрер белеп торсын, хәлиткеч сәгатьләрдә безнең йөрәкләребез тетрәнмәс. Кулларыбыз хыянәт итмәсләр».

С ә й ф у л л и н *(тәэсирләнеп)*. Рәхмәт сиңа, дус.

М у с а. Ни өчен? Гитлерны мактаганым өченме?

С ә й ф у л л и н. Сизмәдем.

М у с а. Монысы менә начар, Шәрәф. Легиончылар бу исемне хәтерләрендә тотарга тиешләр.

С ә й ф у л л и н. Син бик, бик яхшы итеп әйттең.

М у с а. Белмим, белмим, Шәрәф... Поезд кайчан китә?

С ә й ф у л л и н. Ярты сәгатьтән.

М у с а. Алайса бар. Соңга калма.

С ә й ф у л л и н. Сау бул.

М у с а. Сәлам әйт. Безнең турыда барын да, барын да тулы итеп сөйлә. *(Кочаклашып үбешәләр.)*

Ут сүнә. Урам. Өйдән С ә й ф у л л и н чыга. Каршыга п а т р у л ь килә.

П а т р у л ь. Документларыгыз, һер лейтенант?

С ә й ф у л л и н. Рәхим итегез. *(Удостоверение бирә.)*

П а т р у л ь *(укый)*. Шәрәфетдинов Касыйм... *(Кире бирә.)* Бетте.

Икесе ике якка китәләр. Бераздан К л а у с белән Э л ь з а керә. Бераз эчкәннәр.

К л а у с. Кая алып барасың мине?

Э л ь з а. Син арыдың дамы әллә?

К л а у с. Бу тыкрыкларда буталып йөрүдән син нинди кызык табасың, Эльза?

Э л ь з а. Алайса, утырып торыйк. *(Парадный ишеге төбенә утыралар.)*

К л а у с. Монда без бер утырып торган идек инде.

Эльза. Әйе шул. Һәм син миңа иң беренче тапкыр нәкъ шушында мәхәббәт игълан иткән идең.

Клаус *(гаҗәпләнеп)*. Ну?!

Эльза. Әйе. Әллә онытың дамы?

Клаус. О, юк, ул онытыламы соң?.. Син, бәлки, минем аны тагын да бер тапкыр кабатлавымны телисеңдер?

Эльза. Әллә сиңа бик авырмы ул эш?

Клаус *(кочаклап)*. Кадерлем минем. Аһ, белсәң иде, ничек яратам мин сине. Матурларның да матуры син... Мин һәр көн синең тавышыңны гына тыңлап торыр идем.

Эльза. Бу сүзләрне син һәрбер кызга әйтәсеңме?

Клаус. Мин сиңа үз мәхәббәтемне исбат итәчәкмен әле. Сугыш бетү белән Украинада үземә илле гектар җир алачакмын. Юк, йөз гектар!.. Йорт һәм башка каралтылар. О, без әле шундый матур итеп яшәрбез... Мин йорт әйләнәбезгә чәчәкләр утыртачакмын, ә син...

Эльза. Отпускаң кайчан бетә?

Клаус. Алты көннән.

Эльза. Шулай ук тизме?

Клаус. Нишлисең бит. Сугыш!

Эльза. Батырым син минем, Зигфрид... *(Үбә.)*

Майор киеменнән Алексеев керә.

Алексеев. Торыгыз! Ни өчен өлкәннәргә честь бирмисез?

Клаус. Виноват, майор әфәнде, күрмәдем.

Алексеев. Документыгыз?

Клаус. Рәхим итегез.

Алексеев *(укып)*. Клаус Грабе... Унбиш көнгә отпускага җибәрелә. *(Документын кире биреп.)* Командирыгызга әйтегез: майор Даниэль сезгә биш сутка гауптвахта бирә.

Клаус. Тыңлыйм, майор әфәнде.

А л е к с е е в. Һәрвакыт исегездә тотыгыз: фюрер солдаты, нинди генә хәлдә булса да, өлкәннәрне күрергә тиеш. Барыгыз!

К л а у с. Тыңлыйм, майор әфәнде. *(Китә.)*

А л е к с е е в *(Эльзага)*. Гафу итегез, фрейлен, сезне дә борчыдым, ахры. Гаскәри тәртип барыннан да югарырак.

Э л ь з а. Сез хаклы, майор әфәнде. Хушыгыз. *(Китә.)*

Алексеев Эльза белән Клаусның киткәнен күзәтеп тора да өйгә керә. Пауза. Э л ь з а кире керә, аның артыннан К л а у с.

К л а у с. Эльза, тагын инде кая барасың?

Э л ь з а. Син бераз көт. Мин брошкамны төшереп калдырганмын.

К л а у с. Төкер. Мин сиңа яңаны бүләк итәрмен.

Э л ь з а *(эзли)*. Юк, кирәкми... Синеңчә ничек, әлеге майор немецмы?

К л а у с. Әйе... Аңарда Берлин диалекты.

Э л ь з а. Бик инде дөрес диалект. *(Брошкасын тапкан булып.)* Менә таптым.

К л а у с. Әйдә киттек!..

Китәләр.

Муса бүлмәсе яктыртыла.

А л е к с е е в белән М у с а кулларын бер-берсенең җилкәсенә салып сөйләшеп утыралар.

М у с а. Беләм, башкача мөмкин түгел. Һәм мин түзәм... Күңелем йомшарганын берәү дә әле күргәне юк. Ләкин син минем иске дустым... Берничә генә тамчы күз яшемне гафу итәрсең. *(Алексеевның тезенә башын куя да елый.)*

А л е к с е е в. Муса, син нәрсә, җитәр!.. Тыныч!..

М у с а. Әйе, әйе, син хаклы... Миңа тыныч булырга кирәк. Миңа бик тыныч булырга кирәк. Ләкин...

А л е к с е е в *(кесәсеннән газета чыгарып)*. Мә, укы.

М у с а. «Правда»? Каян килде бу сиңа?

А л е к с е е в. Советка каршы пропаганда өчен дип Геббельсның үз рөхсәте белән алабыз.

М у с а. Геббельс рөхсәте белән?! Хәтта ышануы кыен... Мәскәү исе аңкый.

А л е к с е е в. Син укы, укы!..

М у с а (укып). «Белоруссия партизаннары...»

А л е к с е е в. Менә монысын.

М у с а *(укый)*. «...Казан. Кызыл Армиянең соңгы җинүләре белән рухланып, Татарстан эшчеләре һәм колхозчылары хезмәт фронтында зур батырлыклар күрсәтә... Тымытык районы колхозчылары бер ай эчендә дәүләткә җиде мең пот икмәк тапшырдылар...»

А л е к с е е в. Тагын бер шатлык. Безне немец подпольесы белән бәйли алырлык бер кеше таптым. Тик әле аны сыныйсы, тикшерәсе бар. Мин сине киләсе атнага, чәршәмбе көн, унсигез сәгатьтә шәһәр паркы капкасы янында көтәрмен.

М у с а. Чәршәмбе көн, унсигез сәгать... Килермен.

А л е к с е е в. Ярый, хәзергә сау бул. *(Газетаны алып кесәсенә сала.)* Бик рәхәтләнеп тагын берәр сәгать утырган булыр идем дә, мөмкин түгел. *(Кул бирә.)*

М у с а. Ничек шатландырганыңны белсәң иде, Алеша.

Ут сүнә. Тагын урам күренеше. Муса Алексеевны озата чыга. А л е к с е е в китә. М у с а, ишек алдындагы баскычка утырып, уйланып кала.

М у с а.

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Алмаштырган илен»,— дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, мине сөйсәләр.
Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,

«Муса инде үлгән»,— дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.

Туфрак күмер тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне,
«Үлем» диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне?

Як-ягына карана-карана Анна-Мария керә.

Анна-Мария *(әкрен)*. Муса әфәнде.

Муса. Анна-Мария? Сез ничек биредә? Тәнлә...

Анна-Мария. Сезне кисәтеп куяр өчен.

Муса. Ни турында?

Анна-Мария *(каранып)*. Эльзадан сакланыгыз.

Муса. Сезнең дустыгыздан?

Анна-Мария. Әйе. Мин бүген генә белдем. Ул гестапода эшли.

Муса. Бик яхшы. Безнең бертөрле яшерен эшебез дә юк.

Анна-Мария. Бәлки. Мин тик була калса дип кенә... Мин сезне хөрмәт итәм. Мин генә дә түгел... Сез яхшы кешеләр. Мин сезнең исән калуыгызны телим. Сез миңа ышанмыйсыз?

Муса. Юк, мин ышанам сезгә, Анна-Мария...

Анна-Мария. Беләм, ышанмыйсыз. Кәрим дә шулай ук. Минем авызымнан гестапо дигән сүзне ишетү белән үк, янымнан китеп барды. Хәтта кем турында сүз барганны да белмәде. *(Елый.)* Ә бу... миңа шундый авыр. Минем абыем Рудольфны төрмәдә үтерделәр... Астылар аны. Әтиемне концлагерьга җибәрделәр... Унбиш елга. Ул заводта механик булып эшли иде.

Муса *(ягымлы)*. Ә хәзер ул кайда?

А н н а - М а р и я. Фронтта. Бәлки, үтергәннәрдер дә инде аны.

М у с а. Еларга кирәкми, Анна-Мария. Мин аңлыйм синең кайгыңны. Авыр сиңа... Башкаларга авыр булган кебек, сиңа да авыр.

А н н а - М а р и я. Мин беләм, сезгә дә шулай... Ләкин Эльза... Гестапо... Бу коточкыч. Аңлыйсынмы, коточкыч. Ярый, барысы өчен дә зур рәхмәт.

А н н а - М а р и я китә.

М у с а *(аның артыннан карап калып)*. Ышанам, мин ышанам сиңа. Анна-Мария.

П ә р д ә

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

ҖИДЕНЧЕ КАРТИНА

Редакция. А л и ш өстәл янына баскан да зур борчылу белән кабинетта барган сөйләшүләрне тыңлый. Б а т ы р ш и н керә дә Алишка берничә листовка бирә.

Б а т ы р ш и н. Яшер. Һәрбер газета эчендә бер листовка.

А л и ш. Барысы шушымы? *(Бюст эченә эшерә.)*

Б а т ы р ш и н. Әйе. Туктатырга туры килде. Ул биредәме әле?

А л и ш. Биредә.

Б а т ы р ш и н. Нәрсә кирәк аңа? Ни өчен әле ул көтмәгәндә килеп чыккан?

А л и ш. Мине дә шул борчый.

Б а т ы р ш и н. Ни дә булса сизенделәрме әллә?

А л и ш. Әйтә алмыйм. Ләкин алар бүген шундый игътибарлы... Нәрсәдәндер шикләнәләр, ахры.

Батыршин. Эзгә төшсәләр, якты дөнья белән бәхилләшергә генә кала.

Алиш. Кайчан да булса бер дөнья белән бәхилләшербез анысы. Ләкин, нинди генә нужалар күрсәк тә, безгә яшәргә кирәк әле. Ике ай, ике атна, ичмасам ике генә көн булса да... Инде без Оксман заводында эшләүче хәрби әсирләр белән дә элемтә урнаштырдык. Алексеев зур ярдәм күрсәтә. Берничә көннән немецлар подпольесы белән бәйләнешкә керәчәкбез, ә аннан... фашистлар империясе вулкан өстендә... Без легионны таркатачакбыз. Тик безгә нинди тә тирәнрәк яшеренергә кирәк.

Батыршин. Шул ук вакытта эшне дә туктатмаска...

Алиш. Әйе. Андый-мондый хәл булганда, качу өчен безгә тагын берничә ышанычлы адрес табарга кирәк...

Батыршин. Моны үз өстемә алам. Альфред ярдәм итәр дип уйлыйм.

Алиш. Ни өчен бик күңелсез син бүген?

Батыршин. Болай гына...

Алиш. Я әле, яшермичә генә сөйлә әле.

Батыршин. Эх, Алиш абый!.. Ул гестапода эшли икән бит.

Алиш. Кем?

Батыршин. Анна-Мария.

Алиш. Каян белдең?

Батыршин. Үзе әйтте.

Алиш. Үзе? Алдамыйсыңмы?

Батыршин. Ул да, Эльза да. Нишләргә инде хәзер?

Алиш. Анна-Мария безнең эшебез турында берни дә белмиме?

Батыршин. Белми. Ләкин кызыксына. Күбрәк Муса абый белән. Мин буып үтерәчәкмен аны.

Алиш. Тукта... Үз-үзләрен фаш иткән агентларга нәрсә буласын беләсеңме син?

Батыршин. Минем өчен хәзер барыбер...

Алиш. Юкка. Аларны аталар...

Батыршин. Атсалар ни дә миңа хәзер, атмасалар ни?

Алиш. Ә син уйлап кара. Әгәр ул үзенең томерен шундый куркыныч астына куйган икән инде, димәк, аңа яшәүдән дә кыйммәтрәк нәрсә бар дигән сүз. Бу турыда уйламыйча мөмкин түгел. Ә хәзер бар типографиягә. Борыныңны салындырма. Миңа калса, син әйбәт кызны яратасың, Кәрим.

Батыршин Алишны үбә дә йөгереп чыгып китә.

Менә тиле!..

Унгляуб белән Янгузов керә.

Унгляуб. Бүгенге номер чыктымы әле?

Алиш. Чыкты. Тик әле типографиядә.

Унгляуб. Миңа бер-ике экземпляр алып килсәгезче.

Алиш. Хәзер. *(Китә.)*

Унгляуб *(Янгузовка)*. Ашыгыгыз. Сезнең карамакта алты минут.

Янгузов *(өстәл тартмаларын һәм башка җирләрне актарып)*. Бик гажәп инде бу, һер Унгляуб. Сез бит бөтен редакцияне ачыктан-ачык тенти аласыз, һәрвакыт күзәтеп тора торган кешеләр куя аласыз... Ә сез нигәдер тәкәллефләнәсез...

Унгляуб. Сезнең һәркайсыгызны судсыз-нисез, һичбер тикшерүсез асып куярга хакыбыз бар, ләкин без немецлар — югары цивилизация кешеләре...

Янгузов *(эзләнүендә дәвам итеп)*. Бу эштә аның кулы уйнагандыр дип башыма да китерә алмыйм.

Унгляуб. Балаларча уйлыйсыз. Безнең белән эшләргә Муса Җәлил ни өчен бик тиз риза булды? Сез ки-

ңәш биргән өчен генәме? Ни өчен ул бик тырышып-тырышып батальоннарга йөри? Шәһәрдә булса, көн аралаш редакциягә килә: Юк, сез уйлаганга караганда күп мәртәбәләр катлаулырак кеше ул:.. Шуның өчен аның артыннан күзәтүне тагын да көчәйтегез. Соңгы вакыйгалар турында хәзергә беркемгә дә берни дә әйтмәгез. Аңладыгыз?

Янгузов. Аңлыйм.

Янгузов листовкалар яшерелгән жиргә якынлаша. Нәкъ шул вакыт Алиш керә.

Алиш. Газеталар сораган идегез. *(Унгляубка бирә. Калганнарын өстәлгә куя.)*

Унгляуб. Рәхмәт. Борчыганым өчен гафу итегез. Хушыгыз. *(Янгузовка.)* Әйдәгез, миңа фотолаборатория-не күрсәтегез. *(Китәләр. Пауза.)*

Кызу гына Муса керә.

Муса *(кабинетка ымлап)*. Андалармы?

Алиш. Чыктылар.

Муса *(жиңел сулап)*. Ох! *(Күтәренке күңел белән.)* Алиш, беренче батальон, офицерларны кырып бетереп, үзебезнекеләр ягына чыккан... Чыккан!.. Сигез йөз сугышчы Ватанга кайттылар, димәк. Бу турыда тиз генә барлык легионнарга хәбәр итәргә кирәк.

Алиш. Дөрес.

Муса. Ал кәгазь, листовка яз. Яз: «Совет Армиясе ягына чыккан чакта гитлерчы бандаларга каршы сугышта унҗиде иптәшебез батырларча һәлак булды. Мәңгелек хөрмәт һәм дан аларга». Булдымы?

Янгузов керә. Алиш, берни дә булмагандай күренергә тырышып, язуын дәвам итә.

Янгузов. Исәнмесез, Муса әфәнде. Нигәдер сез бу арада сирәк күренәсез.

Муса. Бушый алмыйм.

Янгузов. Нинди яңалыклар бар?

Муса. Берничә яңа корреспонденция алып кайттым.

Янгузов. Мин сезгә соңгы мәртәбә үземнең хезмәтемне тәкъдим итәм. Риза булмасагыз, ялгызым хәрәкәт итәчәкмен.

Муса. Анысы сезнең үз эшегез.

Янгузов. Сезнең өчен әллә шагыйрь Муса Җәлил Ватанын сатучы хаин дигән хурлыклы исемне күтәрү берни дә түгелме?.. Әминә ханым белән Чулпан турында уйлагыз. Алар ни хәлдә калачак?

Муса *(узен тыныч тотарга тырышып)*. Әгәр сезгә тормышыгыз кыйммәт булса...

Алиш *(Янгузовка)*. Китегез биредән... Яхшырак булыр.

Янгузов. Сез юкка кызасыз. *(Китә.)*

Муса. Була бит дөньяда кешеләр...

Алиш. Кешеме соң әле ул. Шунысы шикле.

Хәсәнов, Салмеев, Мәхмүтов керәләр.

Хәсәнов *(Мусага)*. Ярый әле син биредә икәнсең.

Муса. Исәнмесез, офицер әфәнделәр. Сезнең ни йомыш, Мәхмүтов?

Мәхмүтов. Мин... Хәсәнов иптәш белән... мм... әфәндеме шунда, ничек дип әйтергә дә белмим... бергәләп газета алырга килдек. Өченче батальон өчен.

Хәсәнов. Хәзер ул алачак. Безнең яңа иптәшебез.

Муса. Шәп, бик шәп, Мәхмүтов. *(Кулын кыса.)* *Алишка мөрәҗәгать итегез.*

Мәхмүтов белән Алиш кул кысышып күрешәләр.

Хәсәнов *(кызу-кызу пышылдап)*. Батальонга Алмашев белән Унгляуб килде. Алар белән эсэс отрядлары. Без могҗиза белән генә ычкынып калдык. Бер минут соңласак, чыгармыйлар иде.

Муса. Ни өчен килгәннәрен сизенмәдегезме?

Салмеев. Юк...

Хәсәнов. Ниндидер бер җитди хәл булса кирәк.

Муса. Димәк, листовкаларны бүген биредә калдырып торырга кирәк.

Хәсәнов. Юк, без аларны ничек тә алып барырбыз. Бүген алар, минемчә, башка көннәргә караганда да кирәгрәк анда.

Алиш *(Мәхмүтовка листовка куелган газеталар бирә)*. Бүгенге номерлар. *(Әкрен.)* Саграк булыгыз.

Мәхмүтов. Беләм. Шайтанның үзе дә сизмәс. (Кычкырып.) Без, легионерлар, үз газетабызны бик яратабыз. Рәхмәт сезгә, Гумеров әфәнде. *(Барына да честь бирә.)* Хушыгыз, әфәнделәр. *(Ишек төбенә җиткәч, әкрен.)* Иптәшләр!.. *(Китә.)*

Муса *(Хәсәновка)*. Мин аларның ни өчен утлы табага басканнарын беләм.

Хәсәнов. Ни өчен?

Муса. Фронтка җибәрелгән безнең батальон, немец офицерларын үтереп, үзебезнекеләр ягына чыккан.

Хәсәнов. Менә бу шәп! Ишетәмсең, Салмеев!

Салмеев. Әйе, әйе... Бик шат.

Анна-Мария белән Эльза керә.

Эльза.
Анна-Мария. } Хәерле көн, әфәнделәр.

Бар да. Хәерле көн. Исәнмесез!

Эльза *(чемоданын ачып сигарет тәкъдим итә)*. Рәхим итегез!

Анна-Мария *(Мусага)*. Алыгыз.

Муса *(бер пачка ала да акча түли)*. Рәхмәт. Әйбәт сигаретлар.

Эльза. Ой-о... Анна-Мария үзе дә әйбәт кыз.

Муса *(Алишка)*. Ә сез, күрәм, немец кызларын яратмыйсыз?

Алиш. Юк, нигә? Тик мин тартмыйм.

Эльза. Бәлки, офицер әфәнделәр алыр? *(Хәсәнов белән Салмеев янына килә.)*

Газеталар тотып Батыршин керә.

Батыршин. Бу яңа батальон өчен. *(Мусага.)* Минем арттан күзәтәләр.

Муса. Сер бирмә. Газеталарыңны куй да Анна-Мария янына бар. Сагынган ул сине.

Батыршин *(Анна-Мария янына килеп)*. Исәнме, хәсрәтем минем.

Анна-Мария. Узең нихәл, шатлыгым минем.

Батыршин. Синең өчен борчылам, Анна-Мария. Яратам сине.

Анна-Мария. Мин дә...

Бу вакыт Алиш газеталарны урнаштыра. Янгузов керә.

Янгузов. Хәерле көн, кызлар һәм хөрмәтле әфәнделәр.

Бар да. Хәерле көн!

Янгузов. Яңа газеталар?

Алиш. Әйе.

Янгузов. Бирегез әле.

Алиш газета бирә.

Батыршин *(Янгузовның игътибарын газетадан читкә юнәлдерергә теләп, җырлый)*.

О Мари, о Мари,
Я навеки тобою пленен...

Янгузов *(газетаны куя да Анна-Мария янына килә)*. «О Мари, о Мари...»

Ул матур гына жырлый, аңа кул чабалар.

Эльза *(Мусага)*. Ә бу яңа сигаретлар — «Язгы чәчәк» дип атала.

Муса. Яхшы. *(Сигарет тартмасыннан укып):*

Май ае тик елга бер кат чәчәк ата,
Мәхәббәт тик — гомергә бер генә...

Эльза. Дөрес. Мәхәббәт тик — гомергә бер генә. Шуның өчен ул кадерле дә. Сезне мин яраткан да булыр идем, ләкин сез шундый горур...

Муса. Бәлки, киресенчәдер.

Эльза. Шуның өстенә йөрәгемне башка берәүгә вәгъдә иттем. Ул кеше миңа зур бер батырлык күрсәтергә булды.

Янгузов. Һәм күрсәтер дә... *(Бүлмәсенә керә.)*

Эльза. Карарбыз. *(Мусага.)* Ә сез яраткан кызыгыз өчен үзегезне корбан итәргә булдыра аласызмы?

Муса. Белмим. Ул турыда беркайчан да уйлап караганым юк.

Эльза. Ничек инде алай? Сез шагыйрь. Ә шагыйрьләр безне гүзәллеккә, бөеклек һәм фидакарьлеккә чакыручылар.

Муса. Шуңа карамастан, аларга да кайчак күңелсез дә, куркыныч та була.

Эльза. Сез миңа ошаганнан-ошый барасыз. *(Янгузов кереп киткән бүлмәгә карап ала.)* Әгәр дә ул сүзендә тормаса, йөрәгемне сезгә бирәчәкмен.

Муса. Рәхмәт. Ләкин, кадерле Эльза, аның белән мин нишләрмен соң?

Эльза. Йөрәк үзе әйтер.

Һава тревогасы.

Алиш. Безнекеләр сәлам китерәләр.

Янгузов *(ишектә күренеп)*. Һава тревогасы! Хә-

зер үк бомбоубежищега! Үзегез белән кызларны да алыгыз. Тизрәк!

Бар да кызу гына чыгалар.

(Салмеевны туктатып.) Сабыр ит.

Аларның сөйләшүе самолетлар гүләве, бомба һәм артиллерия тавышлары астында бара.

Утырыгыз!

Салмеев ике кулы белән башын тотып урындыкка утыра.

Синең белән азап чигү туйдырды мине. Хәзер инде ыкмык итәргә урын юк. Сезнең батальон, офицерларны үтереп, Кызыл Армия ягына чыккан. Беләсеңме шуны? Шәп тәрбияләгәнсез! Сезнең турыда мәсьәлә хәл ителгән хәзер. Тикшереп, суд-фәлән ясап тормаячаклар. Эт урынына атып үтерәчәкләр.

Салмеев бер ноктага карап калган да дәшми, тик утыра.

Я, нинди дә булса яңа хәбәр сөйли аласыңмы? Муса һәм аның компаниясе турында кайчан материал бирәсең? Үлемнән котылу өчен бу сиңа бердәнбер юл. Нәрсә әйткәнне аңладыңмы? Нигә дәшмисең, сволочь! Күпме көтәргә сине?

Салмеев *(калтыранган куллары белән бюст эченә яшерелгән газета һәм листовкаларны алып)*. Менә... Тик мин... Мин берни дә белмим.

Янгузов. Листовка? *(Укый.)* «Иптәшләр! Гитлерчы юлбасарлар һәм сатлык Алмашевлар сүзенә алданып Ватаныбызга хыянәт итмәгез. Үз туганнарыгызга каршы бер генә пуля да атмагыз. Фронтка барып житү белән Совет Армиясе ягына чыгыгыз. Җиңү көнебез якын. Тиздән Гитлер Германиясе тар-мар ителәчәк. Исегездә тотыгыз: Ватанга хыянәт итүчеләр дошманнар

белән берәүдән көчемгә тартылачаклар. Совет патриотлары штабы». Ха!.. Анысын әле карарбыз, кем кемне көчем итәр. *(Салмеевка)*. Җитәр сина калтыранырга. Кыяфәтеңне тәртипкә китер дә, бар тизрәк кит. Тревога беткәч, иң соңыннан гына кайтырсың. Башка бомбоубежищеда булдым, диярсең.

Салмеев китә.

Мин үз сүземдә тордым, фрейлен Эльза.

Отбой. Янгузов үз бүлмәсенә кереп китә. Пауза. Эльза, Анна-Мария һәм Батыршин кайталар.

Янгузов *(ишектә күренеп)*. Үзегезне ничек хис итәсез, сөекле туташлар?

Эльза. О, Батыршин искиткеч уңган кавалер.

Янгузов. Эльза, бер генә минутка.

Эльза кабинетка кереп китә.

Батыршин. Син бик курыкмадыңмы, Анна-Мария?

Анна-Мария. Юк, янымда син бар идең ич.

Батыршин. Мин тревоганың озак, бик озак дәвам итүен теләгән идем.

Анна-Мария. Мин дә...

Эльза чыга.

Эльза. Анна-Мария, безгә китәргә вакыт.

Анна-Мария. Киттек. Сау бул, Кәрим.

Батыршин. Мин озата барам. Почмакка кадәр.

Чыгарга баралар, Муса, Алиш һәм Хәсәнов керә.

Муса. Китәсез дәме?

Эльза. Әйе, бәхет телим сезгә, Муса әфәнде.

Китәләр.

Муса *(Батыршинга)*. Син кая җыендың?

Батыршин. Кызларны озатам.

Муса *(туктатып)*. Кавалер! Төзәтен бераз. *(Әкрен.)* Ерак барма. Кирәк булачаксың.

Батыршин. Мин бик тиз. *(Китә.)*

Янгузов чыга.

Янгузов. Әфәнделәр, минем шуны әйтәсем килә... Начар эшлисез. Әйе, бик начар. Сезгә мин үземнең ярдәм кулымны суздым, бергәләп эшлик, дидем. *(Мусага.)* Ә сез кире кактыгыз. Хәзер инде менә үзегез генә җавап бирегез. Сезне саттылар! Менә... *(Листовканы күрсәтә.)* Дәшмисез? Мине читкә этәрдегез, ә сатлык җанны кочагыгызга алдыгыз.

Салмеев керә. Янгузов аны күрми.

Сезне Салмеев сатты. Листовканы миңа ул бирде. Ләкин мин аны сезнең күз алдыгызда ук ертып ташлыйм. Чөнки минем хаин буласым килми. *(Ерта).*

Салмеев. Ничек телең бара?! Бу син... син... син!.. Ышанмагыз аңа... ышанмагыз!.. Бу ул... Ул мине... Көн саен эзәрлекләп...

Янгузов. Әйдә, сөйлә, кешегә яла ягу ансат бит ул.

Салмеев. Ул мәкерле, усал кеше... иптәшләр!

Янгузов. Тагын кемгә донос ясадың? Әйт хәзер!

Салмеев. Ах, син, кабахәт җан... *(Янгузовка ташлана.)*

Янгузов *(пистолет белән нык итеп чигәсенә сугып)*. Үләксә.

Салмеев егыла. Пауза.

Муса. Самосуд ясарга кем сиңа хокук бирде? Хаиннарны без үзебез хөкем итәбез.

Янгузов. Сөйләргә ирек бирегез...

Муса. Җинаятеннең шаһитен юк итәргә тырыш-

тың? Үз гаебеңне аңа ябарга. Синең сатлык жан икәнең безгә күптән билгеле. Син безне генә түгел, Ватаныңны, гаиләңне саттың.

Янгузов. Миңа андый сүзләр сөйләргә сез...

Батыршин керә.

Муса. Ватанга хыянәт итүчеләрне без Советлар Союзы исеме белән иң югары җәзага хөкем итәбез. Үлем хаинга! Совет патриотлары штабы. Шулаймы?

Бардa. Дөрес!

Янгузов *(пистолетын төзәп)*. Якын килмәгез! Атам! *(Йөгереп тәрәзә янына бара.)* Тәрәзәдән ташланам.

Батыршин *(ыргылып бара да пистолетын каерып ала)*. Ташлан, гад!

Янгузов *(Муса алдына тезләнеп)*. Муса! Кызганыгыз!

Муса ишарә ясый. Батыршин белән Хәсәнов Янгузовның авызын томалап, кабинетка өстерәп кертәләр. Пауза.
Бераздан Хәсәнов белән Батыршин кире чыга.

Хәсәнов. Хөкем карары үтәлде.

Алиш. Инде нишлибез?

Муса. Хәзер үк төрлегез төрле якка таралыгыз. Син, Хәсәнов, батальонга кайт. Син, Батыршин, итек чистартучыларда яшерен. Алиш, син дә... Янгузов белән Салмеев турында берни дә белмисез. Листовкаларны юк итәбез. Ул эштә сезнең бер катнашыгыз да юк. Аларны чыгаручы һәм таратучы кеше — мин ялгызым.

Батыршин. Мин моңа риза түгел.

Хәсәнов. Моңа һичкем ышанмаячак та.

Батыршин. Мин беркая да китмим. Барын да үз өстемә алырга сүз бирдем. Синең хакың юк, Муса абый.

Муса. Минем кушканны үтәргә приказ бирәм.

А л и ш. Сиңа биредә калырга ярамый, Муса. Дөресме, иптәшләр?

Б а р д а. Дөрес.

А л и ш. Иң беренче булып сиңа китәргә кирәк.

Х ә с ә н о в. Әлбәттә.

М у с а. Бу минем...

А л и ш. Син безнең карарга буйсынырга тиеш.

М у с а. Ярый, буйсынам. Бәйләнешне Алексеев аша булдырырбыз. Аңлашыламы?

Б а р д а. Аңлашыла.

М у с а. Тик берәм-берәм чыгарга. Киттек. Сау булыгыз, иптәшләр.

Кызу гына берәм-берәм чыгып китәләр. Салмеев ыңгыраша. Әз генә күтәрелә дә тагын егыла. У н г л я у б йөгереп керә.

У н г л я у б. Берәү дә юк... Качканнар! Янгузов!.. Янгузов! *(Кабинетка юнәлә.)*

А л м а ш е в йөгереп керә.

А л м а ш е в. Кайда алар? *(Кабинетка ташлана. Коты очып, арты белән чигенә-чигенә чыга да урындыкка утырып.)* Я алла...

У н г л я у б *(кабинетка керә. Телефонда).* Алло! Алло! *(Чыгып.)* Өзгәннәр, телефонны өзгәннәр!

А л м а ш е в. Я алла!..

П ә р д ә

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

СИГЕЗЕНЧЕ КАРТИНА

Гестапо. Тикшерү-сорау алу бүлегендә зур гына бүлмә. Стенада канатларын җәйгән каракош сурәте. Ике ишек. Сәхнәдә полковник Г р а б е һәм У н г л я у б.

Грабе *(телефонда)*. Юк, кабул итә алмыйм. Сезгә биредә күренергә ярамый... Анысын аңлыйм... Ярый, бераз сабыр итегез. *(Трубканы куя. Унгляубка.)* Дәвам итегез.

Унгляуб. Барлыгы җитмеш алты кеше кулга алынды. Шулардан Совет патриотлары оешмасында катнашучылар егерме сигез кеше.

Грабе. Безгә билгеле булганнары, ә билгеле булмаганнары күпме?

Унгляуб. Тикшерүне дәвам итәбез.

Грабе. Алиш белән Батыршин кайда?

Унгляуб. Аларны әле эзлиләр.

Грабе. Салмеев ничек?

Унгляуб. Үләр алдыннан аңына килде, ләкин бер сүз дә әйтмәде.

Грабе. Хайван!

Унгляуб. Җәлил аларны, төркем-төркем итеп, бары тик үзләре бәйләнештә булган кешеләрне генә белерлек итеп оештырган.

Грабе. Димәк, Җәлилнең телен язмый торып, йомгакны ахырына кадәр сүтә алмыйбыз. Ә ул дәшми. Дәшми! Фюрер фронтка гаскәр таләп итә, ә без үти алмыйбыз. Татар легионы большевистик агу белән сугарылган... Югары баш командование штабына мин нәрсә дип хәбәр итәргә тиеш?

Унгляуб. Телен яздырырбыз аның, herр оберст.

Грабе. Миңа тагын сүзегез бармы?

Унгляуб. Хәзергә юк.

Грабе. Менә бу ишектән чыгыгыз. Биредә шефыгыз белән очрашырга ярамый сезгә.

Унгляуб. Сөйләмәгез миңа аның турында, herр оберст. Җаным чиркана. Мин, барон фон Унгляуб, данлыклы тевтон рыцарьлары токымы, дүрт орден кава-

леры, шул кыргый татар алдында баш иеп торырга тиеш. Юк, артык түзә алмыйм моңа, аңлагыз хәлемне.

Грабе. Кадерлем фон Унгляуб, бик аңлыйм сезне, ләкин... нишлисең... Политика! Чыдарга туры килә.

Унгляуб. Барын да аңлыйм. Ләкин бу кадәр мәсхәрәгә сабырлыгым җитми.

Грабе. Хәзер инде күп калмады, ышанығыз.

Унгляуб. Белмим инде, белмим... Хушыгыз! *(Китә.)*

Грабе *(телефон трубкасын алып)*. Анда фрейлен Эльза көтә. Бирегә кертегез.

Эльза керә.

Грабе *(исәнләшеп)*. Күптән инде сезне күргәнем юк.

Эльза. Кем гаепле? Сез әле бүген дә мине кабул итәргә теләмәгән идегез.

Грабе. Нишлисең бит, хезмәт урыныбыз шундый.

Эльза. Тиздән бер ел.

Грабе. Ай-яй-яй, вакыт ничек тиз уза. Матурлангансыз...

Эльза. Сезнең, ахры, эчегез *поша* аңа.

Грабе. Әйе... шундый *поша*, *мөгаен*, урыныгыздан да чыгарырмын.

Эльза. Ни өчен?

Грабе. Һәркөн күрергә мөмкин булсын өчен.

Эльза. Ах!.. Тик куркам, тәҗрибәле бер кешегезне югалтырсыз, ә көн саен мине күрергә барыбер вакыт таба алмассыз.

Грабе. Нинди яңа хәбәрләрегез бар?..

Эльза *(ридикюленнән кәгазь һәм фоторәсем чыгарып)*. Рәхим итегез.

Грабе *(карап)*. Менә бу шәп, шәп!

Эльза. Батыршинны тоттылармы әле?

Грабе. Әзлиләр.

Эльза. Анна-Марияны күзәтегез.

Грабе. Сезнең дустыгызны?

Эльза. Әйе.

Клаус керә.

Клаус. Гафу ит, әти! *(Эльзаны күреп.)* Сәламәтлек телим, туташ...

Грабе. Ни өчен син һичбер хәбәрсез-нисез килеп керәсең, Клаус?

Клаус. Гафу ит, әти! Мин сине үбеп чыгар өчен генә дип кердем.

Грабе. Китәсең дәме?

Клаус. Әйе.

Грабе. Җылы оекбашлар алдыңмы?

Клаус. Алдым.

Грабе. Менә сиңа тагын биш йөз марка. Сорауларың, үтенечләрең бармы?

Клаус *(Эльзага күз ташлап алып, әкрен)*. Мине бу пычрак эш бик туйдырды, әти... Кая да булса бирегә, Берлинга якынрак тирәгә күчерү чарасын күрсәң икән... Әнигә якынрак, сиңа якынрак җиргә дигәнем.

Грабе. Бераз сабыр ит. Хәзергә әле моны эшләү кыен. Ә соңгарак күчерербез... Әлбәттә, күчерербез...

Клаус. Рәхмәт, әти. Ярый, бәхет телим. Хушыгыз!

Грабе. Хәерле юл, улым...

Клаус китә.

Авыр аңа бичарага... Әнисен бик ярата ул... Дәвам итегез.

Эльза. Минемчә, Анна-Мария Батыршин белән очрашырга тиеш.

Грабе. Менә ничек. Аңлашыла. Ә сез Җәлил белән очрашырга телисезме...

Эльза. Әйе. Мин аны җиңә алырмын шикелле.

Грабе. Нәрсәгә таянып әйтәсез моны?

Эльза. Яшь һәм матур хатын нәрсәгә таяна ала?

Грабе. Юк! Бу номер аның өчен түгел... Сау булыгыз, сөеклем. А, юк, теге бүлмәдә бераз көтеп торыгыз. Сезгә аныкларга туры киләчәк. *(Рәсемне күрсәтә.)*

Эльза. Мөмкин. *(Чыга.)*

Грабе *(телефон трубкасын алып)*. Алмашевны.

Алмашев керә.

Утырыгыз.

Алмашев. Рәхмәт. *(Утыра.)* Мин ышанам, һер оберст, әгәр дә без...

Грабе. Әгәр йомгак сүтелми кала торган булса, сезгә бик начар булачак, Алмашев. Аңлашыламы?

Алмашев. Әйе-әйе, һер оберст, мин бит һәрвакыт әйтә килдем...

Грабе. Сез берни, берни дә аңламыйсыз. Империя үзәге Берлинда листовкалар! Большевистик пропаганда! Штаб! Совет патриотлары! Сезнең күз алдыгызда легионны таркаталар... Ә сез... Сезнең аркада безнең һөҗүм өзелә... Безгә бүген һәрбер солдат кыйммәт... Күзегез кайда иде сезнең? Карт шайтан! Борчак чүмәләсе!..

Алмашев. Һер оберст...

Грабе. Бәлки, үзегез дә алар белән бергә...

Алмашев. Сез мине тәхкыйрь итәсез...

Грабе. Мин аны тәхкыйрь итәм... Ха-ха-ха!

Алмашев. Мин президент. Фюрерга жалоба белән барачакмын.

Грабе. Кәмит уйнамагыз! Фюрерга барып җиткәнче сезнең башыгызны пуля тишеп узачак. *(Сигарет тәкъдим итеп.)* Талашудан безгә мәгънә юк. Әйтегез, сезнеңчә, кем аларның башлыгы?

Алмашев. Муса Җәлилдер дип уйлыйм.

Грабе. Барлыгы ничә кеше? Йөз? Ике йөз? Бәлки, алар немец коммунистлары белән дә бәйләнештә булганнардыр?

Алмашев. Боларның барын да Муса Җәлилдән сорашып белергә мөмкин.

Грабе *(телефон трубкасын алып)*. Җәлилне кертегез. *(Алмашевка.)* Аның белән инде мин өч көн, өч төн азапланам. Һичнәрсә әйттерә алганым юк. Хәзер сез сөйләшеп карагыз. Барын да, барын да вәгъдә итегез. Нинди бәһа белән булса да телен ачтырыгыз. Белегез, сезнең киләчәк язмышыгыз шуңа бәйләнгән.

Алмашев. Яхшы.

Кул-аяклары богауланган Мусаны алып керәләр. Сәхнәдәгеләр аны күрмәмешкә салышып, сүзне дәвам итәләр.

Грабе. Мин беләм, Алмашев әфәнде, сез йомшак күңелле кеше. Аны кызганасыз, акларга тырышасыз, э ул...

Алмашев. Ышаныгыз миңа, һер оберст, ул акыллы кеше. Аны, мөгаен, башкалар шундый юлга тартканнардыр.

Грабе. Бәлки, бәлки... *(Мусага карап.)* Менә үзе дә. Утырыгыз, Җәлил әфәнде. Сөйләшегез. (Чыга.)

Алмашев *(чын күңелдән)*. Сез нәрсә эшләдегез, Муса әфәндә? Я, кемгә кирәк иде инде бу? Моның шундый күңелсезлек белән бетәрен белмәдегезмени? Сез бит акыллы кеше. Мин хөрмәт итәм сезне. Дөрес, безнең дөньяга карашларыбыз төрле-төрле, ләкин безгә халкыбызның язмышы бар нәрсәдән дә өстенрәк.

Муса дәшми.

Әнә, немецлар белән руслар үзара сугыша бирсеннәр. Безгә дә милләтебез турында кайгыртырга кирәк. Татар халкы өчен мин сезне коткарырга дип килдем.

Муса. Юкка вакытыгызны әрәм итәсез.

Алмашев. Үзегезне һәлакәткә дучар итмәгез, Муса әфәнде.

Муса. Һәлак булырга дучар ителгән кешеләр сез ул — сатлык Алмашевлар. Халык исеме белән юкка сату итмәгез. Ул инде сезне күптән үлемгә хөкем итте. Сез тере мәетләр.

Алмашев. Минем ярдәмемне кире кагып сез...

Муса *(кычкырып)*. Һер оберст!

Грабе керә.

Президент әфәнде белән минем сүзем бетте. Аны чыгарып җибәрегез.

Алмашев *(ярсып)*. Ах, эттән туган малай!.. Сине үзем буып үтерәм...

Грабе. Чыгыгыз!

Алмашев. Үз кулларым белән...

Грабе. Чыгып китегез!!

Алмашев чыга. Пауза.

Шундый хөрмәтле кеше белән уртак тел таба алмавыгыз бик кызганыч. *(Пауза.)* Икенче августта сез Оксман заводында булгансыз. Анда эшләүче татар хәрби әсирләре өчен газеталар алып баргансыз. Шулаймы? *(Муса дәшми.)* Ләкин сезне анда татарлардан да бигрәк руслар кызыксындырган. Шулай түгелме? Тугызынчы июньдә кич алты сәгатьтә сез генерал Власовның полк мәктәбе офицеры майор Алексеев белән очрашкансыз. Шулаймы? *(Муса дәшми.)* Аның белән нинди темага сөйләштегез?.. Сезгә ул нәрсә бирде?.. Әйтмисез? *(Звонок бирә. Солдатлар Алексеевны алып керәләр.)* Аның белән кайчан һәм кайда очраштыгыз?

Муса. Мин...

Грабе. Туктагыз! *(Алексеевка.)* Бу кеше кем?.. Әйтегез...

Алексеев. Мин аны беренче тапкыр күрәм.

Грабе. Әйтмисез?

Алексеев. Беренче тапкыр күрәм.

Грабе. Оныттыгыз?.. Исегезгә төшерәм. Алтынчы июньдә сез «Остен» ресторанында очраштыгыз. Тугызынчы июньдә штадтпаркта. Унбишендә — урамда. Бәлки, хәтерлисездер? *(Кулындагы фоторәсемнәргә карап.)* Киоск янында.

Алексеев. Мин бу кешене беренче тапкыр күрәм.

Грабе. Ә бу нәрсә? Җәлил һәм сез... Сез әле бераз елмаеп та торасыз? Бер дә начар чыкмагансыз. Юкка гына беренче тапкыр дисез. Я, инде дә үзара бәйләнешебез юк иде диярсезме?

Алексеев дәшми. Грабе өстәлдәге кнопканы баса. Эльза керә.

Эльза. О-о! Хәерле кич, һер майор... *(Алексеев дәшми.)* Танымыйсыз? Хәтерегезгә төшерегез әле, уникенче июнь көнне, кич белән, парадный ишек төбендә... Сез Муса Җәлилгә килгән чакта...

Алексеев дәшми.

Грабе. Сез әле һаман дәшмисез?

Алексеев. Юк, инде сөйлим.

Грабе. *(Эльзага)*. Барыгыз.

Эльза китә.

Кемнәр белән бәйләнештә булганыгызны да сөйлисезме?

Алексеев. Сөйлим.

Грабе. Берлинның коммунистлар подпольесы беләнме?

Алексеев. Әйе.

Грабе. Руслар белән?

Алексеев. Әйе.

Грабе. Татарлар белән дәме?

Алексеев. Әйе. Казахлар, белоруслар белән... немецлар, французлар...

Грабе. Нинди бәйләнештә булдыгыз?

Алексеев. Душевный...

Грабе. Ничек, ничек?

Алексеев. Йөрәк белән, җан белән, димәк...

Грабе. Ах, син, мерзавец! *(Камчы ала.)*

Алексеев. Туктагыз! Әйтәм.

Грабе. Я?

Алексеев аның битенә төкерә.

А! Кабахәт... *(Суга.)* Алыгыз аны!

Солдатлар Алексеевны алып китәләр.

Грабе *(Муса янына килеп)*. Бәлки, сез ни дә булса әйтерсез? Юк?.. Без сезне асачакбыз. Әйе, асачакбыз. Ләкин тиз түгел. Бер атнадан, бер айдан, ә бәлки бер ел, ел ярымнан. Таш капчыкка ябып, акылдан шашканчы тотачакбыз. Чәчләрегез агарып, коелып беткәнче. Әйтергә дә түгел, күңелле язмыш көтә сезне... Нәрсә белән күңелегезне юатканыгызны беләм мин. Ватаныма турылыклы булып калам, дип уйлыйсыз... Шуның өчен совет халкы тәкъдир итәр, дусларыгыз хөрмәт белән искә алыр, дип ышанасыз. Буш хыяллар! Совет кешеләре күз алдында сез инде күптән Ватанын саткан кеше, хаин! Һәм мәңге шулай булып калачаксыз да... Сезне беркем дә, беркайчан да яхшы сүз белән телгә алмасын өчен без бөтен чараларны күрәчәкбез.

Муса *(күтәрелеп)*. Барлык эшәке эшләр сезнең кулыгыздан килә. Сез авылларны, шәһәрләрне жимерә аласыз. Балаларны, картларны үтерә аласыз. Ләкин халыктан һәм тарихтан хаклыкны яшереп кала алу кулыгыздан килми. Килмәс тә! *(Аягүрә калкынып.)*

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә.
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә!

Пәрдә

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

ТУҒЫЗЫНЧЫ КАРТИНА

Моабит төрмәсендә стеналары юешләнеп-күгәреп беткән бер камера. Унда калын тимер ишек. Югарыда рәшәткәле кечкенә тәрәзә. Аннан сызылып кына көн яктысы төшә. Салам матрац җәелгән ике топчан. Аларның берсендә Батыршин ята. Ара-тирә ул ыңгырашып куя. Аның янына Андре утырган. Бер топчан янында идәнгә Муса утырган да кечкенә дәфтәргә нәрсәдер яза. Аны тануы кыен. Йөзе сулган, чәчләре агарган. Алиш белән Хәсәнов ишек янында басканнар да нидер көтәләр. Тынлыйлар.

Алиш *(Хәсәновка)*. Ни өчен ул һаман да юк?

Хәсәнов. Минемчә, аны допроска гына алдылар.

Алиш *(әкрен)*. Кичә икебезне астылар, бүген бәлки...

Хәсәнов. Җитәр, Алиш...

Алиш. Үлемнән курыкмыйм мин... Көтүе газап...

Андре *(дәвам итеп)*. Шуннан Уленшпигель әйтә:

— Матуркай, мин туйганчы ашадым, яңак сөяклә-ремнең хезмәте өчен түләгез инде миңа, — ди. — Ул чагында мин сезне шундый назлы итеп кочаклап үбәрмен, хәтта сезнен сөйгән егетләрегезнең егерме җидесе берьюлы кочакласа да, минем кадәр булдыра алмас, ди.

— Юк, — ди хатын моны этәреп.

— Ах, — ди Уленшпигель, авыр сулап. — Тәнең каймак кебек, иреннәрең чия шикелле. Синнән дә тәмлерәк хатын-кыз бармы икән дөньяда!

— Ах, явыз, — ди ул көлеп, — бушлай ашавың өчен рәхмәт әйт, ичмасам... югыйсә, менә таяк алырмын да...

— Минем таягымны ал, — ди Уленшпигель...

Хатын кычкырып көлә...

Андре сөйләгән чагында бар да аның тирә-ягына җыйналалар.

Муса. Син, Андре дус, бөтен Уленшпигельне яттан беләсең, ахры?

Андре. Шарль де Костерны безнең Бельгиядә белмәгән кеше юк. Яше дә, карты да белә. Аның Уленшпигеле партизаннар сугышының иң авыр шартларында да безнең белән бергә булды.

Батыршин. Бельгия! Мәктәптә чакта укып үттем мин аның турында, э күз алдына китерә алмыйм.

Андре. Сугыш беткәч кил, бар җирен дә үзем күрсәтеп йөрермен. Искиткеч матур ул безнең Бельгия.

Батыршин. Барам, һичшиксез, барам.

Андре *(Мусага)*. Ә син һаман язасың. Укы әле безгә дә, Муса.

Муса *(укый)*.

Ник чакырдың су буена,
Үзең шунда килмәгәч?
Ник әйттердең «сөям» диеп,
Үзең «мин дә!» димәгәч?

Ник елмайдың каш сикертеп,
Яратмагач, йөрмәгәч?
Ник ашаттың тозлы балык,
Соңыннан су бирмәгәч?

Батыршин *(ыңгырашып)*. У-ух!

Андре *(Батыршин янына килеп)*. Авыртамы?

Батыршин *(күз яшьләренә тыгылып)*. Юк... Әллә ни авыртмый.

Андре. Яхшылабрак ят. *(Үз мендәрен ала да-Батыршин башы астына куя.)* Я әле, менә шулай. *(Батыршин ыңгыраша.)* Я, я, түз бераз. Тыныч кына ят. Тыңлыйсыңмы, мин сиңа тагын Уленшпигельне сөйлим.

Батыршин. Тыңлыйм.

Андре. Бервакытны шулай Уленшпигель трактирга килеп керә. Анда аны яшь кенә бер хатын — хуҗа хатыны каршы ала. Ул сорый:

— Сез аш ашарга телисезме?

— Әлбәттә, — ди Уленшпигель, — тик кыйммәтме?

— Алты флоринга байлар өстәлендә, дүрткә сәүдәгәрләр белән, икегә барлык кешеләр белгән бергә, — ди хатын.

— Никадәр кыйммәтрәк булса, шулкадәр яхшырак, — ди дә Уленшпигель байлар өстәленә утыра...

Алиш. Киләләр!

Муса тиз генә дәфтәрен яшерә.

Хәсәнов. Утеп китте.

Алиш. Аяк тавышы ишетелгән саен асарга алып китәләр дип көтеп тору — бу коточкыч. Биш ай инде шулай.

Муса. Алиш дус, син соң әле яңа хикәяңнең сюжетын уйлап бетердеңме?

Алиш. Әгәр сугыш кырында һәлак булсам, мине бәлки хөрмәт белән искә алырлар иде. Ә хәзер нәрсә? Ичмаса, Сәйфуллин кайтып житә алса иде... Безнең биредә дә барыбер сугыш кырындагы шикелле намус белән һәлак булуыбызны кем белә хәзер.

Муса. Кайгырма, дус...

Билгеләми гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык җитүе,
Бәлки менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер?

Батырлык һәм илгә турылыкны
Шушы үлем белән белдерик.
Безнең яшьлек шушы хисләр белән
Данлы иде, көчле иде бит!!

Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда.

(Андрега.) Әй, ни турыда уйланып калдың, партизан? Изабелланы сагындыңмы? Э, Андре?

Андре. Киләчәккә план корам. Туган илемә кайткач, нишләргә кирәклек турында уйлыйм.

Алиш. Син әле кайтуыңа һаман ышанасыңмы?

Андре. Ышанам. Совет гаскәрләре тиздән Берлинда булачак.

Хәсәнов. Ә бүген сине ассалар?

Андре. Шулай вакытсызмы? Монысы инде күңелсезрәк булачак. Аннан соң муен да бик нәзберек минем. Бау белән һич дус түгел.

Алиш. Күңелле кеше син, Андре, һаман шаярасың.

Андре. Мусадан өйрәндем. Чынлап та, нигә еларга? Елаклык үзе ярты үлем. Үлмәс борын үк үзеңне нигә үлеккә санарга? Теләмим.

Муса *(Андрега карап)*. Эх, Андре дус...

Кайтса иде гөлләр арасында
Гөрләп үткән көләч көннәрем,
Дускай, сиңа бүләк итәр идем
Илкәемнең иркә гөлләрен.
Бернәрсә юк минем монда хәзер,
Йортым, бакчам, хәтта иркем дә.

Гөлләр монда бар да кибеп сулган,
Җирләр монда читләр иркендә.
Тик бар минем кара уйлар белән
Тапланмаган керсез йөрәгем.
Йөрәгемнең язгы гөлләр төсле
Җыры булсын сиңа бүләгем.
Үзем үлсәм, исмем, җырым үлмәс,
Ул яңгырар илнең кырында,
Сөйләп илгә тоткын күңелләрдә
Чәчәк аткан дуслык турында.

Ишек ачыла. Кыйнап канга батырылган, күзләре бәйле Алексеевны кертәләр.

Бар да. Алеша, исән!

Алексеев. Үләргә җыенганым да юк.

Аны Батыршин янына китереп яткыралар.

Муса. Сорау алдылармы?

Алексеев. Аннан да яманрагын эшләделәр. Минем күз алдымда башкаларны кыйнадылар... Ә мине карап торырга мәжбүр иттеләр. Мин күзләремне йомдым... Ә алар күзләремә... күзләремә камчы белән... О-ох *(Ыңгыраша. Пауза.)*

Муса. Кабахәтләр.

Алексеев *(капшанып, Батыршинга)*. Синең хәлләр ничек?

Батыршин. Яхшы. Физзарядкада катнаштым.

Алексеев. Иртәгә мин дә... мин дә катнашачакмын! Без әле яшәрбез... Яшәрбез!.. Сугышырбыз... *(Хәле китә.)*

Андре. Алексей, дус.

Алексеев. Су!

Муса. Су!

Алиш *(кружкаларны карап)*. Тамчы гына булса иде, ичмасам.

Андрей *(тыңлап)*. Туктагыз әле, иптәшләр. *(Стенага колагын куеп тыңлый.)* Бу — безнең күрше, немец коммунисты Таубе. Безгә сәлам тапшыра. Туктагыз! *(Тыңлый.)* Гитлерның Курск дугасындагы һөҗүме... җимерелде!.. Дошман көчләрен сындырып... Совет гаскәрләре... һөҗүмгә күчтеләр. Кичә... бишенче августта... Орел һәм Белгород шәһәрләрен алдылар.

Бар да. Орел, Белгород!

Муса. Котлыйм, дуслар!.. *(Кочаклашалар.)* Җиңү белән, дуслар!

Ишектәге кечкенә тәрәзә ачыла.

Надзиратель тавышы. Кичке аш. *(Тәрәзә аша мискиләр бирә.)*

Хәсәнов *(мискиләрне ала)*. Бер, ике, өч, дүрт, биш... *(Тәрәзә ябыла.)* Без алты кеше.

Надзиратель тавышы. Муса Җәлил паектан төшерелде.

Бар да тавыш-тынсыз *катып калалар*. Алишның кулындагы миски идәнгә төшә.

Муса. Аңлашылды.

Хәсәнов *(ачу белән)*. Сез төшерсәгез, без аны төшермибез!

Барысы да тын гына басып торалар.

Муса *(куен дәфтәрен алып)*. Биредә минем соңгы җырларым, соңгы җырларым, соңгы кичерешләрем. *(Берәм-берәм барысына да карап чыга. Соңыннан Андрега тукталып)*. Мә, дускай, син, бәлки, ирекне көтеп ала алырсын. Безнекеләр һичшиксез Берлинда булачаклар. Мин моңа ышанам. Әгәр исән-сау калсаң, боларны минем туган илгә озат. Әгәр иптәшләрем, дусларым, Әминә һәм Чулпаным укыса... бу минем өчен иң

зур бәхет булачак. Шуннан артык бәхетне мин өмет тә итмим.

Андре *(дәфтәрне алып)*. Ышан, дустым, жырларың синең туган иленә кайтып житәр.

Муса. Яшьләй үләбез, дуслар. Ләкин кайгырырга урын юк. Без үз тормышыбызны жир йөзендәге иң изге һәм гүзәл эш—халыклар бәхете өчен, кешеләрнең үзара тату яшәүләре өчен бирәбез. Мин ышанам, бервакыт ул көн киләчәк.

Без матур чорда, матур итеп яшәдек. Мостафа авыллы, гамьсез балачак. Киң кырлар, урман, яшеллек, ә мин барысына да гашыйк идем. Аннан Оренбург, Казан, Мәскәү, тагын Казан, тагын Мәскәү... Әминә һәм Чулпан. Соңгы саубуллашу һәм менә Берлин. Биредә сез — минем турылыклы, кыю йөрәкле дусларым. Тормышымның соңгы минутларында сезнең белән бергә булу — үзе бер бәхет. Миңа булган дуслыгыгыз өчен рәхмәт сезгә, иптәшләр. Тагын нәрсә? Ә... безне яңа хәбәрләр белән таныштырып торган, миңа кәгазь, каләм биргән төрмә надзирателе Миллер картка, аның белән безне бәйләгән кыю кыз Анна-Марияга соңгы сәламем һәм рәхмәтемне әйтегез. *(Пауза.)*

Жырларым, сез шытып йөрәгемдә
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле жирдә хакыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм халык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

Барысы да Муса тирәсенә җыйналалар. Ул уртада, топчан өстенә баскан.

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигыремдәге изге антына,
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш язына,
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңгырар җыр булып.

Муса һәм аның иптәшләренең йөзе алсу нурга күмелә.

Пәрдә

ЖЫР ТУРЫНДА ЖЫР [1]

(Поэмадан өзек)

1

Урнашты бар да акрынлап,
Зал тулы — жырның дуслары.
Йотлыгып тыңлый һәр сүзне
Шагыйрьнең ватандашлары.

Ә шагыйрь? Ник ул килмәгән?
Буш урын калган биредә...
Сүз алып, шул чак шигыре
Сөйләде аның турында:

— Эзләсә мине кем дә кем,
Факелы итсен жырымны.
Яктырса жырым алдында —
Табар да аңлар серемне...

Ияртеп залны, жыр тагын
Канатын какты ашкынып.
...Дәһшәтле сугыш еллары,
Яшь ана үкси яшь коеп...

[1] Казахчадан Шәрәф Мөдәррис тәрҗемә итте.

Киңәш, җыр, акыл, шаян сүз,—
Алдында ята соңгы хат.
Йокысыз төнне яшь хатын
Текәлде аңар мең кабат...
Ә шагыйрь? Кайда, нишли ул?
Зарыкса, хат юк ярына.
Җыр ник сөйләми һәммәсен,
Аңа мәгълүм ич бары да.
Тетрәде кинәт, ярсыды
Ялгыз калган кебек җыр да.
Күкрәде дуслар алкышы,
Давылдай гөр килеп монда.
Ил күңелен, йөрәкләрне
Тибрәндереп чыңлады җыр.
Дәһшәтле елның көзенә
Тоташтырды уйларны җыр...

2

— Кайвакыт? Төнме, таңмы бу?
Кайда без? Нигә ябылган?
Китсәче калгып тагын бер,
Йокысыз, ялсыз арылган...
— Йокысыз шайтан түгел без! —
Ди дә ул, көлеп уяна...
Күз алды ләкин караңгы,
Якты көн килде уена...
Уйлары өзелде кабат,
Күз алды кара төн генә.
Бормасы беткән сәгатьтәй,
Йөрәге тибә тын гына.
Ул гына уяу, ул тере,
Ул гына итә хәрәкәт...
Саный ул күргән газапны,

Төнендә сызлый җәрәхәт.
— Гафу ит! Үлем түгел бу,
Мазасыз, авыр төш кенә.
Алдымда эшләр күп әле,
Мәхәббәт үлмәс тиз генә! —
Дигәндәй ачты күзләрен,
Уйлары китте кабынып.
Җилкенеп, йөрәк гел типте,
Көрәш һәм җырны сагынып.
«Кергәнче кабат сугышка,
Халкыма җитсен сәламем;
Йокыны, Муса, куй, ташла,
Тор әйдә, кайда каләмең?
Торырга ләкин хәлем юк,
Торырга өнди тик күңел.
Сөякләр сынган, ватылган,
Кем тәне? Юк, бу — мин түгел...
Ни булды? Өнме, төшме бу?
Нигә юк нур, юк бер якты?
Нинди йөк минем өстемдә?
Әйтегез, монда кем япты?»
...Ишетми ләкин бер өн дә,
Күрми ул дөнья яктысын.
Шул вакыт Муса төшенде,
Аңлады авыр язмышын...
...Күкрәде сугыш, зур сугыш,
Бер як та берсен җиңмәде.
Бер алай, аннан бер болай
Чайкалды җиңү бизмәне.
Сазлыкта батты кешеләр,
Кан басты итек кунычын.
Җир торды үлчәп адымны
Һәм тойды солдат сулышын.
Соңгы кат күрде туган җир

Шул көнне акын-солдатын
Сугышты Муса, яклады
Ватанын — бәхет бакчасын.
Гөрселдәп утлар чәчелде,
Көрсенеп куйды Жир-ана.
Күз алды төтен һәм тузан,
Күренми берни тирәдә...
Караңгы, дөнья караңгы,
Тулганды, давыл уйнады.
— Бу нәрсә? Үлем бииме? —
Өзелде шагыйрь уйлары...
Югалды ирек, азат көн,
Күрергә язган башканы...
Башланды тоткын газабы,
Яшәү һәм үлем дастаны.

4

Бер мең тугыз йөз кырык өч...
Кар сипте гыйнвар кырларга.
Кылычын айкап торды кыш,
Янады тоткын жырларга.
Ятты Жыр «яңа елда» дип,
Иреккә чыгар көн көтеп,
Жыр сөяр илдән бер сәлам
Килсәче күңел жилкетеп!..
Саргаеп бетә кәгазьләр,
Язылган жырлар — бер данә.
«Очырам!» ди күк кышкы жил,
Гөжелди, дулый, женләнә...
Үләрме шулай Жыр-батыр,
Өч мүшәл[1] яңа тулса да?

[1] Өч мүшәл — 37 яшькә туры килә.

Сайрарга туган былбыл кош,
Сайрый ул тоткан булса да!
Атлый тик вакыт җәяүләп,
Өстендә тора йөк артып.
Чыга да кояш, бата да,
Офыклар читен кызартып.
Әсирләр торган лагерьда
Төн килә җанны шомлатып.
Туарга торган яңа жыр
Эзли гел тын жир, тын вакыт.
Көч, илһам тапты Жыр-Муса,
Үттеләр көннәр көн арты.
Ярдәм-илһамчы кем аңар?
Билгеле түгел моңарчы.
Әллә ул иптәш «Н» микән —
Юнәлтә уйлар агышын?
Әллә ул туган ил микән?
Әйтми тик Муса анысын...
Жырлый ул тоткын жаннарга
Саф хисле татар жырларын;
Кылычын үбеп ант иткән
Егетнең яшьлек серләрен.
«Чит илдә солтан булганчы...»
Яңгырый серле авазлар...
Ут яна кайбер күзләрдә,
Кайсында — моңлы карашлар...
Мусаның анда «эше юк»,
Жырда тик аның бар уе.
Берәүгә жыр — жан азыгы,
Берәүгә — йөрәк даруы.
Куганда эшкә лагерьны,
Әсирләр тауны узганда,—
Күз төшә шәрык ягыннан
Күренгән зәңгәр урманга.

— Бу урман ничә чакрымда?
Җитәрме төнге җыр аңа?
— Җитә,— ди берәү пышылдап,—
Якын ул, Муса, күр әнә!
Яшертен генә конвойдан
Төбәлә күзләр урманга.
Көрсенә тагын берәүләр,
Берәүләр чума уйларга...

5

Атлады Вакыт-мосафир,
Кәрваң күк тезде көннәрен,
Китерде матур шат язны,
Үстерде асыл гөлләрен.
Чыгарып бөре-яфраклар,
Яшь урман ямьгә күмелде;
Уйнатып күксел миражын,
Чакырды тоткын күңелне...
Төшә күк яфрак һавадан —
Әллә шул урман тараткан?—
Табалар яшерен кәгазьләр
Таң-иртән барлык баракта.
Тарала сүз — фронт хәбәре
Җиннән — җиң, телдән — телләргә.
Газаплы җаннар табынды
«Яфраклар» явар төннәргә.
Уйланып Муса төн ката,
Шигърият утын яндыра,—
Җырыннан үреп такыялар,
Баракта «яфрак» яудыра.
Яфрактан түгел, яшеннән
Ялтырап торды күк йөзе;
Кара төн — егет юлдашы,—

Тоткыннан качты күп кеше!
Җенләнде фашист җәлладлар,
Тулдылар кереп баракка.
Эзләүче этләр, сакчылар
Чәчелделәр бар тарафка.
Ә Муса? Муса — тоткында.
Шатланды «эшләр бара» дип;
«Тотарсың атаң башың, бар,
Бар әнә эзләп кара!» дип.
— Рәхмәт, ялкынлы йөрәкләр,
Җилписез ирек канатын!
Сиңа да, җырым, тиз булыр
Карурман белән кара төн!
Китмәде бушка әкиятем,
Юлдашы булды чынлыкның,
Җырым да дошман кулында
Гомергә булмас гел тоткын!—
Көтәм мин кара бер төнне,
Иреккә үзем чыгармын,—
Мәхәббәт белән Нәфрәтем
Көрәштә кабат сынармын!
Иркәләп сөяр Ил-анам
Мусасын — «бунтарь баласын»;
Кочагын ачар Җир-анам,
Гөлләре язар ярасын...
Көтә тик Муса шул көнне,
Йөрәктә көче өметнең.
Көтә ул нуры мул көнне.
Юлдашы төн ич егетнең!
Ташланыр егет көрәшкә,
Үтәлер юлдаш-дус хакы.
Кыен тик җитү теләккә,
Богаулар салды гестапо...

6

Моабит. Салкын камера.
Таш табут кебек тар-кысан.
Таш идән, сәке, диварга,
Ишеккә оешып катты кан.
Чокылган сукыр тәрәзә,
Ничә кат тимер рәшәткә.
Шушылай булгач язмышың,
Калырлык түгел гажәпкә.
Челтәрле чытык тәрәзә —
Суынган мәет теше күк.
Күрмисең айны, кояшны —
Кабердә яткан кеше күк.
Шушында үтте Мусаның
Тоташып көне-төннәре.
Онытты ай-көн исәбен,
Тик җанда ялкын дөрләде.
Җан белән күреп дөньяны,
Җыр белән фәкать сөрләште.
Шәп уйлар, изге өметләр,
Хыяллар белән сөйләште.
Уйланып тора Муса-Җыр,
Тәрәзгә төбәп күзләрен.
Язылды менә соңгы җыр.
Әйтте ахыргы сүзләрен...
Белә ул: бүген үләчәк,
Гомере бетәр шушында.
Әмма юк! Үлмәс шигыре!
Шигыре калыр дусында!

Нинди дус? Каян килгән ул,
Торганда сакта гестапо?
Табылды! Азмы гадел җан?

Әйтмәде исмен. Дус хакы!
Ничә көн шагыйрь уйланды,
Күзәтеп төрмә тәрәзен:
«Бирмәсен дошман миңа нан [1],
Бирсен тик бер бит кәгазен».
Ишетте моны берәүләр,—
Билгесез дусты бар хәзер.
Кем белә? Бергә үләрләр...
Йотмады кемне тар кабер?
Форсат юк. Муса урлады
Йокы һәм газап арасын.
Юган күк булды җырлары
Яшьле күз, канлы ярасын.
Биләүсә булып кәгазе,
Ятты күк шунда баласы.
Тирбәтеп туар шигырен,
Текәлде шуңар карашы...
«Калса да тәнем ят җирдә,
Кайтачак илгә йөрәгем.
Ике үлем юк. Җыр гына
Үлмәсен,— тик шул теләгем!»
Тапшырды кичә бер кулга
Җырының калган битләрен.
Шулардан аңлар Ил-ана
Улының соңгы хисләрен.
Тын тора Муса берүзе,
Элеккән килеш тозакка.
Ишектә түгел тик күзе,
Ишектә түгел, ераkта.
Торса да үзе ул монда,
Ераkта аның уйлары:
Җәелеп ята алдында

[1] Нан — икмәк.

Туган җир — Идел буйлары.
Чума күк шаулы дулкынга,
Сикереп кыя ташыннан;
Күрә күк яшьлек чагын да
Егерменче еллар башыннан.
Дулый күк Идел. Байраклар
Бизиләр Җаек даласын,
Күкрәтеп кага Оренбург
Советны яклау набатын...
Яшүсмер — Ленин солдаты —
Муса окопта, я атта.
Үзенә унбиш тулырга
Я бер ай булыр, я атна.
Сөйрәлеп озын мылтыгы,
Оялты азрак солдатны.
Күз җиткән җиргә кул житэ.
Гаеплэп булмый яшь чакны!
«Туган җир, ерак калдың син,
Якын тик үзең хәзер дә.
Ерак син, чөнки кул житми,
Якын син, чөнки хәтердә!»
Тоткын жан тимер читлектэ,
Житез уй — Идел буенда,
Ул хәзер татар авылында,
Табында, сабан туенда...
— Кайда син, башла, гармунчы!
Егетләр, эйлән-бәйләнгә!
Уйна, көл, бие, җырың суз,
Ямь бирик, кызлар, бәйрәмгә!
— Иртә дә кил, кич тә кил.
Тәрәзәмне чиртә кил!
Чиртүеңнән танырмын,
Каршы чыгып алырмын.
...Уртага чыкты Муса да,

Тыпырдап бии башлады.
Биегән җайга як-якка
Сибелеп торды такмагы:
— Сезнең түбә түбәмени,
Вәт безнең түбә түбә,
Сезнең кызлар үбәмени,
Вәт безнең кызлар үбә!
...Тукайда кинәт «Карурман»
Яңгырап китте моң гына.
Аһәңле җырга сокланып,
Чайкала Идел тын гына.
Чайкала, һаман чайкала,
Тирбәтеп яшьлек җилкәнен.
Сагына җырда йөрәкләр
«Галиябану»ын, «Иркәм»ен.
...«Иркәм» дип куйды пышылдап,
Сизмичә тоткын үзе дә.
Сагынган җирләр тагын да
Күренде төсле күзенә...
Уйланды шагыйрь, уйланды,
Утырып, торып, йөренеп.
Истәлек, теләк, хыяллар —
Киттеләр саф-саф тезелеп.
Арылган. Вакыт йокларга.
Уйлар да инде чуалды.
Тын гына шунда ак беләк
Муенына килеп уралды...
«Сөеклем, иркәм, бәгырем,
Синме бу минем кырымда?
Үзең син — илһам, балабыз —
Дәвамым да ул, җырым да!
Бервакыт әйтер шат тавыш:
«Әти!» — дип халык эченнән.
Кочар ул якты дөньяны,

Мин юкта минем исемнән.
Сабыйның тәүге соравы
Булырмы Ватан хакында?
Белерме ничек туганын
Кайсы ил күге астында?
Әй сабый, сабый, бала кош,
Каян соң белсен яшь жаның?—
Әйтмәдем сина кайвакыт
Күкләрне болыт басканын.
Болытлы күкне кәһәрләп,
Ятам мин үлем карнында.
Мин монда әсир, бер мәет,
Дошман мин монда, ят монда.
Германия күге — кара төн,
Капланган кара казан күк,
Канат та жилпи алмадым,—
Тәбәнәк, кырыс, саран күк».
Уйланды Муса, сизмәде
Киткәнен ишек ачылып.
Жандарм керде. Кемнәрдер
Каядыр чапты ашыгып...
Тоткынны хәтта уй белән
Калдырмый дошман — көнләшә.
Табутта көн-төн тынгы юк,
Бер керә фашист, бер дәшә.
Тик бүген... бүген эш башка:
Шом гына жәллад күзендә...
— Әзерлән!.. Капут, комиссар!..
— Әзерлән, палач, үзең дә!
...Төн керде кичтән төрмәгә,
Кап-кара кәфен яптырып.
Вакытсыз беткән гомердәй
Югалды соңгы яктылык.
Хәзергә сүнми торды тик

Ике ут — ике күз генә.
Аларда — илгә мәхәббәт,
Дошманга нәфрәт, үч кенә.
Аларда — өмет, омтылыш,
Сизәләр ал таң атканын;
Йөриләр газиз җирләрдә,
Күрәләр Идел акканын.
Юллый ир соңгы сәламен:
«Саф булды җаным, вөҗданым.
Күрсәм дә әсир хурлыгын,
Җан саклап антым бозмадым.
Чиксәм дә авыр газаплар,
Булмады минем ялгышым.
Зинданда әсир богавын
Өзәлми үләм ялгызым...»
«Әй улым, беләм!» дигәндәй,
Ерактан бер өн килде күк.
Төрмәне ватып, туган ил —
Шәфкатьле ана керде күк.
«Хәбәрсез узган елларым
Үтмәде синсез, Ил-анам!
Ышан син әсир улыңа,—
Мин сиңа чиксез инанам!
Алдымда балкый кырларың,
Бәхетле тыныч елларың.
Киң булып баса каршыма
Киләчәк, нурлы юлларың.
Менә син бире киләсең
Яулардан җирне тазартып.
Эх, якын инде, бик якын
Мине эзләгән Азатлык!
Каршыңа очар көчем бар,
Юктыр тик ирек күрәсем.
Кала бер намус бурычым —

Партия взносы түләсем...»
«Түләдең, Муса, түләдең!
Кызыллык килмәс йөзеңә.
Мәңгелек взнос — иҗатың,
Партия өчен хәзинә!»
Аңлады Муса: бу тавыш —
Үзенең соңгы теләге.
Шушындый җылы бер сүзне
Зарыгып көтте йөрәге.
Шулай да чынлап ышанды,
Куанды чынлап Муса аңа,—
Онытып якын үлемне,
Куаныч сәер булса да...
Йөрәккә авыр шом салып,
Ник улый тагын җил анда?
Төшерде искә үлемне,
Онытып торыйм дигәндә...
Яктырды кинәт камера,
Кабынды лампа биектә.
Ишетелде палач тавышы,
Зыңлады йозак ишектә.
Ишекне ачты биш палач,
Тын калды басып чыра күк.
Тоткын җан түгел, каршыда
Корулы мылтык тора күк.
Мусаның кулы — биләндә,
Карашы горур үзенең.
Битараф, салкын кан белән
Каршылый шулай үлемен.
Саргайган, ябык йөзендә,
Кояш күрмәгән күзендә
Якты нур, ирлек, сылулык,
Батырлык торды бүген дә...

7

Шуннан соң?— дисез, дусларым.
Хисләре — чиксез күңелнең...
Прологы булсын дастаным
Эпилогсыз зур гомернең,
Яхшы җыр мәңге яшәүчән,
Үлемсез безнең Җәлил дә.
Буш нәрсә ул «үзе юкның
Күзе юк» дигән дәлил дә.
Мусаның җырын саклаган
Бельгия улы — партизан:
— Юк,— дигән,— андый яхшы дус,
Аның күк гүзәл, затлы җан!—
Бурычлы түгел Муса да,
Калмады дуста дус хакы:
Андрены йолдык зинданнан,
Кирәген алды гестапо!
Акынның кайтты җырлары
Сөекле туган җиренә,—
Картаймый һаман, яшь килеш
Сыенды газиз иленә.
— Муса!— ди аңа сөйгәне,
— Әткәй!— ди аңа баласы;
— Җәлил!— ди сәхнә авазы,
— Герой!— ди Ватан-анасы.
Шигырьдә тибә йөрәге,
Җаны да шунда Җәлилнең.
Легенда, җыр итә аны
Дус, туган халкы һәр илнең.
Муса-Җыр Алтын Йолдызлы
Күрә ул илнең киңлеген;
Әлмәттә — нефть вышкасын,
Иделдә — Казан диңгезен.

Күтәрдек чирәм, кыр-дала.
Хыяллар ашты тормышка,—
Шагыйрьнең матур уйлары
Әйләнде гүзәл чынлыкка.
Сөюче иде ул таңны.
Яхшының яхшы дусы иде.
Гүзәлдән гүзәл Ватаны —
Хыялы аның шушы иде.
Шуннан соң?— дисез, дусларым,—
Хисләре — чиксез күңелнең.
Прологы булсын дастаным
Эпилогсыз зур гомернең.

МУСА

(Романнан өзек)

V

Инде айдан артыкка сузылган төрмә тормышы, инди генә кабахәтлеге һәм вәхшилекләре белән жәберләмәсен, барыбер Мусаны изеп ташлый алмады. Хәтта мескенәйтмәде дә. Тора торгач, ул үзенең очсыз-кырыйсыз авыр уйларыннан, үкенү һәм пошынуларыннан барыбер айнып китә, еш кына кайчангыдыр якты хатирәләре исенә төшеп, бөтенләй онытыла, хәтта берни дә булмаган шикелле елмаеп та куйгалый иде. Шундый чакларында ул, гүя һич кайгысыз һәм борчылусыз кеше шикелле, кулын артына куйган килеш ишекле-түрле йөренгәләп, үз камерасының әлмисактан бирле агартылмаган стеналарын «өйрәнә» иде. Алар бөтенләй чуарланып беткән. Монда утырган һәрбер кеше үз календарен ачкан да кыска гына итеп үзенең әрнүле фикерләрен, нәфрәтен яки йөрәк хисләрен язып калдырган. Ул юллардан көйдергеч каһәр белән тулы йөрәк ачысы бәрелеп тора, дөнья белән саубуллашу авазы яңгырый.

Нинди генә телләрдә язылмаган алар! Немецча, французча, голландча, серб һәм хорватча, русча, полякча, украинча һ. б., һ. б. Бакчы, хәтта 1918 елгылар да бар: «Хуш, Шарлотта! Иртәгә мина үлем. Әмма мин ка-

рак түгел, шуны исендә тот! Синең Гансың». Шуның янында ук: «Яшәсен Германия революциясе! Полиция палачлары мине асып кына аны җинә алмас! Сәлам якты дөньяга! Курт Гауфер, ташчы». Муса, шуларны укый-укый, түшәмтә таба үрелде: «Һитлер — бандит. Безне алдады. Ф. Нейман. 1933». «Хай живе Вкраина! Тарас. 1942. III», «Лучше умереть здесь, чем быть власовцем. Иван Власов. 1943».

Йөрәк каны белән язылган бу язулар бик күп иде, аларның һәрберсе уйландыра, билгесез бу көрәшчеләрнең йөрәк тавышын ишеттерә, өч авыз сүз белән олы бер тарихның фажигале сәхифәләрен ачып бирә кебек иде.

Шулай күнеле урыныннан кузгалып, алар язмышы өчен кайгырып, уйланып йөри торгач, беркөнне стенага яңа бер язу өстәлде: «Егылсам да җиңәм дигән антым хәтеремдә минем һәркайчан. М. Җәлил. 1943.IX». Шуннан соң ул, туфли үкчәсеннән теше белән суырып алган нечкә кадакны, шушы хезмәте өчен кадерләп, пинжәк чабуының капшалмастай бер җөе эченә яшереп куйды.

Шул билгесез корбаннардан аның уйлары үз иптәшләренә күчте. Теге Мемориаль такта әвәләгән язуга караганда, Берлиндагы дуслары бар да төрмәдә булырга тиеш. Тик аларның берсен дә Мусаның очратканы юк. Ә менә легиондагы дусларының язмышы турында ул һаман әле һичнәрсә ишетә алмый иде. Исәннәр микән алар? Әгәр алынмаган булсалар... Әгәр...

Һәм ул кинәт татлы бер хыялга чума. Мавыктыргыч кыю планнар күз алдына килә: үзенең монда утыруына да карамастан, ниндидер юллар белән багланыш тотып, эшне һаман дәвам иттерү мөмкин булмас идеме?.. Әгәр бөтенесе дә болай кинәт кенә өзелеп калса, күпме көч куелган эш сүнәчәк, күпме меңләгән солдат, көтелгән иреккә чыга алмыйча, харап булуы мөмкин!..

Муса, бу хәвефле билгесезлекнең очына чыга алмыйча, әрле-бирле йөренә, ишек янына килеп туктый. Югарыдагы тәрәзәгә күзе төшә дә, андагы иптәшләре, бәлки, алынмагандыр, әле алай өметне өзәргә ярамыйдыр кебек тоела башлый... Нишләргә? Җеп очын каян табып, каян ялгарга соң!..

Ул шулар белән баш вата да, уйлары таркала башлагач, тагын стена белән сөйләшергә тотына. Ишек янындагы почмакта моңарчы бетенләй укылмаган яңа бер язу бар икән: «Тоглер — провокатор. Сак булыгыз! Вилли. 1933».

Муса, өстенә суык су койгандай, чирканып китте. Аның үзеннән-үзе йодрыклары йомарланып килде: «Кем сатты безне? Кем ул шакшы жан — провокатор?..»

«Идел-Урал» тирәсендәге күп кенә адәмнәр турында уйлап карады ул. Ишбулдин, Хәнәфин, Шиһап Нигъмәти, Солтан...

Болар ышанырга ярамастай шикле кешеләр иде. Ул аларны каршысына бастырып, мәрхәмәтсез кырыслык белән һәрберсен җентекләп күздән кичерде: шуларның берсеме? Әллә Шәфи Алмаз үземе? Кем генә булыр соң? Ихтимал, бу хакта Алишмы, Булатмы, Шабаев яки Симаевмы бик яхшы белә торганнардыр. Эх, менә хәзер аларның язуын да шушы стенадан табу мөмкин булсын иде! Ул чакта Мусаның хәле нинди жиңеләер, һәм, тикшерүченең этлекле сорауларына каршы, ул үзе провокаторны фаш итәр иде! Хәер... барыннан да элек үзе гаепле ул. Әйттеләр, күпме кисәттеләр! Ә ул, барыбер колагына элмичә, чемоданына листовка төяп чыкты. Шул житмимени бөтен эшне жимерергә! Шул листовка булмаса, аны кем гаепли алыр иде? Һәм ул моннан тиз генә чыгып, оешманы саклап калмас идемени?..

Шундый каршылыклы һәм чияләнгән төендәй чишеп булмый торган уйлар белән интеккәндә, тикшерүче та-

гын аны допроска чакыртты. Бу инде унынчы яки унбишенче тапкырдыр, Муса хәзер аларның бөтенләй исәбен җуйган иде. Кайчандыр үзенчә бик нечкәдән башлаган һәм бик нәзакәтле кыланган Геденктафель һәр очрашкан саен һаман усаллана барып, Мусаны ничек тә куркытырга, тел яздырырга, аяктан егарга тырышты. Мусадан кем кушуы буенча эшләвен, «шпионлык үзәген», «Мәскәү кулын» талтырырга тели иде ул. Әмма нинди генә хәтәр кеше булып кыланмасын, сәбәбен үзе дә белмәстән, Муса аңардан курыкмады. Аның шул кәмит кыяфәтен күргәч, ниндидер эчке горурлык белән үзендә өстенлек тоя һәм жирәнеп көлемсери генә иде. Ихтимал, шушы санга сукмавы Мусаның үз башына күп бәлаләр китергәндер дә. Чөнки үчлекле немец, үз корбаныннан әз генә булса да әдәп һәм буйсыну шикелле сыйфатлар күрмәгәч, отыры котыра барып, үзенең «клайн» һәм «гросс» концертлары белән күнел ачарга тотына иде. Бу чакыртуында да ул, Мусадан бернинди яңалык та ишетә алмагач, тагын шулар белән үк сыйлап кайтарды аны. Төткындагы кеше түзә икән. Иректә чакта мондый ерткычлыкны күтәрә алуы мөмкин түгел кешенең, үзен-үзе һәлакәт чокырына ыргытыр иде ул.

Юеш тоз калчыгыдай сөйрәп кертелеп ташланган Муса, камера суык булганлыктан озакламый аңына килеп, туңа башлады. Куллары белән бер кырыйга шуышып, параша ящигына үрелде һәм, көч-хәл белән гәүдәсен калкытып, аның өстенә утырды, стенага терәлде. Суелып беткән аркалары шундук ут янып әчетергә тотынды. Ләкин таш стенадан бәргән салкынлык ниндидер йомшак компресс шикелле, ул әчетүләргә әз генә жиңеллек биргәндәй булды. Һәр буыны аерым-аерым сулкылдап сызлый, күз алмалары кургаш баскандай кызып авырта иде. Шулай аркасын һәм башын таш стенага терәгән, күзләрен йомган килеш, озак, бик озак утырды

ул. Аның каплаган соры томан әкрен-әкрен таралып киттеме, әллә кан йөреше үз эзенә төштеме, аның эченә әз-әз ачыклана барды, күзләре ачылып, каршы стенаның түшәм почмагына терәлде. Үзе абайлаган беренче уе: «Бу соң нинди Германия?..»— дигән газаплы һәм һаман аңланмый торган ачы сорау иде. Чынлап та... Сизмә соң бу, Муса белгән ил?.. Ул әле яшь чагында ук, Европа әдәбияты белән таныша башлагач та, Шиллерне, Гётене, Һейнене һәм немецның тагын бик күп шагыйрь вә әдипләрен укып, беренчән-бере талантлы һәм киңрәк колачлы композиторларына тан калып, яңа идея титаннарына табынып, үзе белгән шул Германиягә бөтенләй гашыйк булып йөргән егет иде бит. Кайда шул Германия?!.

Ул, сызлаган сәякләрен көчкә сөйрәп, тәрәзә каршына килде. Аңлау мөмкин булмаган шушы ачы сорауга, үзенең шушы караңгы кичерешләренә инә күзедәй генә бер якты нокта табарга теләгән кебек, тимер челтәр артындагы кин дөньяга йотылып карады. Ләкин ул тар дүрткелдән бары тик кызыл кирпеч өемнәре, көл төсле соры суык стеналар гына күренде, сокланғыч кояш нуры да, күнел җилкетерлек якты киңлекләр дә юк иде. Гүяки монарчы ул белгән тылсымлы йолдызлар бу караңгы илнең күгендә беркайчан да балкымаган, анда бөтенләй чын яшен түгел, ә бары тик алдавыч ажаган гына уйнаган! Гүяки бу ил, мәңге шулай вәхши караңгылыгында яшәп, фәкать әнә шул әшәке кара көчләрне, Гитлер, Геббельсларны гына тудыра алган! Гүяки бу илнең күгенә ничәмә-ничә урыннардан бары тик биек кара моржалар гына күтәрелә, һәм алардан адәм баласын яндырган сасы кара төтен дөньяга тарала! Әллә соң бу зур халыкны шушы кыска гына вакыт эчендә фашизм дигән йогышлы чир шундый кабахәтлеккә китереп житкергәнме? Әллә бу әшәке сыйфатлар тумыш-

тан үк немецның канына салынганмы? Бу ил кешеләре шуңа күрә үзләреннән башка бер кешене дә яратмаулары, аларны түбән санау, җәберләүләре белән горурланамы? Шуңа күрә комсызлыкны үзләренә алла итеп, бүтәннәрнең актык сыныгын, актык чүпрәген тартып аламы?..

Муса сәгатьләр буена шушы авыр уйлардан котыла алмады. «Синме соң бу — бөек Маркс иле һәм давыллы Шиллер ватаны?..»— дип пышылдый иде ул. Үзенең яралы аркаларын да, сулкылдап сызлаган буыннарны да онытkандай булды. Бу ил белән, бу халык белән сөйләшәсе, үзенең актык тавышын ишеттерәсе килә иде аның. Җанын газаплаган уйларны әйтеп бирсә, җиңелрәк булыр кебек тоелды. «...Тоткын итеп сиңа китерде дә «кол» дип мине немец атады...» Бу аның күп җәберләрдән соң туган һәм җаны-тәне белән әрнеп әйткән үпкә сүзе иде. Үзен шулай тетрәткән карангы һәм әшәке Германия турында шундый тирән борчылып уйланулары, әмма шуның белән бергә, аның каядыр яшерентән якты көчләреннән әле һаман өмет өзмәве, аларга хаклык сүзен ишеттерәсе һәм аларны көрәш мәйданында күрәсе килүе, ниһаять, кайнар җырга әверелеп, күңел түреннән түгелә башлады:

Әйт син мина: утлы, «Рот-фронт»лы
Көннәреңне кая югалттың?
Нигә мине — Клара әбисенең
Сөйгән улын — кыйнап жылаттың?..
Шулай дипме сине белә идем
Гёте белән шашкан чагымда?
Бетховенның кыю симфониясе
Ник яңрамый мәрмәр залында?
Хәр йөрәкле һейне гашыйгына
Хужаң тимер богау кигезде.
Карл белән Роза каны тамган
Төрмәләрнең бозын имезде.

Мин күрмәдем синдә кояш нурын,
Баскан аны канлы тузаның.
Тик татыдым батыр Тельман яткан
Подвалларның авыр йозагын...

. . . . . .

Арагызда кем бар Цеткин улы,
Тельман егетләре кайсыгыз?
Ишетегез бөек хаклык сүзен,
Төрмәләрне безнең ачыгыз!..

Әмма Цеткин уллары да, Тельман егетләре дә килмәде, төрмәләр ачылмады. Чөнки алар үзләре дә Бухенвальд, Дахау, Маутхаузен шикелле үлем чокырларына тутырылган иде. Ихтимал, шуңа күрәдер, Муса иректә чакта да аларның берсен дә очрата алмады, ә бик тә эзләп йөргән иде, югыйсә. Булмады шул. Инде немец төрмәләрен ачарга Ленин егетләре килми булмастыр. Башка һичкем моны эшли алмаячак! Тик ул егетләр әле ераста, һай, бик ераста. Өзелмәсме нечкә генә булып калган гомер җебе?..

Иртәгесен Мусаны икенче тапкыр прогулкага чыгардылар. Башка бөтен бәхетләре үтерелгән төрмә кешесе өчен моннан да зур бәхет юк. Беренче мәртәбә аны унсигез көннән соң чыгарып, унбиш минут йөрткәннәр иде. Үз этажларыннан чыккан утыз-кырык кеше арасыннан бер генә таныш-белешен дә, һич югында, берәр русча сөйләшкән кешене дә очратмады ул. Тик бер озын гәүдәле кеше генә аңа: «Син хорват түгелме?»— дип, немецча эндәште. Шул да, шушы чит кешенең кешечә эндәшүе дә, бәхет иде.

Менә бүген, унбиш көннән соң, тагын чыгардылар. Тар гына озынча ишек алды. Сентябрьнең шактый түбән инган кояшы, ишек алдына төшеп җитә алмыйча, төрмә корпусы башларына эленеп кала. Шул шыксыз мәйданчык уртасына ярты метр биеклектә, бер генә кеше басарлык итеп, бетоннан озынча түгәрәк ясалган. Надзи-

ратель үз карамагындагы тоткыннарны алып чыга да шул бетон «күпер» өстенә тезә. Үзе түгәрәк уртасындагы буш урынга барып баса. Һәм тоткыннар унбиш минут буена аның җитез күзәтүе астында әйләнеп йөриләр. Гүя алар кешеләр түгел, ә кыргый киекләр. Уртадагы надзиратель — шул кыргый киекләрне цирк һөнәренә өйрәтүче маэстро. Аның күзгә күренмәс камчысы озын һәм зәһәр. Әз генә читкә тайпылдыңмы, камчының кылдан ишкән очы чажлап синең ботыңа яки биленә килеп төшә...

Түгәрәкнең тар башыннан борылганда, үзеннән арттагырак бер кешенең аны тырышып күзәткәнлеге Мусаның күзләренә чалынып калды. Икенче башны әйләнгәндә, ул аның үзен күзәтә башлады: өстендә легион солдаты кителе, яланбаш, чем-кара кыл чәчле, төптәс гәүдәле, бүрәнкәрәк авызлы... Туктале, тукта... бу бит Кылычбай түгелме соң?.. Димәк, алар да... Алар да!..

Муса, кинәт хәле киткән гәүдәсе белән артка борылып карый-карый атлый торгач, хәтта панель өстеннән егылып төшә язды. Надзиратель аңа кычкырып җибәрде:

— Алдыңа бак, швайн!

Алар никадәр карашсалар да, бер-беренә якын килү мөмкин түгел иде. Тик, унбиш минут узып, баскычтан меңгәндә генә, гомуми буталчык арасында, Кылычбай Мусаны куып җитте, биленнән кочаклады, алай унайсыз булгач, култыгыннан кысты. Алар икесе дә бер-берен сагынышканнар иде. Башкорт егете, Мусаның сораулары на тиз-тиз җавап бирергә тырышып, өлгерә алган хәтле барын да сөйләп алды.

— Унынчы август. Кырыклап кеше. Кайберләрен легионда ук кире чыгардылар. Кайберләре Аршау төрмәсеннән кайтарылды. Рушатов, Кормаш, Фәритев, Сәйфелмөлекев, Батталов, Хәсәнев Зиннәт, Шәрипов,

Фәхри Димский һәм мин — Берлинга китерелдек. Мин монда Зиннәт белән генә, бугай. Аның хәле бик авыр. Башкаларны Тегельгә озаттылар шикелле. Монауда урын юк, имеш...

Бу фажигале хәбәр Мусаны артык таушалтып жибәрде, бишенче катка көч-хәл белән генә менеп житте ул. «Бөтен тармаклар буенча һәлакәт... Нишләдек соң без?..»— дип кабатлый иде ул. Актык баскычларны менгәндә:

— Допроста ничек соң үзең?..— дип сорады.

— Без нык торабыз, беребез дә бирешмәй, Муса абый,— диде егет.— «Белмәем!»— жавап шул...

Егет үзенең 95 нче камерасына житте дә ишеккә карап басты.

— Шулай дәвам итегез!— дип пышылдады Муса һәм үз камерасына узып китте. Кылычбай аның кайда туктаганын күз кырые белән генә карап торды: бер, ике... биш... жиде, сигез... Әһә, сигезенче булып туктады: 103 нче камерада икән...

Камерасына кайтып кергәч, Мусага тагын да авыррак, монсу һәм күңелсезрәк булып китте. Бөтен дөнья караңгы болытлар астында, таш төрмәләр куенында калган кебек тоелды. Инде ничә мәртәбәләр кабатланган үкенү сүзләре тагын кабатланды. «Кемдер сатты безне... Юк, немецлар үзләре генә бернидә белә алмаслар иде... Кем? Кем булыр ул мөртәт?..»

Шул каһәрле сорауга жавап табудан гажиз булып, ишекле-түрле йөренә торгач, тәмам алжып, талчыгып идәнгә ятты. Аны шундук кандала сарып алды. Цивилизацияле немецларның Берлин уртасындагы зиндан камераларында бу комсыз хәшәрәтләр мыжылдап тора һәм, тоткыннарның актык каннарын суырып, симереп беткәннәр иде. Монда кергәннән бирле, Муса алар белән байтак кына сугыш алып барды, хәтта үткен кинаяләрен дә кулланды. Ләкин ул бер дә ирешмәде. Ул бер дә ирешмәде. Ул бер дә ирешмәде.

ле бер шигырь дә язарга мәҗбүр булды. Әмма бүген ул аларга игътибар итәрлек хәлдә түгел иде; үзен бөтенләй ташкатып ташлаган яңа кайгыдан әз генә онтылмакчы булып, күзләрен йомды, йокларга теләде. Ләкин алай җиңел генә онытылып китәргә язмаган икән әле, уйлар газабы тагын ялганып китте: «Каберебез шушы төрмә булыр микәнни?.. Кабер... Кайда ул кабер?.. Бәхетлеләрнең кабере билгеле бер зиратта, тимер чардуган эчендә, гөлләр арасында, якыннары янында була. Ә безнең кабер?.. Ул инде адәм аяк басмый торган нәмәгълүм бер урман эчендә, ач бүре өере генә улый торган текә ярлы ташландык бер чокырда булыр. Анда безнең шикелле йөзләгән-меңләгән гаепсез кешеләр аударылыр. Җир белән тигезләп күмәрләр... Кая сиңа киртә, кая сиңа, ичмаса, сыңар гына гөл сабагы? Хәтта исемең язылган такта башы да булмаячак. Илеңнән балаң килеп, дусың килеп эзләсә дә, тик бер генә эзеңне табудан да гажиз калачак...»

Камерага кичке эңгер керде. Мусаның күзләрен сөртелмәгән яшь ярысы каплаган иде. Ихтимал, шуңадыр ишек катындагы почмакларны күк томан сарган шикелле күренде. Хәрәкәтсез күзләр шунда төбәлгән килеш, уйлар газабы һаман дәвам итә иде әле... Менә кинәт уң почмактагы юка гына томан эчендә үлем шәүләсе пәйда булды. Ул үз төсендә иде: шыр сөяк гәүдә, шүрәленекеннән дә озын һәм шылтырап торган бармаклар, упкындай караңгы күз чокырлары, ыржаеп торган тешләр тезмәсе, чиртсәң — шыңлап көй чыгарыр сыман юка кабыргалар арфасы. Болар һәммәсе беравык эчендә Мусаның күзенә чалындылар да, ул сискәнеп китте. Хәтта курыкты да шикелле. Урыныннан сикереп торып, каядыр качарга теләде, ләкин кузгала алмады, әйтерсең кадаклап куйганнар иде аны. Бәләкәй чактагы шикелле, «тфү-тфү» дип, як-ягына төкермәкче булды, тик иреннә-

рә ачылмады, әллә нинди сагыз сыман нәрсә белән ябыштырып куйганнар икән. Төрлечә борылырга маташса да, барып чыкмады — нинди дер таш астында калган кебек иде. Шуннан соң үлем аңа көлемсерәп бераз якын килгәндәй булды да, «Курыкма!» дип, бармак янады. Мусага бик кызык тоелды бу: үзе үлем, үзе курыкмаска куша! Һәм ул кычкырып көлеп жибәрде. Бу юлы аңа иреннәрен ябыштырган сагыз да комачау итмәде. Ул әле хәтта: «Ник килдең монда?»— дип сорый да алды. Әмма монысы инде бөтенләй әрсезлек иде, үлемгә ошамады, ахрысы: ул шундук көлүен сүндерде дә, шыр сөяк чыраен ачу белән ыржайтып, Мусаның тезенә китереп типте.

— Ал-лай!— дип кычкырып жибәрде Муса һәм үз тавышына уянып китте. Ул, чыннан да, йокыда булган икән. Камера эче дөм-караңгы иде.

— Фу, шайтан алгыры,— диде ул һәм кузгалмакчы булды. Баягы тезе тагын авыртып китте. Җентекләбрәк караса, аның нәкъ өстенә диярлек, автоматик ачыла торган койка аягы төшеп баскан иде. Муса көлеп жибәрде: менә ничек икән ул эжәл типкән тез!

Хәзер инде ул койкасына менеп ятты да үлемне хәтерләде. Кайн килеп керде әле ул аның төшенә? Ә-ә, каберләр турында уйлаган иде бит... Гажәп, «Курыкма!»— дип көлемсерәве нәрсә икән? «Яшәрсең, үлмәссең, үтерә алмаслар!»— дигән сүземе?.. Муса эчке өмет яктылыгы тулган күзләрен югарыга, караңгы түшәмгә текәде. Тик анда бәхет йолдызлары күренми иде.

— Эх, бер әйбәт кенә төш юраучы әби булса икән монда!— дип куйды ул, үз-үзеннән көлеп. — Һәммәсен әйтеп бирер иде...

Ә икенче төнне бик тыныч йоклады ул. Хәтта кандалалар да ул хәтле каныкмадылар кебек тоелды. Һәм шул тынычлыкта бик матур яңа бер төш күрде. Казан-

дагы квартирасының йокы бүлмәсе ишеген ачкан кебек, камера ишеген җиңел генә ачып, нәни Чулпан берүзе килеп керде, имеш. Керде дә, этисен җитәкләп, тышка алып чыгып китте. «Карап бар, этием, машина тапламасын»,— дип, урам аша уздырды. Аннары бәләкәй генә, ямь-яшел генә Лядской бакчага алып керде. Муса ныклабрак караса, бу бөтенләй Лядской бакча түгел, ә кин җәелеп әллә кайларга киткән һәм ераклардагы исемсез тау итәкләренә барып тоташкан Саелмыш болыннары, имеш. Күз күремендәге бөтен тирә-як шау чәчәк белән тулган. Куе яшел яфраклы, алсу-шәмәхә һәм алсу-ак төстәге эре-эре тукранбашлар, бармак тиерсәң буявы сыланырдай сап-сары каз тәтиләре, бормалый-бормалый сибеп киткән зәп-зәңгәр конфетти төсле вак кына күгәрчен күзләре, сыек шәмәхә төстәге нәзек кенә, монсу гына, иркә генә миләүшәләр, сары түбәтәйләренә ап-ак эмаль каурыйлар тезеп чыккан ромашкалар тоташ ак түбәле пәри әнисләре, дымсурак җирләрне каплап алган әз генә йөнтәс яфраклы бөтнекләр, яр буйларына тезелеп киткән кара башлы камышлар, кара күбәләк канатыдай янып торган чәчәкле тән гөле, тагын әллә нинди-әллә нинди исемсез чәчәкләр бал тулы хуш ис аңкытып, әкрен генә тирбәләләр...

Чулпан, этисен җитәкләгән килеш, шул чәчәкләр арасыннан һаман бара да бара, «Әнә тегендәрәк матур, этием, әйдә, мин сине шунда алып барыйм»,— ди. Муса гажәпләнә: баланың бит әле бу болыннарда беркайчан да булганы юк. Ул аны бу якларга алып килергә өлгерә алмаган иде. Каян белә соң ул мондагы матур урыннарны? Һәм дөрес күрсәтә бит: анда көмеш төпле түгәрәк күл бар. Аның читендәге хәтфәдәй йомшак үләннәр, андагы саф һәм бик юка ярылы кыңгырау чәчәкләрдән музыка яңгырый кебек тоела иде. Чулпан этисен шунда җитәкләп килде дә каяндыр ак җәймә чыгарып җәйде,

сабыйларча куанып уртасына кереп утырды, шунда ук әтисен янына яткырып, аның башын алдына салды. «И әтием, әтием,— диде ул зарлы тавыш белән. Һәм чәчкә сабагыдай гына нечкә бармаклары белән чәчләреннән сыйпады.— Нишләп шулай бик озак йөрдең? Тәрәзәдән карап бер көн көттем, икене көттем. Аннары тәрәзәгә боз катты. Анысын санамадым. Боз эрегәч, тагын алтыга тикле санадым, аннары саным бетте. Санамыйча гына көттем. Әни әйтте, ун ай, диде, тагын әйтте: унике ай. Тагын сораган идем, инде бер ел узды артыгы белән, диде. Ничек инде ул: унике ай дип әйтә дә бер ел дип яңадан саный башлый. Алай дөрес булмый бит ул. Сагынгач шулай ялгыша торгандыр инде. Мин дә сине бик сагындым, әтием, даже мишкам белән дә уйнамый башладым. Сорыйм-сорыйм: әти кайчан кайта дим, һаман эндәшми. Үпкәләдем, җавап бирмәгәч...»

Муса, кызчыгының алдына башын салган килеш, шундый бәхетле булып, шундый рәхәт татып ята, имеш, аның өчен дөньядагы барлык гүзәллек шушында: Саелмыш тирәкләрендә таңгы сандугачлар сайравы да, шушы болыннардан күтәрелеп, күктән төшмәгән тургайлар җыры да, язгы түбәләрдә күгәрченнәр гөрләве дә, тезелеп узган кыр казлары тавышы да — һәммәсе дә, һәммәсе дә шушы сабыйның өзлексез чөкердәвендә җыелган. Бу фани дөньяда ана бүтән һични дә кирәкми. Чулпанкайның тавышы һаман дәвам итә: «Әтием, мин сине бер җиргә дә җибәрмим инде, яме. Әнә шул камышлардан шушында өй ясарбыз. Печән җыеп урын җәярбез, шушы җәймәне өстенә ябармын да, аякларым өстендә тирбәтермен. Мин әле онытмадым, син дә мине бәләкәй чакта шулай тирбәтә идең бит... Әни безгә чәй куяр, мороженое алып кайтыр...»

Ә Муса, куаныч диңгезендә тирбәлеп: «Нинди татлы

яшәү, көчле сөю! Нинди якты, иркен җир йөзе!..» дип пышылдый, имеш...

Әмма төшенең иң матур җирендә генә уянып китте ул. Әле таң яктысы тимер челтәрләр аша кермәгән иде. Шулай да үзенең кайда яткынын бик тиз шәйләп алды һәм бер генә секундка да үз тирәсен күрәсе килмичә, кабат күзен йомды. Карангыдан файдаланып, яңадан йоклап китәргә һәм бәхетле төшенә барып ялганырга теләде ул.

Әлбәттә, йоклый алмады. Төшенә кергән бәхетле беравыкның искиткеч рәхәтеннән башта айный алмыйча ятты, соңыннан исә, кара язмышның аны шушындый татлы хыяллар, татылмас куанычлар белән үртәвенә әрнеп, чиксез көенүләрен тыя алмады: «Ah, ни үрти мине хыял белән тик тилертеп, кайтмас язларым? Ник төш кенә минем шатлыкларым, ник бетмәс өн — кайгы, газабым?..» дип кабатлый иде ул.

Шундый җан һәм тән газаплары белән, төрмәнең бөтен әшәкелекләре, бөтен катылыклары һәм бөтен шакшылыклары белән тагын унбиш көн узып китте. Прогулкага чыгу сәгате якынлашты. Дөньяның искә дә алынмый торган иң гади генә ирекләреннән дә мәхрүм булган кешеләр өчен тышта үткәрелә торган бу унбиш минут, ачы көенеч булса да, үзенчә бер бәйрәм сыман тоела иде. Шул шырпы тартмасыдай тар һәм сасы ишек алдында булса да саф һава аласың, бәхетле булсаң — танышларыңны күрәсең, хәтта бер-ике сүз алмашу хәйләсен дә табасың. Муса да бу минутларны зарыгып көтеп алды. Допроста умырылган сәдәпләрен, балагының эчке чабуыннан җеп суырып, әлеге кадак ярдәме белән урыннарына такты. Чалбарын астына салып «үтүкләде», шул ук допроста өч-дүрт кенә теше калган тарагы белән чәчләрен тарады. Таушалып беткән күк күлмәге белән костюмын да рәткә китереп киде, соры туфлиен

дә чистартты. Ул бүген Кылычбайны яңадан күрү өметендә иде. Башка иптәшләре очраса да, өс-башының ыкътымат күренүе яхшы, алар борчылмасын...

Әйе, әгәр бу унбиш көн эчендә андый-мондый хәл булмаган булса, Кылычбайны, әлбәттә, күрер ул. Әкүр, сә, легион хәлләрен, андагы дусларын яңадан сорашыр. Кемнән шикләнүен, кемнең хыянәтче булу ихтималын белергә тырышыр. Аннары егеткә үз адресын бирергә уйлады ул. Чөнки Кылычбайның болар тырнагыннан котылу ихтималы шактый зур: анын күренеп торган гаебе юк, аңардан листовка чыкмаган, өешмада торганы немецлар өчен ачык мәгълүм түгел. Шулай булгач, бәлки, ул якты дөнья йөзен күрә алыр. Ә шуның белән бергә Мусаның да соңгы эзләре кайда югалганын якыннарына хәбәр итәр. Бер утырып искә алырлар...

Муса әйләнә-тирәсен күзәтенде. Нәрсәгә язарга соң? Бармак битедәй кәгазь кисәге дә, тырнак очыдай карандаш сыныгы да юк. Ул кесәләрен актарынды, әйләндереп селкесә дә, әлеге тарактан башка һичнәрсә чыкмады. Кара пластмасса таракның актык тешләренә карап торды. Һәм аларны тиз генә кырып ташлады да әлеге бәләкәй кадак белән тарак сыртының бер ягына Казан адресын, икенче ягына Мәскәү адресын тырнады. Әйбәт чыкты, җуелмаслык булды.

Һавага чыгару башлангач, Кылычбай белән күрешүне көткән Мусага баскычтан төшкәндә үк бөтенләй икенче кеше очрады. Кайчандыр һәрвакыт көләч йөз белән йөрүче, йомшак баритон тавыш белән җырлаучы, э хәзер бик боек чырайлы күренгән Фәхри Димский иде бу. Кинәт кенә болай бер-бере белән очрашуларына икесе дә бик куаныштылар һәм шунда ук сөйләшә-сөйләшә түбән төшә башладылар. Муса сораулар яудырырга тотынды. Аңа һәр очраган кешедән, ичмаса, бер генә, бә-

ләкәй генә яңалык ишетсә дә, ниндидер бер тотка, ниндидер бер таяныч булыр кебек иде.

— Сөйлә, сөйлә,— дип кызулады ул Фәхрине.— Тагын ниләр беләсең?

— Ниләр дип... Әллә ни юк та кебек инде дә... Әйтүе дә кыен шунда...

— Сузма, сузма,— дип түземсезләнде Муса.— Сузмый гына сук!

— Сук дип, ни бит... Әйтмичә дә булмый шул... Әшәке нәрсә инде ул...— дип унайсызланды егет, сүзләрен өзгәләп.— Безне сатучы Мәхмүт Ямалтаев булган...

Муса алдан төшә иде, кинәт борылып, күзләре тулы аптырау белән Фәхригә карады.

— Ямалтаев дисеңме? Кайсы ул?

— Ник, теге, күзлекле тыңкыш бар иде бит. Яңа пропагандист. Бөтен кыланышларын ук яратмый идем шунын, сагыз шикелле сылана иде, җырла да җырла, имеш...

Озын буйлы Фәхри, Мусага иеләрәк төшеп, үзенең Варшава төрмәсендә прогулкага йөргәндә Рушатов белән очрашуын һәм аңа Габдулла Батталов ниләр әйткәнен сөйләп бирде. Алар баскычтан төшеп җиттеләр дә әлеге бетон панель өстенә менеп тезелделәр. Кинәт тетрәнеп киткән Муса, башын түбән иеп, байтак кына сүзсез атлады. Аның артыннан атлаган озын муенлы Фәхри сузылып-сузылып аңа караштыргаласа да, ул тиз генә эндәшмәде, үз уйларына күмелде. Менә ничек икән ул... Әйе, хәтерли: төбәнәгрәк буйлы, яньчек борынлы, тыңкыш тавышлы.. Песидәй юаш кына кылана... Кормаш ашыгып ышанды микәнни соң? Якташ дип иде, бугай. Баттал да ашыгып эш иткән икән шул... Ә хәзер үзенә хөкем чыгарган. Хөкем... Кяшки ул хөкем белән генә хәлне төзәтеп булса иде? Муса хәтта үзенә дә ан-

дый хөкемне кабул итәр йде. Төп җитәкче буларак, тимер дисциплина урнаштырмавы өчен...

— Муса абый,— диде Фәхри,— сез ул хәтле кайтырмагыз. Әгәр башым исән кала икән, мин ул бәндәне дөнья йөзендә йөртмәячәкмен. Җиде кат җир астына качса да, табып алырмын. Менә сиңең алда ант итеп әйтәм, минем хөкем аңа шул.— Фәхри ике кулының озын бармакларын бөжраландырып күрсәтте.— Барыбыз өчен дә!— дип өстәде ул.

— Рәхмәт, мин әйтәсе сүзне син әйттең,— диде Муса кәефсез генә тавыш белән.— Әмма аның илгә кайтмавы бик мөмкин бит. Көнбатышка качар ул.

— Аңарчы!— дип кайнар пышылдады Фәхри.— Тик моннан гына ычкыныйм... Һәм ычкынырмын да! Мин җырчы гына бит. Гел йөреп тордым, берни белмәдем — шулай сукалыйм мин.

— Шулай сукала,— дип раслады Муса.— Дөрес булыр. Сине ничек кенә булса да котылдыру өчен тырышырбыз...

— Әмма минем өчен бер корбан да кирәкми, Муса абый,— диде Фәхри калтыранганрак тавыш белән. Аның күңеле нечкәреп, өмет, яхшылык һәм нәфрәт белән дулкынланганы сизелеп тора иде.— Сез болай да минем өчен мәңге онытылмаслык изгелек эшләгән кеше. Сез миңа хаклык юлын күрсәттегез, дөньяның яңа матурлыкларын ачтыгыз!..

Муса эндәшмәде. Аның уйлары, яхшылык — явызлык, жинаять — хөкем шикелле, мәңгедән килә торган кыен төеннәр эчендә чуала иде. Кешегә кул күтәрү — нинди авыр эш! Әмма берәү, үзенең кешелек сыйфатын югалтып, башкаларга зыян сала башласа, бик күпләр аның аркасында бәхетсезлеккә дучар булса, ул чагында ниш-ләргә?.. Бөтен кешелек җәмгыяте өчен уртак яхшылык гуманизм дип атала. Ләкин гуманизмның да җәмгыять

иминлеген саклау өчен каты хөкемнәре бар. Ә Ямалтаев иң әшәке хаинлык эшләгән...

— Корбан турында баш ватмыйк,— диде Муса, ниһаять, сүзгә килеп.— Барыбыз да гаделсезлек корбаны... Ә хөкемнә... мин дә кушылам. Ләкин без әле оешманың бары ике генә әгъзасы. Башка ептәшләрне күрсәң, безнең карарны аларга әйт. Мин күрсәм дә әйтермен. Алар да кушылсалар, бу хөкем, иртәме-соңмы, җиренә җиткерелергә тиеш!

— Антым шушы!— диде Фәхри, гәүдәсен турайта төшеп.— Үтәлер!..

Кыен сүз иде бу. Озакка сузылды. Башка нәрсәләр хакында сөйләшергә дә өлгермәделәр, керергә команда булды. Муса Кылычбайны да күзәтә алмыйча калды. Чыккан идеме ул, юкмы — күзенә чалынмады. Һәм алда тиз генә күрә алырмы ул аны?.. Баскычтан менгәндә, Муса Фәхринең артына туры килде. Шунда аның адрес мәсьәләсе исенә төште. Нишләргә соң? Әгәр Фәхригә генә тапшырса? Нигә, икесе дә якын дуслар ич. Һәр икесе дә кыенсынмый үтәр аның соңгы теләген... Һәм ул әлеге тарак сыртын чыгарды да Фәхринең китель кесәсенә төшереп җибәрде. Баскычтагы ыгы-зыгы белән егет аны үзе дә сизмәде.

— Беләсеңме, Фәхри,— диде Муса, өченче катка менеп җиткәндә.— Дөньяның хәлен белеп булмый... Кайсыбыз исән калсак та, гаиләләребезгә хәбәр итешик... Мин синең кесәңә адрес салдым. Сакларга тырыш, әйбере сакланмаса, күнелеңә сеңдереп куй. Шул адреслар белән барып табып, минем кызыма, әгәр көткән булса, Әминәмә, безнең бергә тартышканнарны, бергә газап чиккәннәрне сөйләрсең... Икенче прогулкага син дә адресыңны язып алып чык. Мин дә Зәй буйларындагы Акбаш авылына, әниең янына барырмын... Һәм белмәссең, бәлки, без шунда кочаклашып тагын күрешербез!..

— Мин дә шуны бик телим, Муса абый,— диде Фәхри.— Шундый куанычта исән-сау күрешсәк иде!

— Допросларда ник тор. «Белмим»нән башканы белмә!— дип, тагын бер кисәтте Муса.— Чыгармый хәлләре юк, чөнки синнән һичнәрсә табылмаган. бит. Ә инде моннан котылгач, Франкфуртка бар, Одердагысына. II вокзал, пивзавод. Шилов. Кайсы баракка кереп сорасаң да, аны белерләр. Ул сезгә ярдәм итәр һәм нишләргә кирәклеген дә әйтер. Безнең хәлләрне дә сөйләп бир. Ул хикмәтле кеше. Элемтәсе зур... Тиешле чараны күрми калмаслар...

— Ярый, Муса абый. Әгәр тиз генә легионга озатмасалар, обязательно барам.

— Берлинда калырга тырыш. Радиога сора. Җырларга.

Димский үз ишеге төбендә тукталып калды, сүзләре дә кинәттән генә өзелде. Тагын әллә ниләр сөйләшәселәре бар иде әле, ләкин булмады... Аның янында бер генә авыкка тоткарланган Мусаны надзиратель төрткәләп ары таба алып китте...

МОАБИТ ТОТКЫНЫ

(Поэмадан өзек)

Калмык шагыйре Даут Күгелтдинов Бөек Ватан сугышы елларында Берлиннең Моабит төрмәсендә газаплап үтерелгән татар сугышчысы һәм шагыйре турында поэма язды һәм ул аны шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә багышлый. Әсәрнең төп герое Тимер исемле булса да, аның тоткынлык биографиясеннән кайбер детальләре тулысынча Мусаныкы шикелле итеп бирелмәсәләр дә, батырлыкка һәм үлемсезлеккә дан жырлаган бу поэманы без сөекле һәм бәһадир Мусабыз истәлегенә күтәрелгән һәм күтәреләчәк поэтик һәйкәлләр исемлегенә куанып кертәбез.

Поэма, калмык поэзиясенә гомумән хас булганча, ак шигырь белән язылган. Оригиналда шигырь юлларының үлчәве һәм ритмы ирекле, ә рифмалар бөтенләй юк. Өзекләрне шагыйрь Зәки Нури татар укучысына якынрак булган ритм белән һәм рифмалап тәржемә итте.

...Бомба көтеп курыккан бер илнең
Мәркәзендә — ягъни Берлинның
Урамыннан уза машина —
Үзе утсыз, үзе ашыга,
Үзе житез, үзе кара ул,
Һәм кара бер йортка бара ул.
Куркыныч һәм чиксез кара йорт
Кара төндә күренә каралып.
Оясы ул кыргый эшләрнең,

Қабере ул тере кешеләрнең —
Анда җанны утка аталар...
Ул Моабит диеп атала.
Эзеп салып Берлин ташына
Менә шунда килде машина.

...Тоткын текәп карый башлады —
Язмыш аны кая ташлады?..
Берлин төрмәсендә хәзер ул.
Исеме — Тимер, үзе — шагыйрь ул.
Бу таш төрмә — гүя таш оя.
Тар бүлмәләр уйган таш кыя
Белән аны мөмкин тиңләргә —
Көннәр дә бер монда, төннәр дә.
Баш бәрелер диеп куркасың,
Монда кергәч — буең иелгән.
Ә тутыккан тимер койкасы
Таш идәнгә коеп куелган.
Бер тишек бар тимер ишектә,
Лампа яна — кизү якты бар,
Кирәк — күрә, кирәк — ишетә
Нишләвеңне синең сакчылар.
Тәрәзәдә тимер рәшәткә,
Стенада шәүлә — челтәрле.
Зурмы урын?— Уйлап баш ватма,
Өч атларга, бәлки, җитәрдер.
Кандалалар эле посканнар,
Тик идәндә чаба тычканнар...
Барысын, барысын Тимер карады.
Һәм, утырып, каты яралы
Аягын ул чиште яңадан —
Кан саркыла иде ярадан.
Гимнастерка кигән иде ул,

Тар якасын шуның капшады.
Башын кинәт түбән иде ул,
Тирән уйлар уйлый башлады.

«Күрешергә дип килгәч хатыным,
Күз яшьләре чыгар атылып...»
Төрмә җыры төште исенә.
Һәм, ялганып берсе берсенә,
Үткән көннәр китте күренеп.
Утырды ул уйга күмелеп.
Унөч яшьлек малай чакта ул,
Күз йоммыйча төнлә хәтта ул,
Өйләрендә бетсә керосин,
Яки сайлап учак тирәсен,
Айлы чакта яки утырды —
Бертуктаусыз китап укыды.
Укыды ул шулар турында:
Патша хакимлеге чорында —
Һич курыкмыйча кемнәр көрәшкән
Өмет нуры сибеп йөрәктән,
Бутыркада, Шлиссельбургта
Ач үлемнең үзен күреп тә
Каршы торып явыз үлемгә
Үлемсезлек өчен иләндә
Кем көрәшкән аямый үзен —
Укыды ул шуларның сүзен,
Фигнер, Морозовны укыды.
Бар диеп тә белми куркуны,
Шулар итеп үзен төрмәгә
Яба иде, һичбер кемгә дә
Сер бирмичә сынау алганда,
Ышанмыйча һичбер ялганга
Халык өчен кыю торды ул,
Тәрәзәгә күзен борды ул,

Һәм караган чакта аны да
Рәшәткәле итеп күрде ул.
Я булмаса көннең берендә
Хөкем иткәч үзен үлемгә
Сакчыларны алдап качты ул,
Төрмә ишекләрен ачты ул...
Шул чакларны шагыйрь уйлады.
«Эх, иртәрәк туып булмады!
Утыз биш ел бары яшәдем...
Ә син, язмыш, кая ташладың?»

Күз алдына килде киткәндә
Шаулап калган Казан каласы,
Сораганы соңгы үпкәндә
Җаны сөйгән газиз баласы:
«Әти, әти, тизме кайтырсың,
Табышмаклар миңа әйтерсең?»
Күз алдына килде анасы:
«Начальникны тыңла, балам, син!»
Камиләсен — сөйгән хатының,
Йөрәгенә иң-иң якының
Хәтерләде Тимер — гүя ул
Анда һаман: «Саклан!»— дия ул.
Хәтерләде барлык дусларны,
«Җиңеп кайт!»ны, «сау бул, хуш!»ларны,
Озатканда әйткән сүзләрне
Һәм озатып калган күзләрне.
Күзләр, күзләр... моңсу идегез,
«Кемнәр кайтыр икән...»,— дидегез...

...«Фелькишер Беобахтер» газетын
Китермиләр бер дә аз итеп —
Укыгыз дип һәрбер иртәдә

Һәр бүлмәгә аны кертәләр.
Белеп торсын, имеш, тоткыннар
Һәм һәрвакыт истә тотсыннар
Фашизмның көче күплеген,
Аны җиңәр көчнең юклыгын.
Ә газетны укып кешеләр
Тик кирәген генә эшлиләр:
Күңел иләгеннән үткәреп
Җилгәрәләр ялган чүпләрен.

Алдап язса газет бер эшне,
Күңел аңлый барыбер дөресне.
Басыла икән Геббельс чыгышы,
Төрмә белә: фашист сугышта
Бик әйбәтләп, димәк, кыйналган.
Һәм белеп тор шуны син алдан:
Бер фронтта фәлән авылны
Алдык, диеп газет кычкырса,
Андый хәбәр булыр чи ялган!..

Кәгазь, кәгазь! Телсез зирәклек!
Син һәркемгә бик-бик кирәк бит.
Ә эшендә исә шагыйрьнең
Син менләгән тапкыр кадерле.
Кәгазь, кәгазь, булды чакларың,
Урамнарда очтың чүп булып,
Кайчакларда ертып ташладым —
Кәрзиннәрдә яттың күп булып.
Бүген исә, бүген Тимергә
Тәндәге җан кебек кирәк син,—
Бик күп уйлар туды күңелдә,
Илтәласың шуны ерак син.
Чарладым мин тормыш ташында
Йөрәкне һәм заман фикерен,—

Син булганда шуның барсын да
Киләчәккә була җиткереп.
Үтәү өчен изге теләген —
Сөйләттерер өчен йөрәген
Сине, Тимер, сине эзләде.
Очкынланды менә күзләре —
Инде бүген кәгазь тапты ул.

Кыштырдый ул, ак ул, якты ул!
Ак тасмалар кисеп газеттан
Бүген менә дәфтәр текте ул —
Саклаулары җайлы булсын дип,
Кош теледәй нәни итте ул.
Шиненленең сүтеп җөйләрен
Шул дәфтәрне ерак яшерде.
Йөрәк серен күкрәп сөйләр ул —
Йөрәге бит аның яшенле.
Якасына яшереп озак ул
Саклап йөртте карандаш үзәге,
Вакыт җитте аңа чыгарга!
Каләм итеп шуны тыгарга
Сабына ул агач кашыкның
Энә белән оя казыды.
Җырлап була! Күңел, ташып тул,
Һәр авазың, йөрәк, язылыр!...

...Башта бер уй, тик бер уй иде:
— Каләмеңнән ялкын кой!— диде
Уйлар аңа. Уйлар кычкырды,
Һәм, әйтерсең, аңа көч керде.
Кәгазь алды, яҙып утырды —
Дәфтәренә ялкын тутырды,
Кабынды ул сихри көч кереп.
Куйгач ләкин кинәт йөткереп

Авызына аның кан килде...
Үпкә каны — кара кан иде.
«Тоткын идем, авыру өстәлде...
Юк! Башкармый үлмәм эшләрне —
Мин җиңәрмен сине, үлем, белән,
Мәңге үлми торган җырым белән!..»

...Шундый гүләү кинәт ишетелде,
Күкнең төбе, гүя, тишелде
Һәм яудылар аннан бомбалар,
Дошман җиренә сибелә мул алар!
Бомба ява Берлин өстенә —
Фашист өнен зур һәм кечкенә
Бик күп бомба бүген актара...
Төтен. Сөрем. Һәр як — кап-кара.
Чын күңелдән Тимер куанды,
Бөтен хисе аның уянды,—
Канатланып гүя китте ул,
Үзе гүя бомба сипте ул.
Күңелкәе аның очына:
«Утыртып сез канат очына
Туган илгә алып китегез,
Җырларымны минем илтегез.
Россияне килә күрәсем,
Шатлык белән килә үләсем!..»

Барздаускас — фашист хакиме
Үзе керде бүген бүлмәгә.
Карары шул: «Тимер, эй Тимер,
Син моңарчы нигә үлмәгән?..»
Таш идәндә Тимер Моратов
Ята иде әрнеп, әлсерәп.
Барздаускас утыра сорашып,
Читтән башлый сүзне — хәл сорап:

— Моабит бу, тыныч була бездә,
Куркынычсыз урын — шул бездә.
Ишә алмый аны бомбалар,
Табалмыйлар монда юл алар.
Шәп саклыйбыз сезне, шагыйрьне,
Сез бит, шагыйрь, безгә кадерле!

— Рәхмәт сезгә. Саклау — яхшы ул.
Бәйрәм ашы — кара-каршы ул:
Белеп торсын сезнең хөкүмәт,
Һәм Гитлерың белсен — Албастың,
Бездән шундый катгый хөкем әйт:
Германия исән каласын
Тели икән — безнең белән ул
Үз урынын бүген алмашсын.

— Әгәр эшләр алай булмаса?
— Шулай кирәк. Бүтән юл — начар!
— Һәркайда сез лаек кадергә,—
Хөрмәтем зур минем шагыйрьгә.
— Күреп торам барысын көзгесез.
— Аңламыйсыз ләкин безне сез.
— Төшенермен тиздән һәммәсен!
— Ачыгырак сөйлик. Әллә сез...
— Бер кат күрү сезне бик җиткән,
Германияне аңлыйм мин күптән.
— Шаяртасыз юкка, шагыйрь, сез,
Илгә кайткач,— сез бит кадерсез
Булачаксыз: ГПУ эзәрлә,
Кыен булыр сезгә түзәргә!..
— Шуңадыр шул безне саклыйсыз,
Таш түбәләр белән каплыйсыз.
— Германиядә төрмә күп түгел.

Ә бүтәне исә юк түгел:
Матур кызлар, матур көйләр бар.
Германиядә бик күп өйләр бар...
— Җир астында!..
— Безнең гаскәрләр
Тиздән тагын һөҗүм башларлар.
Мәскәүләргә табан булыр юл.
— Берлин аша ләкин булыр ул.
— Сез, язучы, Гитлер гаскәрен
Аңлау өчен, ахры, яшь әле.
Тактикага, яшерен маневрга
Төшенүләр, хәер, авыр ла.
— Бисмарк, Мольтке, Шлифен канатын
Нинди генә утлар өтмәде,
Ә тактика һаман бетмәде,—
Хәзер аны Гитлер яңартты,
Һәм сынамак булды сугышта.
Версальдан да яман «уңышка»
Китерә ул сезнең ватанны.
Кисәттеләр күпме кат аны:
— Көнчыгышка күзең салма!— дип,
Наполеон хәленә калма! — дип.
Мольткеларның шәкерт яшьләре —
Шәрикләре, шәриктәшләре
Людендорфлар белән Кейтельләр:
— Сугышабыз!— диеп әйттеләр,
Һәм сугышка барып керделәр,
Һәм Паулюслы көчле гаскәрне
Сталинградка илтеп бирделәр...

— Хәрби дәрес миңа бирергә
Митинг түгел сиңа биредә.
Мин карцерда сине ишеттем,
Һәм, кызганыч, йомшак эш иттем.

Исемнәрен яле, әйт безгә,
Күпме бандит оешмагызда?
— Сүз бирелә икән, сүз алыйм да
Әйтсәм әйтим инде дөресен мин:
Күрәм менә хәзер күз алдымда
Бандитларның иң-иң зурысын мин.

— Җитәр! Җитәр!
— Ләкин ул бандит
Асылыр өчен җиргә туган бит...

Барздаускасның йөзе кызарды,
Томанланып кинәт күз алды,
Чырай сытты, кашын җимерде.
Атар өчен шунда Тимерне
Кобурына кулын сузды ул,
Юкка иде ләкин — сизде ул,
Парабеллум янда кермәгән,
Шундый закон чөнки төрмәдә.
Тик күзеннән агу сипте ул,
Бер кычкырып аяк типте ул,
Сакчыларга бирде әмерне:
— Чыгарыгыз! Белми кадерне...

Нәкъ шул чакта, нәкъ шул бүлмәгә —
Бер кош керде очып төрмәгә.
Ак күгәрчен! Кара төрмәгә
Тәрәзәдән очып керде ул.
Канатларын җилпеп бер мәлгә
Тар бүлмәдә очып йөрде ул.
Аны, ахры, бомба куркыткан —
Качып кергән монда ул уттан.
Карап торды палач аптырап,
Һәм, куллары кинәт калтырап,

Шприцы төште идәнгә.
(Агулаучы иде бу бәндә.)

Курыкты сакчы:— Нәрсә булды бу?
Ни галәмәт! Начар билге бу...
Ул да, эчтән нидер укынып,
Баш киемен салды куркынып,
Ә Тимергә шул чак аларны
Рәхәт иде көлеп каравы.
— Менә кемгә, менә кемнәргә
Тапшырганнар безне җиңәргә.
Мескен җаннар! Мескен һәммәсе!—
Тимер көлде, Тимер күзендә
Кечерәйде дошман шәүләсе.
Тимер үлде... Тимер йөзендә
Яшәү чаткылары сүнделәр.
Ят бер илнең салкын көзендә,
Белмим, аны кайда күмделәр...

...Илләр буйлап җилләр исәрләр,
Моабиттан килер авазлар:
— Булсын өчен көннәр аязлар,
Онытмагыз безне, исәннәр!

Илдар Юзеев

СОҢГЫ СЫНАУ

(Драматик легендадан өзек)

Муса Җәлил үлем җәзасы алдыннан Гётеның «Фауст»ын кабат укыган.

1920 ел. Оренбург өлкәсе, Мостафа авылы.

Мефистофель — Әй яшь бала, ундүрт яшьлек яшь бала,
Тормыш юлың бигрәк ямьсез башлана.
Язмышыңнан узмыш юк шул, ни чара,
Ни атаң юк, ни атың юк, бичара.
Әй яшь бала, шигырь язып сызланма,
Үз хәлең хәл — кешеләрне кызганма.

Яшь Муса. — Туган якны камап алган дошманнар.
Шундый чакта өйдә карап ятыймммы?!
Халык эшен яклау өчен сүз бирәм,
Тәкрарлыймын күңелемдәге антымны.

Мефистофель — Шагыйрь булсаң, үз «мин»еңә табынсаң,

Гомерең узар рәхәт тормыш, дан белән.
Корал тотып яу кырына омтылсаң,
Исемеңне чикләрсең син кан белән.

Яшь Муса.

Алда яна якты өмет — идеал,
Шул маякка карап юлга чыгам мин.
Ирек өчен кан коярга әзермен,
Хаклы юлда ни күрсәм дә чыдам мин.

Мефистофель

Мин ни күрәм — бер кулында берданка,
Ай-һай, егет, хәтәр юлга басасың,
Каләмең дә сөйли мылтык телендә,—
Үз бәхетеңнән үзең теләп качасың.

Яшь Муса.

Ил бәхете — ул минем дә бәхетем,
Җир бәхете — ул минем дә бәхетем.
Мин дә барам сезнең белән, абыйлар,
Җимерергә тираннарның тәхетен.

Мефистофель

Баш тарт, бала, баш тарт тизрәк антыңнан,
Китсәң әгәр абыйларың артыннан,—
Анда сине бары тик дәһшәт көтә,
Михнәт, газап, ачлык һәм вәхшәт көтә.
Бер адәм дә түзмәс сынаулар көтә.
Коллык, тарлык, хурлык, богаулар көтә.

Яшь Муса.

Җилләр иссен, давыл купсын — барырмын,
Ташлар яусын, яшен суксын — барырмын.

Егылсам да күккә карап ятам мин.
Омтылырмын алга, кире кайтмам мин.
Туган-үскән җирем, туган йортым,
Хәерле юл телә җырчыңа.
Ул көрәшкә чыга...

Мефистофель. Мескен адәм...
Үлеменә каршы юл чыга.

Яшь Муса. Дошманнарга каршы яуга китәм,
Җыр өйрәткән далам,
Исән бул!

Дала. Ирек тәмен белеп, уйнап-көлеп,
Йөгереп үскән балам,
Исән бул!
Син әйт, балам,
Кайтырсыңмы тагын?

Яшь Муса. Балачагым,
Бер сәгатькә генә
Кайттым сиңа.
Сау бул, исән бул.

Дала. Биргән антын йөрәгендә йөрткән
Туры сүзле балам, исән бул.
Күкрәгемдә эз калдырып үткән
Коңгырт күзле балам, исән бул!

Яшь Муса. Бала күңеле була далада.

Дала. Дала күңеле була балада.

Яшь Муса. Сау бул, иркен далам, хуш, далам...

Дала. Мин тышанып калам, хуш, балам...

Мефистофель. Сайла, бала, я даладан китмисең,
Я гомереңне төрмә белән чиклисең.
Әйтеп куям: анда сине кем көтә:
Алда сине коточкыч үлем көтә.

Яшь Муса. Ни көтсә дә туктамам мин.

Мефистофель. Туктарсың,

Күрү белән гомереңнең ноктасын.

Яшь Муса. Юк, мин юлга туктар өчен
чыкмадым!

Мефистофель. Ищет үлем сәгатенең сукканын.
Туктадыңмы?!
Ха-ха-ха-ха!
Туктадың.

Яшь Муса. Ни күрәм мин...
Юлым кая борылган?
Бөтен дөнья җимерелгән, кырылган.
Алда — төрмә. Үлем йорты.
Кайда мин?

Мефистофель. Сайладыңмы туры юлны?
Сайладың.
Иң ахыргы минутларың
Саныйсың...
Таныйсыңмы бу адәмне?
Таныйсың...
Әллә инде үз-үзеңне
Оныттың?
Бу — син үзең. Синең соңгы
Минутың.

Яшь Муса. Кулларымда — богау?..

Төрмәдәге
Муса. Үлем көтәм.

Мефистофель. Палач — балтасына тотына.

Яшь Муса. Ә син — тыныч...

Төрмәдәге
Муса. Тиран калтырана.
Дөнья богаулардан котыла.

Яшь Муса. Чал чәчләрем тузган...

Мефистофель. Гомер узган...

Төрмәдәге
Муса. *Дөнья авырлыгын күтәреп.*

Шатлыгын да, ачы хәсрәтен дә
Үз йөрәгем аша үткәреп.
Яшь Муса. Ябыкканмын. Гәүдәм кечерәйгән...
Мефистофель. Итек асларында тапталды.
Җирнең барлык газапларын алды...

Төрмәдәге
Муса. Мәгърур җаным ләкин саф калды.
Мефистофель. Юлларында таулар-ташлар ауды.
Тимер сынды...

Төрмәдәге
Муса. Ә мин сынмадым.
Мефистофель. Йөзләр-меңнәр ауды. Күзен йомды.
Мәңге тынды.

Төрмәдәге
Муса. Ә мин — тынмадым.
Кан төкерә-төкерә, көчсезләрне
Азатлыкка өндәп җырладым.
Яшь Муса. Күзләреңдә уйный таң нурлары.
Мефистофель. Сүнәр алар нурлы иртәдә.
Төрмәдәге
Муса. Көрәшченең гомере кыска була,
Данлы үлем белән чикләнә.
Мефистофель. Йөз кайгыга — бер сөенеч күрден,
Әйләнеп син кара артыңа...

Төрмәдәге
Муса. Михнәт-газап китсен үзем белән,
Шатлык кына калсын халкыма.
Мефистофель. Ә син, бала, чыктың шундый юлга,
Кит, кире кит, төкер антыңа.

Төрмәдәге
Муса. Күкрәгемнән беркем ала алмас,
Мин җанымны бирәм халкыма.
Һич куркытмый авыр көрәш юлы,
Мәгърур җаның әгәр яшь булса,

Мин — дәвамың синең. Ахырым юк,
Туктап калма юлда, яшь Муса.
Йомшаклыктан диеп уйлый күрмә
Күзләремә әгәр яшь кунса,
Синең рухың яши бу җанымда,
Синең каның ага, яшь Муса.
Бер дошман да башын идерә алмас,
Хисләреңә акыл баш булса,
Син башлаган юлдан горур бардым,
Куркып чигенмәдем, яшь Муса.
Бер тиран да тезләндерә алмас
Ихтыярың корыч, таш булса,
Күңелем йомшак минем, дусларыма
Бар җылысын бирдем, яшь Муса.
Җырчы исеме миңа харам булсын,
Яшьлек антларыма тап кунса.
Кеше исемен аклап җирдән китәм,
Әмма юлдан китмим, яшь Муса.

Мефистофель. Әһә... Адәм икеләнә...
Син каласың...
Ул китә.
Әҗәл шулай, якынайгач
Җан иясен өркетә.
Йөз ел гомер сине көтә
Рәхәтлектә, иркендә...

Төрмәдәге Муса. Ялгышасың, бу җанымны
Аера алмас беркем дә!

Яшь Муса. Иң беренче җырым минем!

Төрмәдәге Муса. Иң соңгы йөрәк җырым!..

Яшь Муса. Бернинди көч бора алмас
Мин барган көрәш юлын!..

Муса. Йөз ел җирдә яшәгәнче

Җансыз күкрәгем белән,
Караңгы Җирне яктыртып,
Мин яшьли яшьнәп үләм!

Мефистофель. Тылсымымның кинәт көче бетте,
Ия булалмадым мин аңа.
Әй, сакчылар!

Төрмә сакчылары. Әҗәл килде!

Мефистофель. Озатыгыз гильотинага!

. . . . . .

(Гильотина.
Балта ялтырап китте.
Алсу нур чорнады төрмәне.)

Төрмә сакчысы. Үлде...

Мефистофель. Ләкин җанын бирмәде.

ИСКӘРМӘЛӘР

«...Ул гасырлар буе балкып торыр» (Муса Җәлил турында совет һәм чит ил язучылары). 1965 елның җәй аенда ТАССР дәүләт музее кайбер танылган совет язучыларына Җәлил һәм аның поэзиясе турында үзләреңнең фикерләрен язып жибәрүләрен сорап мөрәҗәгать итә. Күп тә үтми, илебезнең төрле почмакларыннан — Мәскәүдән һәм Тбилисидән, Ленинградтан һәм Бакудан, Киевтан һәм Ашхабадтан, Уфадан һәм Вильнюстан, шулай ук бүтән жирлардән — Татарстанның дәүләт музее адресына күп санлы хатлар килә башлый. Ул хатлар шагыйрьнең гражданлык һәм поэтик батырлыгына *тирән соклану һәм хөрмәт белән* сугарылганнар, алардагы һәр юлда дулкынлану, мәхәббәт сизелеп тора.

Бу хатларның төп нөсхәләре Татарстанның дәүләт музеенда сакланa. Русча алар беренче булып «Советская Татария» газетасы битләрендә басылдылар, татарча — «Казан утлары» журналында дөньяга чыктылар («Казан утлары», 1966 ел, 2 нче сан). Бу жыентык өчен алар нигездә «Казан утлары» битләреннән алынды. Леон Небенцаль, Мостай Кәрим һәм Луи Арагон фикерләре «Муса турында истәлекләр» (төзүчесе һәм әдәби эшкәртүчесе Газиз Кашшаф. Татарстан китап нәшрияты. 1964 ел) китабыннан кыскартылып алынды. Сәмәд Вургун сүзләре Җәлилнең 50 еллык юбилеенда (1956 ел) сөйләнгән реченнән алынды.

Хәсән Туфан. Шигырьләр. (Хәсән Туфан. «Давыллы еллар лирикасы». Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1970 ел.)

Сибгат Хәким. Шигырьләр. (Сибгат Хәким. Җылы сүз. Шигырьләр, поэмалар. Татарстан китап нәшрияты. 1968 ел.)

Сәгыйть Агиш. Якташлар. (Сәгыйть Агиш. Якташлар. Повесть, хикәяләр һәм истәлекләр. Башкортстан нәшрияты. Уфа. 1964 ел.)

Сәлих Баттал. Син — *политрук.* («Казан утлары», 1966 ел, 2 нче сан.)

Хисам Камалов. Синең язмышың. («Казан утлары», 1966 ел, 2 нче сан.)

Галимжан Латыйп. Ромашкалар. («Казан утлары», 1966 ел, 2 нче сан.)

Михаил Дудин. Мәңгелек жыр. («Казан утлары», 1966 ел, 2 нче сан.)

Педер Хузангай. Син урнаштың дөнья күкрәгенә («Казан утлары», 1966 ел, 2 нче сан.)

Нәкый Исәнбәт. Муса Җәлил. (Нәкый Исәнбәт. Сәхнә әсәрләре. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1958 ел.)

Нәби Дәүли. Берлинда окоп. (Нәби Дәүли. Юлда очрашулар. Сайланма әсәрләр. Татарстан китап нәшрияты. 1964 ел.)

Әнвәр Давыдов. Муса абый. (Әнвәр Давыдов. Муса абый. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1964 ел.)

Гали Хужиев. Безнең Муса. (Гали Хужиев. Безнең Муса. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1957 ел.)

Риза Ишморат. Үлмәс жыр. (Риза Ишморат. Сайланма әсәрләр. 2 нче том. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1967 ел.)

Жубан Молдагалиев. Жыр турында жыр. (Жубан Молдагалиев. Жыр турында жыр. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1959 ел.)

Шәйхи Маннур. Муса. (Шәйхи Маннур. Муса. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1968 ел.)

Даут Күгелтдинов. Моабит тоткыны («Совет әдәбияты». 1959 ел, 9 нчы сан.)

Илдар Юзеев. Соңгы сынау. (Илдар Юзеев. Соңгы сынау. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1969 ел.)

ЭЧТӘЛЕК

Рафаэль Мостафин. Көрәш җыры. *Кереш сүз* . 3
Ул гасырлар буе балкып торыр (Муса Җәлил турында совет һәм чит ил язучылары) 16
Хәсән Туфан. Европа өстендә Җәлил таҗышы, Иртәләр җитте исә. Моабитны күрдем төшемдә. *Шигырьләр* . 26
Сибгат Хәким. Җәлил шәһәре, Һәйкәл урынында уйлар. Торыгыз, Мусалар. *Шигырьләр* 32
Сәгыйть Агиш. Якташлар. *Повестьтан өзек* . . 35
Салих Баттал. Син — политрук. *Шигырь* . . . 51
Хисам Камалов. Синең язмышың. *Шигырь* . . 52
Гөлнимҗан Латыйп. Ромашкалар. *Шигырь* . . 53
Михаил Дудин. Мәңгелек җыр. *Шигырь.* Мөхәммәт Садри тәрҗемәсе. 55
Педер Хузангай. Син урнаштың дөнья күкрәгенә. *Шигырь.* Нури Арсланов тәрҗемәсе 57
Нәкый Исәнбәт. Муса Җәлил. *Трагедиядән өзек* . 60
Нәби Дәүли. Берлинда өкоп. *Поэмадан өзек* . . 103
Әнвәр Давыдов. Муса абый. *Повестьтан өзек* . . 110
Гали Хужи. Безнең Муса. *Поэмадан өзек* . . . 141
Риза Ишморат. Үлмәс җыр. *Героик драмадан өзек* . 155
Жубан Молдагалиев. Җыр турында җыр. *Поэмадан өзек.* Шәрәф Мөдәррис тәрҗемәсе 192
Шәйхи Маннур. Муса. *Романнан өзек* 208
Даут Күгелтдинов. Моабит тоткыны. *Поэмадан өзек.* Зәки Нури тәрҗемәсе 227
Илдар Юзеев. Соңгы сынау. *Драматик легендадан өзек* 238
Искәрмәләр 245

БЕССМЕРТНАЯ ПЕСНЯ

Литературный сборник о Мусе Джалиле

(на татарском языке)

Редакторы К. Миңлебаев

Художнигы В. Зелинский

Художество редакторы А. Садыйков

Техник редакторы Э. Трофимова

Корректорлары С. Вильданова, Д. Миңнуллина

Наборга бирелде 26/II-1971 ел. Басарга кул куелды 1/VII-1971 ел. ПФ 06134. Типография кәгазе № 2, 70×108 1/32. Учет.-изд. таб. 9,96. Якынча басма таб. 10,85. Заказ В-86. Тираж 6000. Бәясе 61 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур. 19.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең „Татполиграф" типографиясе. Казан, Мирославский ур., йорт 9.

